# Татар драматурглары

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2007

УДК 030
ББК 92
Т23

Төзүчеләре:

***Флера Ганиева, Рамилә Яруллина, Алсу Саттарова***

Татар драматурглары: биобиблиографик белешмәлек / Төз. Ф.Ганиева, Р.Яруллина, А.Саттарова; Кереш сүз авт. Ф.Ганиева. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 271 б. — 3000 данә. — ISBN 978–5–298–01481–6

Китапта 108 язучының — драматург, прозаик-драматург, шагыйрь-драматург, артист-драматургларның кыскача биографияләре һәм иҗатлары турында мәгълүматлар бирелә.

SBN 978–5–298–01481–6

© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Ганиева Ф.Ә., Яруллина Р.Ә., Саттарова А.М., төзү, 2007

## КЕРЕШ СҮЗ

Әдәбиятның проза һәм шигърият төрләре янәшәсендә драматургия аерым урын алып тора. Аның үзенчәлеге шунда — драматург үзенең пьесасын китап булып басылып чыксын дип кенә түгел, әсәр, спектакль-тамашага әверелеп, сәхнәдә уйналсын, геройлар үзләре сәхнәдә «яшәсен» дигән максат белән тудыра. Драматургия шуңа күрә, беренче чиратта, театр сәнгатенә хезмәт итә, пьеса сәхнә әсәре дип атала.

Исеменнән аңлашылганча, җыентыкта татар әдәбиятының драматургия тармагы аерып алынды һәм иң беренчеләрдән булган Габдрахман Ильяси, Фатих Халидиләрдән, ягъни XIX гасырның икенче яртысыннан башлап, бүгенге көнгә кадәр булган чорда иҗат итүче драматурглар турында мәгълүматлар тупланды. Бу китап сүзлек, энциклопедияләр стилендә төзелде: драматургларның тормыш юлын яктыртканда иң әһәмиятле даталарга гына тукталынды һәм, профессиональ драматурглар, ягъни иҗатларын нигездә драматургиягә багышлаган әдипләр белән генә чикләнмичә, пьесалары театр сәхнәләрендә куелган, театр репертуарларын баеткан язучыларга, авторларга да урын бирелде.

Татар драматургиясенең байлыгын мөмкин кадәр тулы итеп күрсәтү төп максат итеп куелды, пьесаларның сәнгатьчә эшләнешенә анализ ясаудан бигрәк, әсәрләрнең драматургия һәм театрлар тарихында тоткан урынына игътибар ителде. Җыентык-белешмә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының директоры Шамил Зиннур улы Закиров һәм баш режиссеры Фәрит Рәфкать улы Бикчәнтәев тәкъдиме белән татар театрының 100 еллык юбилее уңаеннан төзелде.

Белешмәнең 19 йөз ахыры — 20 йөз башы 20–30 нчы еллар драматурглары өлеше Р.Ә.Яруллина, 1940–2006 еллар драматурглары А.М.Саттарова, Ф.Ә.Ганиева тарафыннан язылдылар.

Җыентыкны нинди принциплардан чыгып төзедек, авторларны сайлап алганда, төркемләп караганда кайсы якларга игътибар иттек? Бүлекләргә бүлү яки хронологияне саклау максатын куймадык, авторлар, күп очракларда кабул ителгәнчә, алфавит тәртибендә урнаштырылды, бу принцип җыентыктан файдаланганда уңышлырак булыр дип табылды. Шулай да иҗатларының драматургиядәге һәм гомумән татар әдәбиятындагы урынын билгеләгәндә, авторлар табигый рәвештә берничә төркемгә аерылалар.

Беренче төр язучылар, профессиональ драматурглар буларак, әдәбият тарихында драматургиянең төп үсеш юлын билгелиләр: Г.Камал, Г.Коләхмәтов, К.Тинчурин, М.Фәйзи, Т.Гыйззәт, Р.Ишморат, Ю.Әминов, Х.Вахит, Ш.Хөсәенов, Т.Миңнуллин, Р.Хәмид, М.Гыйләҗев һ.б.

Татар драматургиясенең байлыгы, сәнгатьчә-эстетик төрлелеге беренче чиратта прозаик яки шагыйрь булган язучыларның сәхнә әсәрләре белән дә бәйле. Бу әдипләр дә драматургиядә бик матур традицияләр тудырдылар, классик дәрәҗәдәге пьесалар иҗат иттеләр: Г.Исхакый, М.Гафури, С.Рәмиев, Ш.Камал, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов, М.Галәү, Ф.Бурнаш, Һ.Такташ, Н.Исәнбәт, Н.Фәттах, А.Гыйләҗев, И.Юзеев, Ф.Яруллин, Р.Батулла, З.Хәким, Д.Вәлиев, Ә.Гаффар, М.Маликова, Р.Зәйдулла, Ф.Бәйрәмова, Ф.Садриев, Х.Ибраһим, Р.Мингалим, Л.Лерон һ.б. Җыентыкта алар иҗатының драматургия өлеше алгы планга чыгарып яктыртылды, шул яктан бәяләнде. Басылган әсәрләре, алар турындагы мәкаләләрнең дә күбесенчә сәхнә әсәренә караганнары гына саналды.

Бүгенге драматургиядә төп һөнәри эшчәнлекләре театр белән бәйле булган режиссер, актер, әдәби бүлекне җитәкләүче талантлы шәхесләр дә иҗат итә (аларның кайберләре профессиональ драматургия өлкәсенә күчеп бара). Мондый иҗат — татар драматургиясенең матур бер традициясе һәм ул уңышлы дәвам итә. Театрның бүгенге хәлен, бүгенге тамашачыны, сәхнә законнарын белеп иҗат итүче бу төр язучыларга да зур игътибар бирдек: Г.Каюмов, Ю.Сафиуллин, Р.Җиһаншина, Х.Җәләлов, Аманулла, Ш.Фәхретдинов, И.Мәхмүтова, Ф.Галиев, Э.Яһудин һ.б.

Г.Камал, К.Тинчурин исемендәге театрларның репертуарын өйрәнүдән тыш, балалар әдәбиятының әһәмиятле бер өлеше булган сәхнә әсәрләре — Курчак театры өчен махсус язылган пьесалар, аларның авторлары да лаеклы урыннарын алды. Мәгълүм булганча, балалар әдәбияты әхлак һәм эстетик зәвык тәрбияли, шул исәптән Курчак театрлары да Академия театрларына киләчәк тамашачыларны әзерли. Талантлы язылган һәр пьеса Курчак театры сәхнәсендә энҗе бөртегенә әверелә. Татар дәүләт курчак театры репертуарын Н.Исәнбәт, Н.Фәттах, Р.Батулла, Т.Миңнуллин, М.Гыйләҗев, Р.Корбан, һ.б. пьесалары баетып тора.

Җыентыкны төзүчеләр эчтәлеге һәм структурасы ягыннан әһәмиятле шактый бай чыганаклардан, фәнни хезмәтләрдән файдаландылар:

Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. Төзүче-авторлар: Даутов Р. , Нуруллина Н. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 639 б.

Даутов Р. Балачак әдипләре: Биобиблиографик белешмәлек. Беренче китап. — Казан: Мәгариф. — 2003. — 224 б.

Даутов Р. Балачак әдипләре: Биобиблиографик белешмәлек. Икенче китап. — Казан: Мәгариф. — 2004. — 286 б.

Даутов Р.Н., Гамбәров Н.Г. Балачак әдипләре: Биобиблиографик белешмәлек. Өченче китап. — Казан: Мәгариф. — 2005. — 334 б.

Репертуар Татарского академического театра имени Г.Камала: 1906–1996 гг. Составитель: И.Илялова. — Казань: Тат. газетно-журн. издат., 1996. — 46 с.

Игламов Р.М. Искусство играющих кукол. — Казань: Тат. книжн. издат., 2004. — 231 с.

Яңа татар пьесасы: Альманах. Өч кисәк: Идел-пресс, беренче кисәк — 2004. — 435 б.; икенче кисәк — 2004. — 438 б.; өченче кисәк — 2005. — 432 б.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең системалы һәм алфавит каталоглары.

Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан төзелгән Татар әдәбияты тарихы. 6 томда.

Мәкаләләр әдипнең тормыш юлы, иҗаты турындагы мәгълүматлардан һәм басылган драма әсәрләре турындагы хезмәтләр исемлегеннән тора.

Әдәбиятның һәм театр сәнгатенең гасырга якын үсешен чагылдырган бу җыентыкның киләчәктә дәвамы булыр, ул тагын да тулыландырылыр дип ышанырга кирәк.

***Флера Ганиева,***
*филология фәннәре кандидаты, профессор*

# АБДУЛЛА
# АЛИШ
# (1908–1944)

Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) 1908 елның 15 сентябрендә Спас районы Көек авылында зыялы нәсел — күп буыннардан килгән дин әһелләре, руханилар нәселендә көтеп алган малай булып дөньяга килә. Бабасы Нурулла Бохарада укып кайткач, Көеккә килеп төпләнә һәм авыл мулласы булып гомер сөрә. Әтисе Габделбари исә, нигездә, хуҗалык эшләре белән шөгыльләнә — иген игә, умарта тота. Заманасы өчен укымышлы һәм алдынгы карашлы бу гаиләнең, балаларын белемле, тәрбияле үстерү максатыннан, төрле газета һәм журналлар алдыруы да мәгълүм. Абдулланың әнисе Газизә дә укымышлы хатын була, шигырь һәм бәетләр чыгара.

Абдулла алты-җиде яшендә әтисеннән укырга-язарга өйрәнә, аннары авылдагы башлангыч мәктәптә укый башлый. 1917–1919 елларда күрше Ямбакты авылы мәдрәсәсендә, 1919–1921 еллар арасында Бураково авылы мәктәбендә белем ала. Аннан соң Спас педагогия техникумы каршындагы җидееллык рус мәктәбен тәмамлый. Уку елларында төрле кичә һәм бәйрәмнәрдә, драмтүгәрәкләрдә актив катнаша, стена газетасы һәм кулъязма журналлар чыгаруда башлап йөри, үзе дә шигырьләр, хикәяләр яза.

1927 елның җәендә А.Алиш Казанга килә һәм 1927–1930 елларда Казан җир төзү техникумында белем ала. Биредә уку чорында әдәбият белән кызыксынуы тагы да арта. «Кызыл яшьләр», «Яшь ленинчы», «Яңа белгеч» һ.б. матбугат органнарында төрле жанрдагы әсәрләре белән чыгыш ясый.

А.Алиш 1933–1934 елларда Казандагы Үзәк пионерлар клубында эшли, соңрак «Техника» журналының җаваплы сәркатибе, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналы редакциясе каршында оештырылган әдәби түгәрәк җитәкчесе вазифаларын башкара. Татарстан радиокомитетында да эшләп ала. 1937 елдан ул — Казан дәүләт педагогия институтының кичке бүлеге студенты да.

Бу еллар — язучының иң актив иҗат иткән чоры. А.Алиш татар балалар драматургиясен үстерү юнәлешендә «Йолдыз» (1935, А.Әхмәт белән берлектә), «Кечкенә тоткын» исемле пьесалар яза. Шулай ук өлкәннәр өчен «Күршеләр» (1934, А.Әхмәт белән берлектә) пьесасы дөнья күрә.

Утызынчы елларда А.Алишның «Отряд флагы» (1931), «Якты күл буе» (1933), «Дулкыннар» (1934), «Ант» (1935) кебек җыентыклары, күп сандагы әкиятләре басыла. Зурлар өчен дә нәтиҗәле эшли: «Яшь килен» (1931), «Тиздән туй» (1939) хикәяләрен һәм «Якты күл буе» исемле повестен иҗат итә.

1941 елның июль аенда, Ватан сугышы башлангач, язучы фронтка китә, радист һөнәрен үзләштерә. 1941 елның 12 октябрендә Брянск шәһәре янында, Десна елгасы буенда чолганышта калып, фашистларга әсир төшә. Соңыннан ул Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән очраша, алар белән берлектә фашистларга каршы яшерен оешма эшендә катнаша.

1943 елда яшерен оешма эше ачыла, җәлилчеләр, шул исәптән А.Алиш та кулга алына һәм 1944 елның 25 августында 12 сәгать 12 минутта А.Алишның башы киселә.

Абдулла Алиш иҗаты татар әдәбияты тарихында мактаулы урын тота. 1965 елдан Казанның балалар иҗат үзәге аның исемен йөртә, 1968 елдан 55 мәктәптә әдипкә багышланган бай музей эшләп килә. 1966 елда Спас районы Көек авылында А.Алиш музее ачыла һәм шушы ук елда әдип исемендәге бүләк булдырыла.

А.Алиш — татар балалар әдәбиятын үстерү юнәлешендә зур көч куйган һәм төрле жанрларда иҗат иткән әдип.

Ул 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**


**Алиш А.** Күршеләр: Пьеса 4 пәрдәдә. — Казан: Татгосиздат, 1934. — 57 б.
**Алиш А.** Йолдыз: Балалар өчен 4 пәрдәлек пьеса. — Казан: Татгосиздат, 1935. — 27 б.
**Алиш А**. Кечкенә тоткын: Өч пәрдәлек пьеса. — Казан: Татгосиздат, 1941. — 23 б.

**Алиш А.** Сайланма әсәрләр: Әкиятләр, хикәяләр, пьесалар һәм шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1957. — 240 б.

**Алиш А.** Сайланма әсәрләр / Кереш сүз авт. һәм төз. И.Сөнкишева. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1969. — 439 б.

**Аның турында:**

**Шакир С.** Абдулла Алиш: Тормыш һәм иҗат юлы турында очерк. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1970. — 119 б.

**Сөнкишева И.** Ул безнең арада: Очерк. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. — 95 б.

**Хәйри Х.** Балалар әдәбияты остасы / Хәйри Х. Иҗат чишмәләре. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1975. — 128–132 б.

**Мостафин Р., Солтанбәков Б.** Муса Җәлил һәм А.Алиш шик астында // Татарстан. — 1994. — № 7/8. — 41–47 б.

**Сөнкишева И.** Иманга тугрылык // Мирас. — 1995. — № 5–6. — 193–199 б.

А.Алишның тууына 90 ел: А.Алиш турында Х.Гыйльметдинов, Ә.Бикчәнтәева, Г.Латыйп истәлекләре // Казан утлары. — 1998. — № 10. — 177–181 б.

**Минһаҗева Л.** А.Алиш (1908–1944) // Татар әдәбияты мәсьәләләре. 10 җыентык. — Казан: КДПУ нәшр., 2003. — 53–62 б.

## АМАНУЛЛА
## (ӘМИР КАМАЛИЕВ)
## (1960)

Әмир Аман улы Камалиев 1960 елның 29 маенда Татарстанның Апас районы Шыгай авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне туган авылында алганнан соң, сигезьеллык мәктәпне күрше Сатламыш авылында тәмамлый. Мәктәп елларында әдәбият түгәрәгенә йөргәндә үк ул шигырьләр, хикәяләр яза башлый. Беренче иҗат тәҗрибәсе — дүртьюллык бер шигыре — «Яшь ленинчы» газетасында нәшер ителә.

1975 елда әдип Казан моторлар төзү заводы каршындагы 15 нче профтехучилищега укырга керә. Токарь һөнәрен үзләштереп, Казан моторлар төзү заводында эшли башлый.

1980–1982 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәннән соң, яңадан заводка эшкә кайта. Армиядән соң Әмир Камалиевны театр дөньясы җәлеп итә һәм ул, үзешчән түгәрәкләргә йөреп, төрле спектакльләрдә актер буларак көчен сыный. Яшь талантны Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының режиссеры Празат Исәнбәт белән театрның артисткасы Рәшидә Җиһаншина күреп алып, аңа театр училищесында укырга киңәш итәләр.

1984 елда ул Мәскәүдәге М.С.Щепкин исемендәге театр училищесына укырга керә. Уку дәверендә аның пьесалар язу теләге уяна. Драматургия өлкәсендәге беренче адымнары шул еллардан башлана. 1988 елда Казанга кайтып, Ә.Камалиев Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актер булып эшли башлый. Аңа сәхнәдә тәҗрибәле артистлар белән аралашу, профессиональ югарылыктагы спектакльләрдә катнашу драматургия законнарын өйрәнүдә зур этәргеч була. 1992 елда Әмир Камалиевның «Аманулла» тәхәллүсе астында «Җәйге кырау» пьесасы Чаллы татар дәүләт драма театрында куела. Әлеге әсәр тәнкыйтьчеләрнең һәм галимнәрнең игътибарын нык җәлеп итә. Алга таба Әмир Камалиевның һәр әсәре «Аманулла» тәхәллүсе исеме белән дөнья күрә. Бер-бер артлы иҗат ителгән пьесалары Татарстан һәм Башкортстан театр сәхнәләрендә куела башлый. «Әлепле әртисләре» (1993) комедиясе, тормышка пародия буларак, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, Әлмәт татар дәүләт драма театры, Уфа «Нур» татар дәүләт драма театры, Туймазы татар дәүләт драма театры, Буа сатира театры сәхнәләрендә яңгырады. Аманулланың комедия жанрында язылган әсәрләрендә милли, иҗтимагый, мәдәни һ.б. проблемалар күтәрелә. Драматургның 1993 елда «Итәкле кияү», 1994 елда — «Борын-борын заманда», 1995 елда — «Кыйбла кая?» («Җанлы кеше»)һәм 1996 елда «Кылый Кирам балдагы» комедияләре язылды һәм театрларыбыз сәхнәләрендә уйналды. Аманулла уен категориясе аша җәмгыятьтәге җитешсезлекләрне күрсәтә.

1998 елда Аманулланың психологизм белән сугарылган «Әле кичә генә яз иде» лирик драмасы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелды.

Ул балалар драматургиясен үстерүдә дә зур өлеш кертә. Балалар һәм яшүсмерләр өчен кызыклы, мавыктыргыч һәм гыйбрәтле сәхнә әсәрләре арасында — «Яңа ел әкияте» (1996), «Хөррият кошы» (1997), «Энҗебикә — кар кызы» (1998) әкиятләре бар.

Драматургның балаларның серле дөньясын аңлап иҗат иткән «Мактанчык Әтәч» (1996) әкиятен Әлмәт татар дәүләт драма театры, Казан дәүләт курчак театры, Оренбург татар дәүләт драма театры сәхнәләрендә яшь тамашачылар яратып кабул иттеләр. Драматургның Казан дәүләт яшь тамашачылар (ТЮЗ) һ.б. театрларда сәхнәләштерелгән «Моңлы ядкәр» (2000) лирик драмасы, «Юлларда бозлавык» (2000) драмасы, «Әбиләр чуагы» (2003) лирик драмасы, «Бер кирпеч, ике кирпеч» (2004) комедиясе, «Имән читлек» (2004) драмасы, «Без кайтырбыз, әнкәем!» (2005) драмасы яшь буынга тәрбия бирү өлкәсендә зур роль уйныйлар.

Аманулла «Күзләрем Киек Каз Юлында...» (2004) либретто авторы буларак та билгеле.

2005 елда Аманулланың «Моңлы ядкәр» исемле пьесалар җыентыгы дөнья күрде.

Ул — 1996 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Аманулла.** Моңлы ядкәр: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 350 б.

**Аманулла.** Бер кирпеч, ике кирпеч: Яңа татар пьесасы 3 томда. — 1 т. — Казан: Идел-пресс, 2004. — 7–46 б.

**Аның турында:**

**Бәдретдинов Х.** Җылы караш // Татарстан яшьләре. — 1989. — 6 июль.

**Хәбибуллина Л.** Сәхнә юанычым // Татарстан хәбәрләре. — 1993. — 26 март.

**Галимуллин Ф.** Ышаныч тудыручы яшьләр // Шәһри Казан. — 1994. — 22 гыйнвар.

**Әхмәдуллин А.** Замана аферистлары // Ватаным Татарстан. — 1997. — 28 февраль.

**Нигматуллина Ю.** «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. — Казань: ФЭН, 2002.

**Саттарова А.** Современная татарская драматургия 1985–2000 гг. (концепция эпохи и героя). — Казань: Gumanitarya, 2003. — С. 97–100.

## ДӘРҖИЯ АППАКОВА (1898–1948)

Дәрҗия Сәйфулла кызы Аппакова 1898 елның 2 мартында Татарстанның Түбән Кама районы Байгол авылында туа. Унөч яшендә Казанга килеп, керәшен татарлары өчен ачылган укытучылар мәктәбендә укый, аны тәмамлагач, берничә ел Казанда һәм туган авылында балалар укыта. 1922–1923 елларда Казан Зур театры каршындагы студиядә махсус белем алып чыккач, берникадәр вакыт хәрби труппада артистка, аннары комсомол өлкә комитетында инструктор булып эшли. 1928–1943 елларда ул Урта Азиядә яши, укытучылык эше белән шөгыльләнә. 1943 елда Казанга әйләнеп кайта, гомеренең соңгы көннәренә кадәр язучылык эшен дәвам итә.

Дәрҗия Аппакова әдәбиятка журналистика аша килеп керә һәм татар балалар әдәбиятына шактый өлеш керткән прозаик һәм драматург булып әверелә. 1932–1940 елларда төрле милләт халыкларының үткәндәге һәм шул чор тормышын чагылдырган хикәя, повесть, романнары басылып чыга. Аеруча «Кечкенә Бануның тарихы» повесте популяр була, ул тиз арада татар, рус, үзбәк һәм инглиз телләрендә басыла, яратып укыла.

1943–1948 елларда Дәрҗия Аппакова төп игътибарын балалар драматургиясенә юнәлтә — «Тапкыр егет» (1943), «Шүрәле» (1944), «Бишек җыры» (1946), «Илдус» (1947) исемле пьесаларын иҗат итә.

1945 елда татар фольклоры мотивларына нигезләнеп язылган «Тапкыр егет» пьесасы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куела. Ул шулай ук, русчага тәрҗемә ителеп, Казанның Яшь тамашачылар театры сәхнәсендә дә уңыш белән бара.

Д.Аппакова 1935 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Аппакова Д.** Тапкыр егет: Пьеса 4 пәрдәдә, 7 картинада / Татар халык әкиятләреннән файдаланып. — Казан: Рем. училище тип., 1846. — 15 б.

**Аппакова Д.** Находчивый юноша. — Казань, 1946. — 16 с.

**Аппакова Д.** Ильдус: Пьеса в 3 д. / Перевод С.Ибрагимовой. — Казань: Татгосиздат, 1952. — 36 с.
**Аппакова Д.** Хикәяләр һәм пьесалар. — Казан: Татгосиздат, 1953. — 120 б.
**Аппакова Д.** Сараның башыннан үткәннәре: Хикәяләр һәм пьеса. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. — 136 б.

**Аның турында:**

**Бакир Г.** Язучы Дәрҗия Аппакова // Социалистик Татарстан. — 1968. — 3 март.
**Гайсин Н.** Дәрҗия Аппакова (1898–1948) // Казан утлары. — 1968. — № 3. — 156 б.
**Галимов Д.** Кыйммәтле мирас // Совет мәктәбе. — 1978. — № 3. — 42–43 б.
**Ихсанова Л.** Дәрҗия Аппакова // Казан утлары. — 1978. — № 3. — 176–177 б.

## ГАРИФ
## АХУНОВ
## (1925–2000)

Гариф Ахунов (Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов) 1925 елның 18 сентябрендә Татарстанның Арча районы Өчиле авылында туа. Күрше Казанбаш авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, 1940 елда Арча педагогия училищесына укырга керә, сугыш башлану сәбәпле, укуын өзеп, колхозда эшли һәм аңа 1946 елда гына яңадан укуын дәвам итәргә мөмкин була. 1947–1952 елларда Г.Ахунов Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Студент елларында ук аны «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналына әдәби хезмәткәр итеп эшкә алалар, биш ел буе ул проза бүлеге мөдире, җаваплы сәркатип вазифаларын башкара.

1956 елның көзендә Гариф Ахунов Әлмәт шәһәренә иҗади командировкага бара, 1957 елда шунда күченеп, ун елдан артык нефтьчеләр арасында яши, иҗат итә, актив җәмәгать эшчәнлеге алып бара — Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеген төзи, аның беренче җитәкчесе була. Ул нефть төбәгендә яшәүче язучыларга иҗат мөмкинлекләрен тудыру, тормыш шартларын яхшыртуга күп көч һәм энергиясен бирә, яшь язучыларны иҗади коллективка туплый, аларны үстерү юлында күп эшләр башкара.

1968 елда ул Татарстан Язучылар оешмасының җаваплы сәркатибе итеп сайлана, Казанга күчеп яши башлый. 1971–1974 елларда «Казан утлары» журналының баш редакторы булып эшли. 1974 елда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең рәисе итеп сайлана һәм бу вазифаны 1984 елның маена кадәр уңышлы башкара.

Гариф Ахунов татар әдәбияты тарихында беренче чиратта проза әсәрләре белән урын алды. Аның «Артышлы тау буенда», «Канатлар кая илтә?», «Чикләвек төше», «Ардуан батыр», «Олы язга сәяхәт», «Без бит Арча яклары», «Йолдызлар калка» кебек повестьлары, «Хәзинә», «Хуҗалар», «Идел кызы» романнары укучыларның һәм әдәби тәнкыйтьнең игътибар үзәгендә булдылар.

Шул ук вакытта Гариф Ахунов драма әсәрләре авторы буларак та билгеле. Төрле елларда Әлмәт, Минзәлә, Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәләрендә аның «Чулпан җыры», «Утлар яна учакта», «Тынгысыз йөрәк» (Ф.Мостафин белән бергә язылган), «Икәүдән-икәү генә» (Р.Ахунов белән берлектә), «Чикләвек төше» пьесалары куела.

«Чикләвек төше», «Ардуан батыр» повестьларын, Ш.Камалның «Акчарлаклар» әсәрен Г.Ахунов үзе сәхнәләштерде һәм бу спектакльләр үз вакытында уңыш казандылар.

Әдәбиятны үстерүдәге хезмәтләре өчен Г.Ахунов Хезмәт Кызыл Байрагы (1975), Халыклар Дуслыгы (1984) орденнары белән бүләкләнде, аңа «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» (1972) дигән мактаулы исем бирелде. Ул — Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт, Г.Исхакый исемендәге әдәбият бүләкләре лауреаты.

Г.Ахунов 1957 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Ахунов Г.** Әсәрләр 4 томда. — 4 т.: Пьесалар. Әдәби портретлар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. — 488 б.
**Ахунов Г.** Утлар яна учакта: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. — 192 б.

**Аның драма әсәрләре турында:**

**Гыйләҗев А.** Күпне күрәбез // Казан утлары. — 1975. — № 9. — 62–65 б.
**Гыймранова Д.** Проза геройлары сәхнәгә менә // Социалистик Татарстан. — 1981. — 9 август.

## МӨХӘММӘТ ӘБЛИЕВ (1900–1941)

Мөхәммәт Шәриф улы Әблиев 1900 елның 15 июлендә Кама Тамагы районының Даныш авылында ярлы крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Мәдрәсәдә уку белән бергә, бик яшьли, тамак туйдыру өчен, байларга хезмәт итә башлый. 1915 елда Казанга килеп төрле эшләрдә ялланып көн күрә. 1918 елда азык-төлек отрядына язылa. Туку фабрикасында эшли. 1920–1921 елларда партия мәктәбендә укый һәм, аны тәмамлагач, эшчеләр арасында тәрбияче була.

1921 елда М.Әблиев үз теләге белән Кызыл Армия сафларына китә, 1922 елда Урта Азиядә басмачылар дип яманаты таралган хәрәкәтне юк итүдә катнаша. Шул чордан башлап аның тормышы армия хезмәте белән бәйле.

1923–1926 елларда М.Әблиев Казандагы берләштерелгән татар-башкорт мәктәбен, 1927–1928 елларда Мәскәүдә хәрби-сәяси курсларны тәмамлый. Шуннан соң Төркестан укчы полкына рота политругы итеп җибәрелә, соңга таба ул анда рота командиры булып хезмәт итә.

1932–1936 елларда Ленинградтагы хәрби-сәяси академиядә белем ала. Финнар белән сугыш башлангач, хәрби комиссар М.Әблиев көрәшнең алгы сызыгында була. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк ул укчы дивизиянең сәяси бүлек начальнигы сыйфатында утка керә һәм авыр бәрелешләрнең берсендә батырларча һәлак була.

М.Әблиев егерменче елларда яза башлый. Башта ул проза жанрында үзен сыный — «Минем дустым сугышта» исемле хикәя, «Ком улы», «Итекче кызы» повестьларын яза.

Соңга таба игътибарын драматургия төренә юнәлтә. 1923–1925 елларда ул «Ике туй» исемле пьеса яза. Мөхәммәт Әблиев татар әдәбияты тарихына иң беренче чиратта «Шәмсекамәр» (1929) драмасы белән керә. Пьеса өстендә эшләгәндә, яшь язучыга тәҗрибәле драматург Кәрим Тинчурин булышлык күрсәтә һәм бу иҗади дуслыкның нәтиҗәләре бик уңышлы булып чыга. Драмада Октябрь революциясенә кадәрге татар авылында барган вакыйгалар оста итеп, җанлы картиналарда тасвирлана.

«Шәмсекамәр» спектакле 1937–1938 елгы театр сезонында Татар дәүләт академия театрында зур уңыш казана, озак еллар буе репертуардан төшми уйнала. Пьеса күп кенә татар, башкорт һәм сугыштан соңгы елларда Үзбәк академия театры сәхнәсендә куела.

М.Әблиев 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

### Басылган драма әсәрләре:

**Әблиев М.** Шәмсекамәр: Драма 4 пәрдәдә. — Казан: Татгосиздат. — 1939. — 70 б.
**Аблиев М.** Шамсикамар: Драма в 4 д. (Перевод с татар. М.Н.Елизаровой и З.Дибердеевой). — Казань: Татгосиздат, 1940. — С. 80.

### Аның турында:

**Гыйниятуллина А.** Язучы, коммунист, комиссар // Социалистик Татарстан. — 1968. — 18 февраль.
**Хәбибуллин М.** Якты шәхес // Социалистик Татарстан. — 1982. — 5 август.
**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 578–579 б.
Мөхәммәт Әблиевнең тууына 100 ел // Казан утлары. — 2000. — № 8. — 189 б.

## ЮНЫС ӘМИНОВ (1921–1982)

Юныс Шәрип улы Әминов 1921 елның 1 декабрендә Татарстанның Әгерҗе районы Салагыш авылында туа. 1936–1939 елларда Минзәлә педагогия училищесында укый, аны тәмамлагач, Актаныш районында балалар укыта. 1940 елда Армиягә алына, 1942 елга кадәр хәрби мәктәптә укый, аннары взвод командиры сыйфатында Дон фронтына җибәрелә. Яралы һәм контузияле хәлендә фашистлар кулына эләгә, Румыниядәге хәрби әсирләр лагеренда тоткынлыкта була. Азат ителгәч, яңадан алгы сызыкка әйләнеп кайта, Будапешт, Братислава шәһәрләрен азат итүдә катнаша.

Армиядән кайткач, озак еллар Әгерҗе районында балалар укыта, 1949–1953 елларда, эшеннән аерылмыйча, Алабуга укытучылар институтының рус теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый.

1959–1961 елларда Юныс Әминов Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда укый. 1969 елда гаиләсе белән Әлмәт шәһәренә күчә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда яшәп иҗат итә.

Илленче еллардан башлап Юныс Әминов әдәби иҗат эше белән даими шөгыльләнә башлый. Аның 1955 елны язып тәмамлаган «Язылмаган законнар» исемле беренче күләмле әсәре үк әдәбият мәйданына сәләтле драматург килгәнлеген раслый. Минзәлә театры коллективы тарафыннан сәхнәгә куелган бу спектакль 1957 елда Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында Мәскәү тамашачыларына да күрсәтелә.

1950–1970 еллар — Юныс Әминовның актив һәм нәтиҗәле иҗат чоры. «Гөлчәчәк» (1956), «Тамырлар» (1961), «Өти балак» (1964), «Гөлҗәннәтнең җәннәте» (1966), «Уҗым бозавы» (1966), «Минем җинаятем» (1968), «Умырзаая чәчәкләре» (1959) пьесалары буенча куелган спектакльләр Татарстанның Минзәлә, Әлмәт, Республика күчмә театрлары һәм Башкортстан театрлары сәхнәләрендә зур уңыш белән бара.

Аның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Умырзаая чәчәкләре» драмасы (1960), «Гөлҗәннәтнең җәннәте» (1969), «Кан кардәшләр» (1974) комедияләре куела.

Әлмәт чоры әдипнең драматургиясен яңа темалар, геройлар белән баета: әсәрләренә яшь шәһәр тормышы, нефтьчеләр, завод эшчеләре образлары килеп керә. «Кан кардәшләр» (1972), «Сафура бураннары» (1975), «Сөймим дисәң дә...» (1976), «Очрашырбыз, Гөлсылу!» (1980) комедия һәм драмалары әдәби әсәрләр буларак татар драматургиясе үсешен билгеләүче әсәрләр рәтендә торалар һәм театр сәнгатенең яшәешенә дә нәтиҗәле хезмәт итәләр.

Утыз еллык иҗат гомерендә ике дистәдән артык сәхнә әсәрләре иҗат иткән, тамашачыларда югары әхлак һәм гражданлык сыйфатлары тәрбияләгән Юныс Әминовка 1972 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Ул 1958 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**


**Әминов Ю.** Бер пәрдәлек пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. — 80 б.

**Әминов Ю.** Язылмаган законнар: Драма 4 пәрдәдә. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 100 б.

**Әминов Ю.** Тамырлар: Сатирик комедия. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1962. — 95 б.

**Әминов Ю.** Гөлчәчәк: Пьеса 4 пәрдәдә. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1964. — 76 б.

**Әминов Ю.** Кошның үз канаты була: Өч пәрдәле музыкаль комедия. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1968. — 91 б.

**Әминов Ю.** Өти балак: Комедия // Казан утлары. — 1969. — № 3. — 67–111 б.

**Әминов Ю.** Дүрт пьеса. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1970. — 256 б.

**Әминов Ю. Г**өлҗәннәтнең җәннәте: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1973. — 262 б.

**Әминов Ю.** Сафура бураннары: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. — 224 б.

**Әминов Ю.** Драмалар, комедияләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. — 384 б.

**Әминов Ю.** Очрашырбыз, Гөлсылу!: Сәхнә әсәрләре. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. — 168 б.

**Әминов Ю.** Үлемнең үлеме: Моңсу комедия // Мирас. — 2003. — № 3. — 48–63 б.


**Аның турында:**


**Нуруллин И.** Кече жанр — зур эчтәлек: Ю.Әминовның «Бер пәрдәлек пьесалар» исемле җыентыгына күзәтү // Нуруллин И. Образлар дөньясында. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1964. — 41–58 б.

**Мөсәгыйть Ф.** Сәхнәдә яңа әсәр: «Өти балак» пьесасы // Социалистик Татарстан. — 1965. — 19 декабрь.

**Гыймранова Д.** Сәхнәдә — кешеләр язмышы: «Умырзаая чәчәкләре» пьесасы // Социалистик Татарстан. — 1969. — 6 июль.

**Гыйләҗев А.** Ак нур белән // Казан утлары. — 1971. — № 12. — 130–134 б.
**Миңнуллин Т.** Кеше күңеле // Ялкын. — 1971. — № 12. — 19 б.
**Ханзафаров Н.** Мещанлык бәхетенә каршы // Казан утлары. — 1972. — № 9. — 162–165 б.
**Афзал Г.** Минем җәннәтем // Социалистик Татарстан. — 1973. — 6 май.
**Илялова И.** Кан кардәшләр // Социалистик Татарстан. — 1975. — 19 гыйнвар.
**Мәхмүтов Һ.** Тормыш дөреслегенә омтылып: Ю.Әминовка — 60 яшь // Социалистик Татарстан. — 1981. — 1 декабрь.
**Әхмәдуллин А.** Кешелекле иҗат // Казан утлары. — 1981. — № 12. — 159–162 б.
**Вәлиев М.** Авыл кешесенең матурлыгы // Казан утлары. — 1982. — № 12. — 154–156 б.
**Әхмәдуллин А.** Мин кешеләрне яхшы итеп кенә күрәм // Социалистик Татарстан. — 1991. — 30 ноябрь.
**Ахунов Г.** Салагыш егетенең даны // Ватаным Татарстан. — 1993. — 24 март.
**Вәли-Барҗылы М.** Бергәлек бәхете: Драматург Ю.Әминовның тууына 80 ел // Казан утлары. — 2001. — № 11. — 172–175 б.
**Вәлиев Н., Салихов Р.** Юныс Әминов. — Әдәби Алабуга. — Алабуга: АДПУ, 2005. — 27–33 б.

## МИРСӘЙ ӘМИР (1907–1980)

Мирсәй Әмир (Мирсәяф Мәсәлим улы Әмиров) 1907 елның 6 февралендә Башкортстанның Мәләүез районы Җиргән авылында туа. Әти-әнисеннән яшьли ятим калып, туганнары гаиләсендә, балалар йортында һәм Эстәрлетамак шәһәрендәге җидееллык үрнәк-тәҗрибә мәктәбе интернатында тәрбияләнә.

1926 елда Мирсәй Әмир Казанга килә һәм сәнгать техникумына укырга керә. Шул елда «Авыл яшьләре» журналында аның хикәяләре басыла башлый. Ике курсны тәмамлаганнан соң, ул бу журнал редакциясендә җаваплы сәркатип булып эшли башлый, күп кенә хикәяләре дөнья күрә.

1929–1931 елларда М.Әмир Кызыл Армия сафларында хезмәт итә, «Кызыллармеец» исемле хәрби газетада эшли, юмористик хикәяләрен һәм «Хикмәтулланың маневрда күргәннәре» повестен яза. Армиядән кайткач, «Чаян» сатирик журналында әдәби хезмәткәр, аннары Татарстан дәүләт нәшриятының матур әдәбият бүлегендә редактор булып эшли.

Мирсәй Әмирне татар әдәбиятының классигы итеп таныткан «Агыйдел» повесте 1935 елда языла. Табигатьнең, кеше күңеленең гүзәллеген чын художник буларак тасвирлаган, гади дә, гадәттән тыш та булган язмышларны сурәтләгән бу әсәрен 1970 елларда ул пьеса итеп эшли һәм шул пьесасы буенча Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган спектакль өчен Мирсәй Әмир 1974 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Проза өлкәсендә Мирсәй Әмир «Ялантау кешеләре», «Саф күңел» роман-дилогиясе (1953, 1959), «Җан көеге» (1969), «Балыкчы ялганнары» (1971) повестьлары һәм «Без бәләкәй чакларда», «Үсә төшкәч», «Казан» дигән кисәкләрдән торган автобиографик әсәрләре белән танылды.

Драматургия Мирсәй Әмирне утызынчы елларда ук кызыксындыра, ул «Җәдәч», «Көнлекче Әхмәт һәм аның матур хатыны», «Тун ачуы» исемле комедияләрен яза, тормышның кызыклы якларын, кеше характерындагы көлкеле сыйфатларны тасвирлый. Сугыш чорының хәлиткеч драматизмын, кеше рухының көчен һәм матурлыгын чагылдырган иң күренекле драма әсәрләренә алып киләчәк сукмак салына.

Татар әдәбиятының чор геройларын иҗат итү традициясен дәвам итеп, Мирсәй Әмир Миңлекамал («Миңлекамал» драмасы, 1944), Фатыйма («Тормыш җыры» драмасы, 1946) образларын сәхнәгә күтәрә. Бу әсәрләр буенча куелган спектакльләр үз чорында ук гаять популяр булалар, иң талантлы актерлар репертуарында бу героинялар күренекле урын алалар. «Миңлекамал», «Тормыш җыры» драмалары татар театры сәхнәләреннән төшми уйнала. Соңрак драматург «Җыр дәвам итә» (1947), «Наилә» (1947), «Минем хатын» (1955), «Хөррият» (1960) комедия һәм драмаларын яза. Бу әсәрләре дә татар драматургиясе үсешенә, татар театрларының репертуарларын баетуга лаеклы өлеш кертәләр. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында гына да Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал» (1944, 1957, 1984), «Тормыш җыры» (1947, 1958, 1965), «Җыр дәвам итә» (1948), «Хөррият» (1960), «Агыйдел» (1973) драмалары, «Минем хатын» (1955) комедиясе куела.

Иҗтимагый тормыш һәм әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Мирсәй Әмир орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә, «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек була. Алтмышынчы еллар башында ул Татарстан Язучылар оешмасына җитәкчелек итә.

Ул 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Әмир М.** Сайланма әсәрләр: Хикәяләр һәм пьесалар. — Казан: Татгосиздат, 1941. — 287 б. (Мәкт. сериясе.)

**Әмир М.** Партизан Иван: Пьеса 4 пәрдәдә, 6 картинада / Партизаннар тормышыннан. — Казан: Татгосиздат, 1942. — 94 б.

**Амир М.** Песня жизни: Драма в 4 д. (Пер. с татарского А.Глебова. Муз. Дж. Файзи. Послесл. Г.Кашшафа). — М.-Л.: Искусство, 1949. — С. 120.

**Әмир М.** Кысыр хәсрәт: Комедияләр һәм сатирик хикәяләр. — Казан: Татгосиздат, 1954. — 120 б.

**Әмир М.** Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1956. — 418 б.

**Амир М.** Минникамал: Пьеса в 4 д., 8 карт. (Авториз. пер. П.Градова). — Казань: Таткнигоиздат, 1957. — С. 96.

**Амир М.** Моя жена: Комедия в 3 д. (Авториз. пер. П.Градова). — М.: Искусство, 1957. — С. 72.

**Әмир М.** Өч пьеса. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1962. — 199 б.

**Әмир М.** Сайланма әсәрләр 3 томда. — 2 т. Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1967. — 529 б.

**Әмир М.** Миңлекамал: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. — 220 б.

**Аның драма әсәрләре турында:**

**Кашшаф Г.** Тормыш җыры / Кашшаф Г. Күңел көзгесе: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. — Казан, 1975. — 21–25 б.

**Кашшаф Г.** Хөррият / Кашшаф Г. Күңел көзгесе: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. — Казан, 1975. — 75–81 б.

**Мусин Ф.** Гражданин и художник: К 70-летию М.Амира. — Сов. Татария, 1974. — 3 марта.

**Әхмәдуллин А.** Әсәрләрендә чынбарлык рухы // Әхмәдуллин А. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. — Казан, 1980. — 228–235 б.

## КӘРИМ ӘМИРИ (1893–1962)

Кәрим Әмири (Кәрим Хөсәен улы Әмиров) 1893 елда Башкортстанның Тәтешле районы Бүл-Кайпан авылында туа. Мәдрәсәдә укыганнан соң, ул Уфа һәм Пенза губерналарындагы авылларда балалар укыта. 1918 елда Казанга килеп, укытучылык эшен дәвам иттерә, бер үк вакытта матбугат органнарында («Эш», «Кызыл Армия», «Татарстан» газеталарында) эшли.

1929–1932 елларда Урал һәм Кузбасста эшчеләр өчен нәшер ителүче газеталарда хезмәт итә.

К.Әмири әдәбият мәйданында 1913 елдан күренә башлый. Беренче шигыре шул елларда Оренбургта чыгып килүче «Шура» журналында басыла. 1919 елда аерым китабы дөнья күрә. Шул еллардан башлап К.Әмиринең шигырьләре, поэмалары, хикәяләре һәм драма әсәрләре басыла башлый.

Яшь драматург К.Әмиринең болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәренең сюжетына нигезләнеп язылган «Йосыф белән Зөләйха» трагедиясе 1922 елда Татар дәүләт театры сәхнәсендә уйнала һәм театр тәнкыйтьчеләре тарафыннан уңай бәяләнә. Үз чорының тискәре күренешләрен фаш иткән «Печән базары» (1925), «Казан кызы» (1925) һәм 1905 елгы революцион көрәшне сурәтләгән «Пайтәхет җәлладлары» (1925) пьесалары да 1925–1928 елларда театр сәхнәләрендә күп тапкырлар куела. К.Әмиринең тагын «Таң вакыты» һәм авылларда күмәкләшү елларын тасвирлаган «Зәңгәр күл» исемле пьесалары бар.

К.Әмири 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Әмири К.** Пьесалар: Автобиогр. белешмәсе белән. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1958. — 218 б.

**Әмири К.** Сайланма әсәрләр: Шигырьләр, хикәяләр, пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1969. — 208 б.

**Аның турында:**

**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 592–593 б.
**Бадыйкшин Л.** Аның исеме онытылмасын!: Шагыйрь К.Әмиригә — 100 ел // Шәһри Казан. — 2003. — 21 ноябрь.

## КӘШШАФ ӘМИРОВ (1922–1996)

Кәшшаф Сафиулла улы Әмиров 1922 елның 7 апрелендә Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка районы Яңа Зимница авылында туа; үсмер чагы, мәктәп еллары Үзбәкстанда уза. Сугыш алдыннан Бохара укытучылар институтында укый. 1940–1945 елларда Үзбәкстан мәктәпләрендә укытучы булып эшли.

Ташкентта юридик курсларны тәмамлагач, Таҗикстанда тикшерү органнарында хезмәт итә, төрле җитәкче эшләрдә эшли.

1960 елда Кәшшаф Әмиров Татарстанга кайта, Азнакай Мәдәният йортында үзешчән сәнгать коллективын җитәкли, соңрак Лениногорск шәһәренә күчә, шунда төпләнеп кала һәм җитәкче урыннарда эшли.

Кәшшаф Әмиров — дистәдән артык сәхнә әсәре авторы. Аларның барысы да диярлек профессиональ театр һәм халык театрлары сәхнәләрендә уйналалар. Нефтьчеләргә багышланган «Шөгер моңнары», милиция хезмәткәрләренең тормышын яктырткан «Хөкем алдыннан» пьесалары Республика татар драма һәм комедия театры сәхнәсендә уңыш белән бара. Драматургның «Гаделлек җиңә», «Вөҗдан әмере», «Упкын», «Кодалар», «Туй алдыннан» кебек пьесалары Татарстан театрларында гына түгел, Үзбәкстан һәм Оренбург халык театрларында да куела. Авторның «Зөлфия» пьесасы аеруча уңыш казана — ул илдәге иллеләп театрның репертуарына кертелә. Әфган һәм совет халыклары арасындагы мөнәсәбәтләрне заманча яктырткан бу әсәр, рус теленә тәрҗемә ителеп, «Театр» журналында да басылып чыга (1983, № 5). Бу пьеса 1983 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала һәм матбугатта уңай бәя ала.

К.Әмиров 1985 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Аның турында:**

**Амиров К.** История пишется сегодня: Спектакль «Зульфия» на сцене Татарского академ. театра им.Г.Камала // Веч. Казань, 1984, 3 янв. Интервью с автором пьесы вела Т.Лескова.
**Валеев Р.** Зульфия — сестра Фазили: Спектакль «Зульфия» на сцене Альметьевского драм. театра // Сов. культура. — 1983, 26 апр. — С. 5.
**Хачатуров К.** Солнце должно светить всем людям. — Театр. — 1983. — № 5. — С. 183.

## ФАТИХ ӘМИРХАН (1886–1926)

Фатих Әмирхан (Мөхәммәтфатих Зариф улы Әмирханов) 1886 елның 13 гыйнварында Казанның Яңа бистәсендә Зариф мулла гаиләсендә дөньяга килә. Җиде яшьтә аны Яңа бистәдәге башлангыч мәдрәсәгә укырга бирәләр. Ике ел үткәч, 1894 елның көзендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә күчерәләр. Шул ук вакытта ул үзлегеннән русча өйрәнә башлый. 1904 елның июнь-сентябрь айларында рус телен тирәнрәк үзләштерү максаты белән Самарада яши. Аннан соң Казанга кайтып, большевик студент С.Н.Гассардан дәресләр ала. Теләге — экстерн юл белән өлгергәнлек аттестаты алу, Казан университетына укырга керү була. С.Н.Гассар белән аралашу тәэсирендә сәяси һәм икътисади әдәбиятны ныклап өйрәнә. 1905 елгы революция көннәрендә «Мөхәммәдия» шәкертләренең идеоло-

гик җитәкчесенә әйләнеп китә. Шул елның көзеннән башлап, яшерен рәвештә чыгучы «Әльислах» газетасын җитәкли.

1906 елда Ф.Әмирхан укуын русча дәвам итә. Бу чорда татар яшьләре арасында популяр шәхескә әйләнә, өлгергәнлек аттестаты алырга әзерләнә.

1906 елның көзендә Ф.Әмирхан Мәскәүдә укый башлый, рус теле һәм әдәбияты буенча белемен күтәрә. Мәскәүдә чыга башлаган «Тәрбиятел-әтфаль» («Балалар тәрбиясе») исемле татар телендә беренче балалар журналының җаваплы сәркатибе итеп билгеләнә. Әмма журнал озын гомерле булмый, бишенче саннан соң туктатыла. Бу журналда Ф.Әмирханның берничә тәрҗемәи хикәясе һәм фәнни-популяр әсәре дөнья күрә.

1907 елның маенда Ф.Әмирхан кабат Казанга кайта. «Әльислах» газетасын чыгарырга әзерләнә. Ләкин язмыш аны зур сынау алдына куя: көзен егетнең аяклары параличлана һәм гомере буена инвалид коляскасында хәрәкәтләнергә мәҗбүр була. Атаклы шагыйрь Х.Туфан үзенең «Могикан» (1969) поэмасында Ф.Әмирханны «Аяклары бәйле Прометей» дип атый.

Милләтенә хезмәт итү теләге төрле каршылыкларны җиңәргә булыша. 1907–1910 елларда ул аеруча публицистика өлкәсендә актив эшли. «Әльислах» газетасын оештыра һәм җитәкли, «Кояш» газетасында җаваплы сәркатип вазифасын башкара. «Яшен», «Ялт-йолт», «Аң» журналларында аның әсәрләре, тәрҗемәләре һәм әдәбият-сәнгать мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләре басыла. «Әльислах»та якын дусты Тукай белән бергә татар әдәби тәнкыйтенә нигез сала. Газеталарда еш басылганлыктан, Ф.Әмирхан үзенә «Дамелла», «Галимөхәммәд», «Т-Д», «Зәмзәметдинов» дигән псевдонимнар ала.

Бу елларда Ф.Әмирхан «Гарәфә кич төшемдә» (1907), «Бәйрәмнәр» (1908), «Милләт тәрәккъый иттерү» (1908), «Картайдым» (1909), «Татар кызы», «Танымаганлыктан таныштык» (1909) кебек хикәяләрен, «Яшьләр» (1909) драмасын, «Фәтхулла хәзрәт» (1909) исемле атаклы сатирик повестен яза.

1909 елның җәендә «Әльислах» газетасы чыгудан туктагач, Ф.Әмирхан фикердәшләре Г.Тукай, Г.Камал җитәкчелегендә 1910 елның мартыннан чыга башлаган «Ялт-йолт» исемле көлке журналында актив язышa. 1912–1918 елларда исә ул бөрөзлексез «Кояш» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли.

1910–1917 еллар арасында Ф.Әмирханның татар тормышының төрле якларын яктырткан «Хәят» (1911) повесте, «Урталыкта» (1912) романы, «Тигезсезләр» (1914) драмасы, «Көндезге сәхәр яки рузасызлар» (1911), «Хәзрәт үгетләргә килде» (1912), «Габделбасыйр гыйшкы» (1914), «Танс кичәсе» (1914), «Сәмигулла абзый» (1916), «Салихҗан кари» (1916) һ.б. хикәяләре дөнья күрә. Әдипнең милли фольклор һәм тарихка багышланган хикәяләре дә бар. Гомумән, революциягә кадәр Ф.Әмирханның әсәрләре тупланган егермегә якын китабы басылып чыга.

Талантлы драматург итеп Ф.Әмирханны «Яшьләр» (1908) һәм «Тигезсезләр» (1913) пьесалары таныта. Аларда ул үз чоры өчен актуаль булган аталар һәм балалар каршылыгы, милләт язмышы, икътисад, әдәбият, сәнгать, кеше бәхете кебек проблемаларны яшьләр тормышы аша психологик тирәнлек белән тасвирлый. «Сәйяр» театр труппасы тарафыннан «Яшьләр» пьесасы — 1913 елда, ә «Тигезсезләр» 1915 елда сәхнәләштерелә. Ул шулай ук «Фәтхулла хәзрәт» повестен сәхнә варианты итеп үзгәртә һәм драма 1922 елның җәендә «Ширкәт» труппасы тарафыннан Казанда спектакль итеп уйнала.

1921–1926 елларда Ф.Әмирхан көндәлекләр алып бара. Анда язучының әрнү-сагышлары, әдәбият-мәдәният тормышыннан читтә калдырылуы, рухи һәм матди кыенлыкта яшәве, җәмгыятьтә гаделсезлекләрнең башлануы чагыла. Гомумән, егерменче елларда Ф.Әмирхан «буржуа язучы» дип бик нык тәнкыйтьләнә, аның әсәрләре совет укучысы өчен зарарлы дип табыла. Хаксыз кимсетүләрне яралы йөрәге аша үткәреп, 40 яшен яңа тутырган зыялы әдип 1926 елда вафат була.

Татар әдәбиятын төрле жанрдагы гүзәл әсәрләр, сәнгати табышлар, фәлсәфи фикерләр белән баеткан зыялы шәхес Ф.Әмирхан иҗаты әдәбият тарихының алтын дәверен булдыручыларның иң күренеклеләреннән саналырга хаклы.

1961 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Ф.Әмирханның «Яшьләр» пьесасы куела.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Әмирхан Ф.** Тигезсезләр (Яңа кешеләр). 3 пәрдәдә пьеса. — Казан: Хәсәни., 1915. — 72 б.
**Әмирхан Ф.** Тигезсезләр. Татар кызы. Халык кызлары. — Казан: «Матбугат» нәшр., 1925. — 92 б.
**Әмирхан Ф.** Сайланма әсәрләр 2 томда. — 2 т. Сәхнә әсәрләре һәм публицистика. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1958. — 615 б.
**Әмирхан Ф.** Әсәрләр 4 томда. — 2 т. Повестьлар, роман һәм драма әсәрләре. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1985. — 486 б.
**Әмирхан Ф.** Әсәрләр / Төз.: Д.Заһидуллина һ.б. — Казан: Мәгариф, 2002. — 319 б.

**Аның турында:**

**Хисмәтуллин Х.** Фатих Әмирхан: Тормышы һәм иҗаты турында кыскача популяр очерк. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1961. — 59 б.
**Мәһдиев М.** Яңа бистә Прометее / Мәһдиев М. Әдәбият һәм чынбарлык. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. — 29–68 б.
**Нуруллин И.** Фатих Әмирхан. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. — 279 б.
**Әхмәдуллин А.** Ф.Әмирханның драматургик мирасы / Әхмәдуллин А. Дөреслеккә ирешү юлында. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. — 191–196 б.
Фатих Әмирхан турында истәлекләр / Төз.: Ф.Ибраһимова, Р.Әмирхан. Тулыландырылган 2 нче басма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 254 б.
**Сайганов А.** У истоков эстетики реализма. — Казань: Таткнигоиздат, 1982. — С. 168.

## АБДУЛЛА ӘХМӘТ (1905–1976)

Абдулла Сафиулла улы Әхмәтов 1905 елның 25 мартында хәзерге Курган өлкәсенең Притобольный районы Звериный авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Авыл мәктәбендә башлангыч белем алгач, соңрак махсус курслар тәмамлап, 1922–1923 елларда Чиләбе өлкәсенең Олы Солтан авылы балалар йортында тәрбияче, аннары үз авылларында уку йорты мөдире булып эшли. Шул вакытларда ул Уралда чыга торган «Социализм юлы» газетасына хәбәрләр яза башлый. 1925 елда партия-совет мәктәбен тәмамлаганнан соң, яшь хәбәрчене Свердловск шәһәрендә татар телендә чыга торган «Саба һәм чүкеч» газетасы редакциясенә эшкә чакыралар. Журналистлык хезмәте белән бергә ул әдәби хезмәт белән дә шөгыльләнә. Бер-бер артлы аның очерклары, кыска хикәяләре басыла, 1931 елда Мәскәүдә «Центриздат» нәшриятында «Кара баганалар» исемле беренче китабы дөнья күрә.

1932 елда А.Әхмәт Казанга күчеп килә һәм Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Бөек Ватан сугышы башланганчы «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, аннары Казан химия-технология техникумында һәм музыка мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Әдәби иҗат белән дә шөгыльләнә, колхозлашу темасын яктырткан «Күршеләр» (1933), балалар өчен «Йолдыз» (1934), «Шикле кеше» (1936) һәм фольклорга нигезләнгән «Үги кыз» (1940) исемле пьесалары дөнья күрә (беренче икесе А.Алиш белән берлектә языла). «Үги кыз» пьесасы 1940–1941 елгы театр сезонында Татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелә һәм уңыш казана.

Сугыш башлангач, А.Әхмәт фронтка китә, ике ел буе алгы сызыкта гади солдат булып сугыша, яраланып, госпитальдә дәвалана, яңадан алгы сызыкка кайта һәм сугышның ахырына кадәр татар телендә чыгучы «Алга, дошман өстенә!» исемле фронт газетасы редакциясендә эшли, бик күп очерклар һәм хикәяләр яза.

1946 елда армиядән кайткач, А.Әхмәт башта Татарстан китап нәшриятында яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире (1946–1951), аннары «Пионер» (хәзерге «Ялкын») журналының җаваплы редакторы булып эшли.

Сугыштан соң А.Әхмәт проза һәм драматургия жанрларының һәр икесендә нәтиҗәле иҗат итә. Бу елларда аның Татарстанда беренче буын нефть эзләүчеләрнең фидакяр хезмәте турында «Серләр» (1948) һәм «Егет сүзе» (1954) исемле драмалары языла һәм пьесалар икесе дә Татар дәүләт академия театрында, шулай ук Уфа, Свердловск, Бөгелмә театрлары сәхнәләрендә уйнала.

А.Әхмәт аеруча балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертә. Аның ике дистәгә якын китабы бар.

Шулай ук ул татар халык иҗаты әсәрләрен туплау, әдәби эшкәртү һәм матбугатка әзерләп чыгару буенча да ифрат күп эш башкара, 1938 елда фольклорчы Х.Ярми белән берлектә «Халык иҗаты» исемле зур күләмле җыентык бастыра. Аның тарафыннан төзелгән һәм кат-кат басылган «Хуҗа Насретдин мәзәкләре», «Мәкальләр», «Табышмак әйтәм — табыгыз» дигән җыентыклары да киң җәмәгатьчелектә уңай бәяләнә.

Ул 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Әхмәт А.** Зәңгәр конверт: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1975. — 334 б.
**Әхмәт А.** Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. — 240 б.
**Әхмәт А.** Йөрәк шатлана: Пьесалар, хикәяләр, очерклар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1985. — 312 б.

**Аның турында:**

**Иделле Г.** Прозаик һәм драматург Абдулла Әхмәт / Иделле Г. Язучы һәм аның китабы. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1964. — 124–129 б.
**Бакир Г.** Каләме очлы, хыялы бай аның // Совет әдәбияты. — 1965. — № 3. — 88–91 б.
**Латыйпов Ф.** Балачак хатирәсе: Абдулла Әхмәтнең тууына 100 ел // Казан утлары. — 2005. — № 3. — 178–179 б.
**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: — Тат. кит. нәшр., 1986. — 607–609 б.

## ИДРИС БАГДАНОВ (1886–1916)

Идрис Багданов 1886 елда Сембер губернасы якларында туа. Яшьли әтисез калып, әнисе тәрбиясендә үсә. Казанда Татар укытучылар мәктәбен тәмамлый, аннан соң Мәскәү университетының юридик факультетында укый. Ләкин, авырып китүе сәбәпле, укуын ташларга мәҗбүр була һәм Троицк якларына кымыз белән дәваланырга китә. Шул төбәкләрдә урнашып, фабрикант Яушевлар конторасына эшкә урнаша. Аннары берара Казанда төрле газета идарәләрендә хезмәт итә.

Идрис Багданов XX йөз башында үзенең пьесалары, аеруча «Помада мәсьәләсе» комедиясе белән таныла. Әлеге әсәре һәм «Зөләйха белән Фатыйма», «Югалган хатын» пьесалары 1908–1909 елларда аерым китап булып басылып чыгалар. «Югалган хатын» — 1910 елда, «Помада мәсьәләсе» — 1911 елда, «Зөләйха белән Фатыйма» драмасы 1913 елда «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәләштерелә.

И.Багданов тәрҗемәче буларак А.Пушкин һәм Л.Толстойның кайбер әсәрләрен татарчалаштырып бастыра.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Багданов И.** Зөләйха белән Фатыйма: Пьеса 3 пәрдәдә, 5 күренештә. — Казан, 1908. — 52 б.
**Багданов И.** Помада мәсьәләсе: Пьеса 3 пәрдәдә. — Казан: Хөсәения, 1908. — 184 б.
**Багданов И.** Югалган хатын. Комедия 2 пәрдәдә. — Казан: Мәгариф, 1909. — 39 б.
**Багданов И.** Помада мәсьәләсе: Татар пьесалары. Антология. Беренче китап. — Казан. Татар. кит. нәшр., 1987. — 114–192 б.

**Аның турында:**

Татар пьесалары. Антология. Беренче китап. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. — 719–720 б.
**Рәми И., Даутов Р.** Әдәби сүзлек / Элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 54 б.

## САЛИХ
## БАТТАЛ
## (1905–1995)

Салих Баттал (Салихҗан Вазих улы Батталов) 1905 елның 5 августында Татарстанның Алексеевск районы Зур Тинчәле авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Урта Тигәнәле авылы мәдрәсәсендә һәм гражданнар сугышы чорында бер кыш Чистайдагы Шиһап хәзрәт мәдрәсәсендә укый. 1921 елгы ачлык вакытында туганнарына ияреп, Мәскәү өлкәсенә үз көнен үзе күрергә чыгып китә. Ул төрле көнлекче эшләрдә эшли: икмәк, яшелчә җыеша, вагоннар бушатыша, җир казый, көтү көтә һ.б. Бу елларда каләм тибрәтә башлый һәм беренче шигыре башта татар клубы стенасы газетасында, аннары Мәскәүдә чыгучы «Эшче» газетасында басыла.

1924–1926 еллар арасында С.Баттал татар-башкорт эшче яшьләренең Мәскәүдәге икееллык гомуми белем курсларында укый һәм, аны тәмамлап, Мәскәү өлкәсендәге Вербилка фарфор фабрикасында эшли башлый (мәгариф-агарту эшләрен оештыручы вазифасын да үти). Фабрикада алган тәэсирләре нигезендә «Организатор» (1928) исемле беренче комедиясе языла. Танылган режиссер Газиз Айдарский тарафыннан 1928–1929 елларда пьеса Мәскәү Үзәк татар эшче театры сәхнәсендә күп мәртәбәләр куела һәм билгеле бер күләмдә уңыш та казана.

1927 елдан С.Баттал Кызыл Армия хәрби һава көчләренең Ленинградтагы хәрби теория мәктәбендә, 1928–1929 елларда Оренбург очу мәктәбендә укый һәм өч елдан артык Брянск, Казан шәһәрләрендә очучы булып эшли. Бу чорда аның авылларда күмәкләшү елларындагы сыйнфый көрәшне сурәтләгән «Язучы яулык» (1930–1931) исемле драмасы Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала.

1935 елдан башлап берничә ел С.Баттал әдәби иҗат белән генә шөгыльләнә. Аның очучылар тормышына бәйле төрле жанрдагы әсәрләре языла. «Сынау» (1938) исемле пьесасы 1939 елда режиссер Р.Ишморат тарафыннан Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела һәм матбугатта уңай бәяләнә. Драма шул ук елны аерым китап булып басылып та чыга.

Бөек Ватан сугышы чорында С.Баттал хәрби һава көчләренең Тын океан флотында хәрби очучы булып хезмәт итә, японнар белән сугышта катнаша һәм шәхси батырлыклары өчен сугышчан медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң да иҗат эшен туктатмый. Әхлак-этика мәсьәләләрен яктырткан «Бер карар тирәсендә» (1950), «Киртә» (1959), «Яңа өйгә күчкәч» (1959), «Үтеп барышлый» (1960), «Бәрәкәтле чәй» (1969) кебек пьесаларын яза.

Драматург буларак, аңа зур өметләр баглыйлар. Ләкин пьесалары Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә дә, республиканың башка театрларында да куелмый.

С.Баттал «Капитан Гастелло» (1942) поэмасы, «Олы юл буйлап» (1953) шигъри повесте, «Чирмешән ярларында» (1934–1970) исемле шигъри романы һәм илдәге киеренке чорларда бер очучының катлаулы язмышын сурәтләгән «Сигезенче кем?» дигән повесте белән татар әдәбияты тарихында үзенчәлекле урын алып тора.

Ул А.Пушкин, В.Маяковский, Н.Никитин әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

Әдәбият өлкәсендәге уңышлары өчен әдип 1957 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Салих Баттал 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

### Басылган драма әсәрләре:

**Баттал С.** Сынау: Пьеса 5 пәрдәдә. — Казан: Татгосиздат. — 1939. — 80 б.
**Баттал С.** Комедияләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. — 176 б.

### Аның турында:

Әдип турында каләмдәшләре (Н.Арслан, А.Гыйләҗев, Р.Батулла) // Казан утлары. — 1990. — № 8. — 163–170 б.

**Бадыйкшин Л.** Сугышта ул лачындай очучы иде, җирдә дә аякта нык торды... // Мәдәни җомга. — 1995. — 28 июль.

**Хуҗин М.** Иҗат тасвирате төсмерләре // Мәйдан. — 2002. — № 9–10; 2003. — № 1. — 90–94 б.
**Мостафин Р.** Партия «имәне» белән сөзешкән Казан «үгезе» // Татарстан. — 2004. — № 11. — 62–67 б.

## РАБИТ БАТУЛЛА (1938)

Рабит Батулла (Роберт Мөхлис улы Батуллин) 1938 елның 26 мартында Татарстанның Зәй районы Түбән Олоҗы авылында туа. 1955 елда Биш Авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Кадер авылындагы җидееллык мәктәптә балалар укыта. 1956–1961 елларда Мәскәүдә М.С.Щепкин исемендәге театр училищесында укый, аны тәмамлагач, ике ел Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актер булып эшли, шул ук вакытта режиссерлык эше белән дә шөгыльләнә. 1963–1965 елларда ул — Казан курчак театрында һәм телевидениедә балалар өчен тапшырулар редакциясендә режиссер. 1965 елда Мәскәүдә Югары режиссерлык курсларында белемен арттырганнан соң, соңыннан Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында режиссер-педагог һәм Казан курчак театрында режиссер булып эшли. 1977–1979 елларда Р.Батулла Мәскәүнең М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлаганнан соң, театр училищесында укыта.

Р.Батулла әдәбиятның төрле жанрларында иҗат итә. Иҗатының беренче чорында ул күбрәк Курчак театры өчен яза. Аның «Төш вакытындагы могҗиза», «Курай уйный бер малай», «Салават күпере» һ.б. пьесалары Казан, Донецк, Саратов, Кемерово, Барнаул курчак театрлары сәхнәләрендә куела. «Әбүгалисина кыйссасы» нигезендә язылган «Тылсымчы белән сихерче» (1966) пьесасы аеруча зур уңыш казана: Курчак театрларының Бөтенроссия конкурсында икенче дәрәҗә диплом алуга ирешә. Әдип тирән эчтәлекле, актуаль проблемаларны чагылдырган «Ихлас» (1972), «Кичер мине, әнкәй» (1978), «Өчәү юлга чыктык», «Ләйлә белән Мәҗнүн» («Туйлар узгач», 1972), «Мин Америка ачтым» (1977), «Елантау» (1976), «Исап-хисап» (1979), «Нурислам нигезе» (1982), «Сөйгән ярым ятларга кала» (1983), «Ак күгәрченнәр» (1983), «Сират күпере» (1986), «Кояш баеганда» һ.б. драма әсәрләре яза. Аның әсәрләре төрле театрларда уңыш казана. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә «Өчәү юлга чыктык» (1973), «Кичер мине, әнкәй» (1979), «Елантау» (1984), «Ярым ятларга кала» (1989) пьесалары тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителә. 2003 елда уздырылган «Яңа татар пьесасы» бәйгесендә әдипнең «Җимерелгән бәхет», «Юл газабы» исемле пьесалары зур уңыш казанды.

Р.Батулла шулай ук прозаик, балалар язучысы, тәрҗемәче, тәнкыйтьче буларак та танылды. Ул халкыбызның бөек ханбикәсенә — Сөембикәгә багышлап «Сөембикә» романын иҗат итте. «Юл буенда зәңгәр чәчәк» повесте, балалар өчен язылган «Исемем минем Дүрткүз», «Серле сандык», «Алып батыр маҗаралары», «Ташсуар патша», «Үлемсез егет» һ.б. шундый мавыктыргыч повесть-әкиятләре, хикәяләре дә дөнья күрде.

Рабит Батуллага 1985 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде. Әдәбият өлкәсендә ирешкән уңышлары һәм иҗтимагый эшчәнлеге өчен Гаяз Исхакый исемендәге премиягә лаеклы булды. 2006 елда аңа «Сөембикә» тарихи романы өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге тапшырылды.

Р.Батулла — 1968 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

### Басылган драма әсәрләре:

**Батулла Р.** Могҗизалы тамаша: Мәктәп сәхнәләре өчен пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1968. — 96 б.
**Батулла Р.** Пәһлеваннар иле: Курчак театры өчен пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. — 95 б.
**Батулла Р.** Чебен гөмбәсе: Театраль миниатюралар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1985. — 208 б.
**Батулла Р.** Кичер мине, әнкәй: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. — 439 б.
**Батулла Р.** Ана каргышы: Яңа татар пьесасы 3 томда. — 1 т. — Казан: Идел-Пресс, 2004. — 47–113 б.
**Батулла Р.** Җимерелгән бәхет: Яңа татар пьесасы 3 томда. — 2 т. — Казан: Идел-Пресс, 2004. — 5–97 б.

### Аның турында:

**Шәрәфи Р., Мингалим Р.** Эзләнүләр юлыннан: Батулла иҗаты турында уйланулар // Казан утлары. — 1980. — №8. — 165–169 б.
**Әхмәдуллин А.** Өчәү юлга чыктык // Социалистик Татарстан. — 1974. — 24 март.
**Вәлиев М.** Миңзифаның матурлыгы // Социалистик Татарстан. — 1979. — 11 декабрь.
**Арсланов Г.** Утверждение человечности // Сов. Татария. — 1979. — 2 дек.
Татар драматургиясе (1960–1980). Сайланма пьесалар: «Мәктәп китапханәсе» сериясе. — 21 т. / Төз. һәм кереш мәкалә авт. А.Саттарова. — Казан: ТаРИХ, 2003. — 365–420 б.
**Даутов Р.** Балачак әдипләре: — Казан: Мәгариф, 2003. (Р.Батулла турында 27–33 б.)

## ӘХСӘН
## БАЯН
## (1927)

Әхсән Баян (Әхсән Фәтхелбаян улы Баянов) 1927 елның 8 декабрендә Башкортстанның Илеш районы Әшмән авылында туа.

1943 елда Әхсән Баян күрше Ишкар авылында җидееллык мәктәпне тәмамлый. 1947–1950 елларда район үзәге Югары Яркәйдә Мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе булып эшли. Шул ук елларда урта мәктәпне тәмамлый. 1951–1956 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем алганнан соң, журналист булып эшли. 1963–1966 елларда «Казан утлары» журналы идарәсендә җаваплы сәркатип, 1977–1981 елларда журналның баш мөхәррир урынбасары вазифасын башкара.

Ә.Баян иң элек шигъри әсәрләре белән танылa. Аның «Яшел мәйдан» (1957), «Диңгез шавы» (1958), «Марат» (1959), «Сәяхәтнамә» (1969) һ.б. поэмалары, күпсанлы шигырьләре, балладалары дөнья күрде. Авторның «Яшьлегемне эзлим» (1966), «Язмыштан узмыш» (1974), «Аязучан болытлы һава» (1978), «Тавыш — табигать бүләге» (1977), «Мәңгелек бәхәс» (1986) повестьлары, «Ут һәм су» (1971), «Таш китап» (1981) романнары һ.б. нәшер ителде. Әдипнең «Күзләре нинди иде...», «Һәйкәл», «Зәңгәр кыңгыраулар» һ.б. пьесалары дөнья күрде. «Күзләре нинди иде...» пьесасы 1965–1967 елларда — Татар дәүләт драма театрында, «Һәйкәл» 1970–1975 елларда Минзәлә дәүләт драма театрында куелды. 1980–1986 елларда иҗат ителгән «Алтын кашбау» шигъри трагедиясе тарихи тематикага багышлана. Аның 1989–1991 елларда язылган «Каракош» шигъри трагедиясендә Г.Тукай образы тасвирлана. Әсәрдә тарихилык белән автор уйдырмасының синтезы чагылыш тапты.

«Ут һәм су» романы өчен Ә.Баянга 1975 елда «Камгэсэнергострой» төзү берләшмәсенең беренче дәрәҗә бүләге тапшырыла. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы 1977 елда «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә. 1988 елда аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә. 1999 елда Ә.Баян «Урланган ай» исемле китабы өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды. 2004 елдан ул — Татарстанның халык шагыйре.

Ә.Баян — 1965 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

### Басылган драма әсәрләре:

**Баян Ә.** Сайланма әсәрләр 2 томда. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1992–1993.
**Баян Ә.** Кызык ут: Шигырьләр һәм шигъри трагедия. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. — 287 б.

### Аның турында:

**Галимуллин Ф.** Тәрәзәдән якты бөркелә... // Мирас. — 1997. — № 12. — 43–47 б.
**Низамиев Р.** Яшьлекне сагыну // Казан утлары. — 1997. — № 11. — 28–30 б.
**Даутов Р.** Балачак әдипләре: Ә.Баян турында. — Казан: Мәгариф, 2003. — 40–45 б.

## ФӘҮЗИЯ
## БӘЙРӘМОВА
## (1950)

Фәүзия Әүхәди кызы Бәйрәмова 1950 елның 5 декабрендә Татарстанның Саба районы Сабай авылында ун балалы гаиләдә дөньяга килә. Башлангыч белемне үз авылында алып, сигезьеллык мәктәпне күрше Олы Шыңар авылында тәмамлаганнан соң, ул Саба районында нәшер ителгән «Җиңү байрагы» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. Шул ук вакытта Сабаның кичке мәктәбендә урта белем ала.

1968 елда Казан театр училищесының режиссерлык бүлегенә укырга керә. Укуын тәмамлагач, 1973–1975 елларда Казан телевидениесендә режиссер ярдәмчесе булып эшли. 1975–1978 елларда Ф.Бәйрәмова гаиләсе белән Монголиядә яши, шунда төрки халыкларның тарихы белән кызыксына башлый.

1979–1987 елларда ул үз эшчәнлеген матбугат белән бәйли. 1979–1984 елларда «Казан утлары» журналында, 1985–1986 елларда — «Татарстан яшьләре», соңыннан «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газеталарында хәбәрче вазифаларын башкара. Бу еллардан башлап көндәлек матбугатта аның мәкаләләре басыла башлый. 1987–1990 елларда Ф.Бәйрәмова Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә редактор булып эшли. 1989 елда читтән торып укып, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый.

Ф.Бәйрәмованың эшчәнлеге киңкырлы. Аның прозасы тирән психологизм, фәлсәфилек, үзенчәлекле образлар системасы белән аерылып тора. Язучының «Болын» (1983), «Битлек» (1983), «Чакрым баганалары» (1983), «Күл балыгы» (1984), «Кыңгырау» (1987), «Канатсыз акчарлаклар» (1988) повесть-хикәяләре; «Кара урман», «Соңгы намаз» (2000) романнары һ.б. хәзерге татар прозасының казанышы булып санала.

Сиксәненче елларда Ф.Бәйрәмова драматургия өлкәсендә дә үзенчәлекле иҗади уңышларга ирешә. Әдибәнең фәлсәфи эчтәлекле, катлаулы проблемаларны күтәргән «Аллалар ялгышы, яки Яңа матриархат» (1981), «Һәркемгә бер кояш» (1982) трагедиясе, Һ.Такташка багышланган, архив материалларына нигезләнеп язылган «Атылган йолдыз» (1985), тормышның иҗтимагый-сәяси якларын яктырткан «Безне онытмагыз» (1988), «Вакыйга җүләрләр йортында бара» (1991), Әфганстан сугышында һәлак булган татар егетләренә атап иҗат ителгән «Сандугачның балалары» (1988) һ.б. пьесалары дөнья күрде.

Ф.Бәйрәмова пьесалары, сәхнәләштерелеп, Минзәлә татар драма театрында, Казан татар яшьләр театрында һ.б. куелды. «Безне онытмагыз» драмасы «Халык театры» сәхнәсендә куелып, 1990 елда телеспектакль буларак Казан телевидениесе аша тапшырылды.

Ф.Бәйрәмова иҗтимагый-сәяси, дини мәкаләләр авторы да. Аның «Үтерелгән пәйгамбәр», «Талант фаҗигасе», «Гасырларга тиң фаҗига», «Сайлаган юлың дөресме?» һ.б. мәкаләләре тирән эчтәлекле, кыю фикерле булулары белән характерланалар.

Ф.Бәйрәмова татар милләтенең бүгенгесе һәм киләчәге турында кайгырткан сәясәтче буларак та бөтендөнья күләмендә танылды. Милли, дини һ.б. мәсьәләләргә багышланган докладлары белән ул Америка, Германия, Бельгия, Голландия, Дания, Төркия, Кипр кебек илләрдә халыкара форумнарда, конгрессларда, корылтайларда чыгыш ясый. Әдибә — Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты әгъзасы, Бөтендөнья төрки Ассоциациясенең рәис урынбасары (Төркия, 1997), Бөтендөнья төрки хатын-кызлары оешмасының җаваплы сәркатибе (Төркия, 2004). Ул 2001 елдан Россия мөселман хатын-кызлары оешмасын җитәкли. Ф.Бәйрәмова Гаяз Исхакый һәм Һади Атласи бүләкләре иясе.

Ул — 1986 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Бәйрәмова Ф.** Безне онытмагыз: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. — 253 б.

**Бәйрәмова Ф.** Мишәрнең бөек улы: Фәнни-публицистик язмалар, драма. — Казан: Аяз, 2001. — 144 б.

**Аның турында:**

**Закирҗанов Ә.** Онытырга хакыбыз юк // Казан утлары. — 2000. — № 8. — 137–141 б.

**Саттарова А.** З.Хәким һәм Ф.Бәйрәмова драматургиясенең үзенчәлекләре // М: // i Mədəniət. — 2001. — № 1. — 63–66 б.

**Сверигин Р.** Гасырлар чатында // Казан утлары. — 2002. — № 4. — 150–152 б.
**Саттарова А.** Современная татарская драматургия: 1985–2000 гг. (концепция эпохи и героя) (О пьесах Ф.Байрамовой на с. 13–29, 29–38).
**Даутов Р.** Балачак әдипләре: Биобиблиографик белешмәлек. Икенче китап. (Ф.Бәйрәмова турында 30–42 б.). — Казан: Мәгариф, 2004. — 285 б.
**Әхмәтова Г.** Ф.Бәйрәмова драмалары // Шәһри Казан. — 2004. — 13 август.

## КӘБИР БӘКЕР (1880–1942)

Кәбир Бәкер Оренбургтан ерак түгел урнашкан Зубачы авылында туа. Татар телендә чыга башлаган беренче газета һәм журнал битләрендә мәдәният, әдәбият һәм милли театр мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләре белән танылa. «Әльислах», «Йолдыз», «Вакыт» газеталарында даими рәвештә театр репертуарында булган пьесаларга, милли драматургиянең үзенчәлекләренә рецензияләр яза. Ул үзенең язмаларында шул чор татар театр сәнгатенең үсеш закончалыкларын, уңыш һәм кимчелекле якларын аермачык итеп күрсәтә. Аның бу юнәлештәге эшчәнлеге замандашлары тарафыннан да (Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Җ.Вәлиди) югары бәяләнә. К.Бәкер 1905 елдан Петербургта «Әльислах»та язышa һәм 1913 елда Оренбургтагы «Вакыт» газетасына эшкә күчә.

Үткен каләмле әдип драматургиядә дә көч сынап карый. 1909 елда басылган «Чөн тамъ, яхуд Татар мәдрәсәсендә атна кич» исемле комедиясен «Сәйяр» труппасы 1912 елда сәхнәгә куя. Комедиягә Ф.Әмирхан махсус рецензия дә яза. Икенче әсәре — «Тарихи пьеса»сы (Юри шаяртып укыр өчен язылган бер пьеса-хикәят) 1912 елда аерым китап булып басыла.

К.Бәкер тәрҗемәче, «Чын егетлек нәрсәдә?» (гарәп тормышыннан хикәя) (1909) , «Ахун хәзрәтнең вафаты» (1912), «Кара тап» (1912), «Җанлы курчаклар» (1912) исемле хикәяләр һәм шагыйрьнең вафатыннан соң язылган «Тукай Петербургта» исемле кызыклы истәлек (1914) авторы буларак та билгеле.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Бәкер К.** Чөн тамъ, яхуд Татар мәдрәсәсендә атна кич: Комедия 1 пәрдәдә. — Казан, 1908. — 32 б.
**Бәкер К.** Тарихи пьеса (Юри шаяртып укыр өчен язылган бер пьеса-хикәят). — Казан: Юл, 1912. — 24 б.

**Аның турында:**

Кәбир Бәкернең тууына 100 ел (1880–1942) // Казан утлары. — 1980. — № 1. — 183–184 б.
**Рәми И., Даутов Р.** Әдәби сүзлек: Элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 45–46 б.

## ШАМИЛ БИКЧУРИН (1928–1991)

Шамил Мотыйгулла улы Бикчурин 1928 елның 3 гыйнварында Татарстанның Әлмәт районы Миңлебай авылында туа. Авылда һәм Әлмәттә укып ун класс белем алганнан соң, 1945 елда Казанга килә, ике ел Татар театр училищесында укый, аннары беркадәр вакыт Әлмәт дәүләт драма театрында актер булып эшли. 1948–1952 елларда хәрби авиация частьларында хезмәт итә. Армиядән кайткач, Шамил Бикчурин туган ягында нефть чыгаручылар арасында эшли, газета редакциясе эшендә катнаша: бүлек мөдире вазифасын үти. 1965–1967 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый.

Татар әдәбияты укучыларына Шамил Бикчурин беренче чиратта эшчеләр тормышын, Татарстанга зур үзгәрешләр алып килгән нефть темасын яктырткан әсәрләре белән таныш. Әлмәт төзүче-

ләре һәм нефть чыгаручылар турындагы очерк, хикәяләре иҗатының төп китаплары булган «Каты токым», «Тирән катлам» романнары өчен җирлек әзерләделәр. «Каты токым» романы, рус, украин, словак телләренә тәрҗемә ителеп, эшчеләр хезмәтен чагылдырган әсәрләр конкурсында җиңеп чыга.

Сүз сәнгатенә килү юлы театр училищесыннан һәм актерлык хезмәтеннән башлану табигый рәвештә Шамил Бикчуринны сәхнә әдәбияты белән дә кавыштыра. 1961 елда язучы «Тальян моңы» исемле музыкаль комедиясен яза. Нефтьчеләр белән авыл эшчәннәре арасындагы эчкерсез дуслыкны, кызыклы мөнәсәбәтләрне чагылдырган бу әсәр Әлмәт татар дәүләт театрында һәм Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрларында уйнала. «Бергә, гомергә» исемле комедиясе дә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелып (1964), тамашачылар һәм тәнкыйтьчеләр игътибарын җәлеп итә.

Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ш.Бикчурин 1978 елда «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә.

Ул 1962 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Бикчурин Ш.** Бергә, гомергә: Музыкаль комедия. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1966. — 83 б.
**Бикчурин Ш.** Тальян моңы: Музыкаль комедия. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1967. — 73 б.

**Аның драма әсәрләре турында:**

**Дунай Ф.** Дәвам итсен бу җыр // Татарстан яшьләре. — 1964. — 13 июнь.
**Ишморат Р.** Әйбәт бүләк // Социалистик Татарстан. — 1961. — 25 ноябрь.
**Семенов К.** Мелодия тальянки // — Сов. Татария. — 1961. — 30 ноября.
**Медведенко Д.** Спектакль, театр, город // — Сов. культура. — 1962. — 14 июня.
**Шумская Н.** Уроки одного спектакля // — Сов. Татария. — 1963. — 13 окт.

## РАВИЛ БОХАРАЕВ (1951)

Равил Рәис улы Бохараев 1951 елның 18 октябрендә Казанда галим укытучылар гаиләсендә туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, 1968–1974 елларда Казан дәүләт университетының механика-математика факультетында укый һәм кибернетика белгечлеге буенча аспирантура тәмамлый. Шулай да әдәбият-иҗат дөньясы аны күбрәк мавыктыра һәм ул, фән өлкәсендә алган белемен дә файдаланып, кыю-тәвәккәл рәвештә әдәби-иҗтимагый эшчәнлеген башлап җибәрә: 1979–1980 елларда Р.Бохараев — Россия Язучылар оешмасының Идел буе республикаларында консультант, Мәскәүдәге М.Горький исемендәге Әдәби институтта татар теленнән тәрҗемәләр буенча семинар җитәкчесе (1980–1986). 1990 елдан Равил Бохараев Англиядә яши, төрле жанрларда иҗат итә һәм актив рәвештә тәрҗемә эше белән, әдәбиятка бәйле оештыру эшләре белән шөгыльләнә.

Р.Бохараев — шагыйрь, прозаик, драматург һәм тәрҗемәче. Рус, инглиз, венгр телләрендә татар әдәбияты, беренче чиратта аның шагыйрьләре, Татарстан турында сөйләп һәм язып торучы, күп мәсьәләләр белән кызыксынучы, киң эрудицияле шәхес.

Ул — 20 дән артык китап авторы, әдәби әсәрләре янәшәсендә тарих, политэкономия һәм ислам мәсьәләләренә багышланган әсәрләре дә зур кызыксыну уята: «Азан — Исламская поэзия поволжских татар» (Лондон, 1991), «Модель Татарстана: политэкономическая монография» (Лондон-Нью-Йорк, 1999), «Ислам в России: историческая монография» (Лондон -Нью-Йорк, 2000), «Историческая антология татарской поэзии» (Лондон, 2000), «Казанский Кремль сквозь века» (Лондон, 2001). Инглиз телендә басылган бу китаплар чит илләрдәге укучыларга Татарстан турында мәгълүмат-белем өстиләр.

Равил Бохараев Татарстан, татар әдәбияты һәм сәнгате белән даими бәйләнештә яши — язучылар, тәрҗемәчеләр белән аралаша; театрлар белән хезмәттәшлеге дә матур нәтиҗәләр бирә. Ул «Яңа татар пьесасы» конкурсында катнашып лауреат булды һәм «Тимер борчак» («Железная горошина») пьесасы 2005 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелды.

Г.Тукайның иҗаты һәм шәхесе Равил Бохараевны даими кызыксындыра: ул аның шигырьләрен тәрҗемә итә, үзе төзегән антологиягә кертә һәм Тукай тормышы-язмышы турында «Тукай тирәсендә» дигән драматик повесть яза (1986). Курчак театры өчен язылган пьесасы да — бу теманың матур бер гәүдәләнеше. Казан курчак театрында аның пьесалары зур уңыш белән куелып киләләр: «Йолдызчык Ромашка» (1985), «Апушның тылсымлы төшләре» («Волшебные сны Апуша», 1986), «Сказка о двух монетах» (2005). Татарстан телевидениесендә аның ике серияле «Каюм Насыйри урамы» драмасы күрсәтелде (1989).

Равил Бохараевка 1986 елда Муса Җәлил һәм Габдулла Тукай шигырьләренең тәрҗемәләре өчен Татарстанның М.Җәлил исемендәге Республика бүләге бирелде. 2001 елда ул «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем алды. 2006 елда «Очсыз-кырыйсыз поезд» («Бесконечный поезд», Мәгариф, 2001), «Казан карлары» («Казанские снега», Мәгариф, 2004) китаплары өчен Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Р.Бохараев — 1979 елдан Россия Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Бохараев Р.** Апушның тылсымлы төшләре: Әкият-пьеса (Мөдәррис Әгъләмов тәрҗемәсендә) // Ялкын. — 1986. — № 4. — 8–13 б.

**Бохараев Р.** Апушның тылсымлы төшләре: Әкият-пьеса / Серле алан. — Казан: Татар. кит. нәшр. — 1991. — 14–37 б.

**Бохараев Р.** Тимер борчак. Татар халык йолалары, ышанулары нигезендәге әкият (Җәүдәт Сөләйман тәрҗемәсендә) / Яңа татар пьесасы. — Казан: Идел-пресс, 2004. — 98–175 б.

**Аның турында:**

**Акмалов Н.** Тамырларның тирәнлеген тою // Татарстан яшьләре. — 1986. — 1 ноябрь.

**Валиева В.** Эпох трагических разрывов. // Литературное обозрение. — 1991. — № 9. — С. 57–58.

**Зөлфәт.** Егетлек: Англиядә яшәп иҗат итүче язучы Равил Бохараев турында // Шәһри Казан. — 2003. — 18 апрель.

**Мустафин Р.** Чрезвычайный и полномочный посол татарской литературы // Республика Татарстан. — 2003. — 28 марта.

## ФӘТХИ
## БУРНАШ
## (1898–1946)

Фәтхи Бурнаш (Фәтхелислам Закир улы Бурнашев) 1898 елның 13 гыйнварында элекке Сембер губернасының Буа өязе (хәзерге Чувашстанның Батыр районы) Бикшик авылында мулла гаиләсендә туа. Башта авыл мәдрәсәсендә, соңрак, 1907 елдан Казанның җәдит «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала. Мәдрәсәнең югары сыйныфларында үз көнен үзе күрә башлый: җәйләрен казакъ далаларында мөгаллимлек итә яки, Мәкәрҗәгә барып, көнлекче эшләрдә эшли. 1916 елда «Мөхәммәдия»не ташлап чыга һәм, үзлегеннән әзерләнеп, дүрт класс гимназия программасы күләмендә рус теленнән имтихан тота.

«Мөхәммәдия»дә уку чорында әдәби иҗатта беренче адымнарын ясый. Г.Кариев белән таныша һәм «Сәйяр» труппасы өчен 1914 елда рус язучысы С.А.Найденовның «Ванюшин балалары» («Дети Ванюшина») драмасын татарчага тәрҗемә итә. Беренче тәрҗемә әсәренең сәхнәгә куелуыннан канатланып, шул ук елны «Язмыш» исемле беренче оригиналь пьесасын, бераздан «Сукбай» (1915) һәм «Саташкан кыз» (1916) дигән драмаларын иҗат итә. Бу әсәрләр өчесе дә 1917 елда «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәдә уйнала.

Ф.Бурнаш 1917 елгы Февраль революциясен журналист-әдип буларак каршылый. 1917 елның маенда солдат хезмәтенә алына һәм сентябрьгә кадәр Сембердә 97 нче пехота полкында хезмәт итә.

Солдаттан азат ителгәч, берникадәр вакыт Буа, Сембер шәһәр мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта.

Революция елларында Ф.Бурнаш атаклы «Яшь йөрәкләр» драмасын һәм романтик эчтәлекле «Таһир-Зөһрә» трагедиясен иҗат итә. Ике пьеса да 1918 елда «Сәйяр» артистлары тарафыннан сәхнәгә куела.

Гражданнар сугышы елларында ул совет яклы матбугат органнарында эшли. Сембердә нәшер ителүче «Көн», «Таң» газеталарының редакторы була. 1919 елда коммунистлар партиясе сафына әгъза итеп алына.

1920 елда Ф.Бурнаш Казанга күчеп килә һәм 1924 елга кадәр башта «Кызыл Армия», аннан соң «Татарстан» газеталарының редакторы булып эшли, бер үк вакытта «Безнең байрак» газетасын, «Чаян» һәм «Безнең юл» журналларын оештыруда һәм чыгаруда якыннан катнаша. 1927–1928 елларда Татар дәүләт академия театры директоры вазифасын башкара.

Совет чорында Ф.Бурнашның крепостнойлык чоры татар крестьяннарының язмышын һәм фаҗигасен чагылдырган «Хөсәен мирза» (1919) трагедиясе, искелек белән яңалык көрәшен драматик яки көлке ситуацияләрдә тасвирлаган «Адашкан кыз» (1920), «Шәмсия» (1922), «Камали карт» (1925), «Илһам» (1928), «Авыл яшьләре» (1929), «Хатирә апа» (1929), «Лачыннар» (1931), «Таң» (1932), эшчеләр тормышы һәм колхозлашу темасын яктырткан «Олы юл белән» (1929), «Тукучы Әсма» (1931), «Ялгыз Ярулла» (1940) кебек пьесалары иҗат ителә. «Хөсәен мирза», «Камали карт», «Тукучы Әсма» пьесалары Татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелә; «Хатирә апа» пьесасы 1929 елның 17 апрелендә Мәскәүдә куела, «Камали карт» комедиясенә С.Сәйдәшев махсус көйләр яза.

Ф.Бурнаш күпсанлы шигырьләре, поэмалары белән үзен талантлы шагыйрь итеп тә таныта. Ул шулай ук биш йөзгә якын публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы да. 1931–1935 елларда әдип Татарстан китап нәшриятында эшли. Аның тәрҗемәсендә А.Пушкин, Л.Толстой, И.Тургенев, М.Горький, Н.Островский һ.б. рус, азәрбайҗан, казакъ, белорус, грузин әдипләренең аерым әсәрләре басылып чыга.

Аның шулай ук биш опера либреттосы да бар. М.Җәлил белән берлектә 1936 елдан Ф.Бурнаш татар операсына махсус кадрлар әзерләү студиясенең әдәби секторын җитәкли, милли опералар өчен оригиналь либреттолар тудыру эше белән шөгыльләнә. Ул барлыгы 22 сәхнә әсәре яза.

1940 елда Ф.Бурнаш, нахакка гаепләнеп, кулга алына һәм гомере 1946 елда төрмәдә өзелә.

Ул 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

Ф.Бурнашның Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 1918, 1920, 1959, 1987 елларда — «Таһир-Зөһрә» трагедиясе, 1920, 1922, 1934, 1964, 1985 елларда «Яшь йөрәкләр» драмасы сәхнәләштерелеп, аеруча популярлык казана.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Бурнаш Ф.** Сайланма әсәрләр 2 томда. — 1 т. / Кереш мәкалә авт. Б.Гыйззәт. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. — 278 б.

**Бурнаш Ф.** Сайланма әсәрләр 2 томда. — 2 т. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. — 299 б.

**Бурнаш Ф.** Яшь йөрәкләр: Пьесалар / Җыент. төз. һәм кереш сүз авт. А.Әхмәдуллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. — 256 б.

**Бурнаш Ф.** Мәңгелек мәхәббәт: Җыентык / Төз. һәм кереш мәкаләләр авт. Р.Хафизова. — Казан: Gumanitarya. (ТДГИ нәшр.) — 2003. — 311 б.

**Аның турында:**

**Әхмәдуллин А.** Фәтхи Бурнаш. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1967. — 175 б.

**Әхмәдуллин А.** Бүген дә кыйммәтле мирас / Әхмәдуллин А. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — 146–152 б.

**Әхмәдуллин А.** Фәтхи Бурнаш / Татар әдәбияты тарихы 6 томда. — 4 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 271–287 б.

**Баһаветдинов Ф., Әхмәдуллин А.** Фәтхи Бурнашның соңгы еллары // Казан утлары. — 1990. — № 10. — 176–182 б.

**Шабаев М.** Фәтхи Бурнаш (1898–1942) // Казан утлары. — 1998. — № 1. — 188–190 б.

**Әхмәтҗанов М.** Фәтхи Бурнаш архивыннан яңа материаллар // Мирас. — 2001. — № 10. — 76–77 б.; 2003. — № 1. — 46–48 б.

**Гайнутдинов М.** Фатхи Бурнаш / Гайнутдинов М. Татарская литература зыбких времен (1917–1929 гг.) — Казань, 2001. — с. 43–67.

**Әхмәдуллин А.** «Бодай чәчсәң җиргә, һичвакытта тигәнәкләр үсмәс...» / Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 49–54 б.

## ХӘЙ ВАХИТ (1918–1978)

Хәй Вахит (Габделхәй Каюм улы Вахитов) 1918 елның 2 декабрендә Казан губернасы Арча өязе (хәзерге Татарстанның Биектау районы) Мәмдәл авылында туа. 1934 елда Казанга килеп, театр техникумына укырга керә. 1937–1940 елларда музыка училищесында, 1945–1951 елларда Казан дәүләт консерваториясендә, 1956–1958 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда укый. Хәй Вахит сугышка хәтле үк яза башлый. 1938–1940 елларда аның «Соры кортлар», «Канлы куллар» пьесалары, «Дулкыннар», «Әкиятләр», «Безнең авылда», «Якты юл» һ.б. шигырь җыентыклары дөнья күрә.

Язучының төп иҗат иткән жанры — драматургия. Бу өлкәдәге беренче иҗат тәҗрибәсе авторның «Газета килгәч» (1956), «Егет өйләнә» (1956), «Сырхавына күрә дәвасы» (1958) дигән скетчлардан башлана. Х.Вахитның 1950 еллардан соң иҗат иткән һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында уйналган спектакльләр арасында «Беренче мәхәббәт» (1960), «Рәхим итегез!» (1961), «Кайда соң син?» (1963), «Карлыгач канат кага» (1965), «Соңгы хат» (1966), «Күк капусы ачылса» (1967), «Илһамия» (1968), «Туй алдыннан» (1969), «Мәхәббәтең чын булса» (1972), «Давыл» (1974), «Ике килен-килендәш» (1976), «Талак, талак» (1976–1977), «Оныта алмасаң нишләрсең» (1977) һәм башкалар, шул чор татар драматургиясенең казанышы булып, илнең төрле сәхнәләрендә куелды. Әдип каләмен төрле жанрларда сыный. Драматургның скетчлары, комедияләре, драмалары, илебезнең төрле сәхнәләрендә уйналып, тиз арада халык күңелен яулап ала. «Беренче мәхәббәт» драмасы буенча Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган спектакль өчен әсәрнең авторы Хәй Вахит һәм аның режиссеры Рәфкать Бикчәнтәев 1960 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булалар. 1968 елда драматургка «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеме бирелә.

Күпкырлы талант иясе буларак, Х.Вахит опера либреттолары авторы буларак та танылды. «Самат», «Дим буенда», «Җиһангир» опера либреттолары җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде.

Х.Вахит 1956 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

### Басылган драма әсәрләре:

**Вахит Х.** Беренче мәхәббәт. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1962. — 94 б.

**Вахит Х.** Рәхим итегез. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1963. — 76 б.

**Вахит Х.** Карлыгач канат кага. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1965. — 92 б.

**Вахит Х.** Беренче мәхәббәт: Пьесалар, скетчлар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1968. — 368 б.

**Вахит Х.** Күк капусы ачылса: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. — 94 б.

**Вахит Х.** Яшьлек юллары: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. — 488 б.

**Вахит Х.** Мой депутат. (Лит. пер. О.Сосина). — М.: ВААП, 1977. — С. 76.

**Вахит Х.** Если любовь настоящая: Пьесы. (Пер. с тат. яз.). — М.: Сов. писатель, 1979. — С. 400 и др.

### Аның турында:

**Әхмәдуллин А.** Драматургның үсү юлы / Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. Әдәби-тәнкыйть мәкаләләре. — Казан, 1980. — 202–220 б.

**Әхмәдуллин А.** Сәхнәгә гашыйк // Казан утлары. — 1968. — № 12. — 143–144 б.

**Гыйззәт Б.** Хәй Вахит һәм аның геройлары // Казан утлары. — 1978. — № 12. — 150–156 б.

**Гыймранова Д.** Мәхәббәтең чын булса // Социалистик Татарстан. — 1973. — 1 февраль.

**Арсланов Г.** Кеше булу җиңелме? // Социалистик Татарстан. — 1983. — 13 март.

**Махмутов Х.** К почетному ряду: К 60-летию Х.Вахита // Соц. Татария. — 1978, 19 дек.
**Әхмәдуллин А.** Хәй Вахит (Татар әдәбияты тарихы, 6 т.). — Казан: Раннур, 2001. — 388–405 б.
Татар драматургиясе (1960–1980): Сайланма пьесалар: «Мәктәп китапханәсе» сериясе. — 21 т. / Төз. һәм кереш мәкалә авт. А.Саттарова. — Казан: ТаРИХ, 2003. — 21–142 б.
**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 71–73 б.

## ДИАС ВӘЛИЕВ (1938)

Диас Назыйх улы Вәлиев 1938 елның 1 июлендә Татарстанның Арча районы Казанбаш авылында туа. Балачагы һәм мәктәп еллары Казан шәһәрендә уза. 1956 елда Казан дәүләт университетының геология факультетына укырга керә, студент чагында ук геологик экспедицияләрдә катнаша, күп өлкәләрдә һәм республикаларда була. 1962 елда университетны тәмамлагач, Кемерово өлкәсендә геолог булып эшли. 1965 елда Казанга кайтып, беркадәр вакыт геология өлкәсенә бәйле оешмаларда эшләп алганнан соң, «Комсомолец Татарии» газетасында әдәби хезмәткәр вазифаларын үти. 1973–1975 елларда Д.Вәлиев Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый. Аннан кайткач, тулысынча язучылык эшенә күчә.

Диас Вәлиев рус телендә яза. Алтмышынчы еллар дәвамында аерым хикәяләре, очерклары Мәскәүдә чыгып килүче әдәби журналларда һәм Татарстанда көндәлек матбугатта басыла. Хикәя һәм повестьлары тупланган проза китаплары Казан һәм Мәскәү китап нәшриятларында дөнья күрә.

Диас Вәлиевнең язучылык сәләте драматургия өлкәсендә аеруча ачык чагыла. Интеллигенция тормышыннан алып язылган, кискен конфликтларга корылган «Намус хөкеме» («Суд совести» яки «Охота к умножению») исемле беренче драмасы ук театр дөньясына үзенчәлекле, интеллектлы, караш-фикерләве белән аерылып торган драматург килгәнлеген хәбәр итә. «Дәвам» («Продолжение») исемле героик драмасы тагын да зуррак уңышка ирешә. Социаль-политик яңгырашлы, киң колачлы вакыйгаларга нигезләнгән драма, әдәби әсәр буларак, чын сәнгать биеклегенә күтәрелә. 1976 елда «Дәвам» пьесасы өчен Диас Вәлиевкә Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелә.

Драматургның шуннан соң язылган «Диалоглар» («Диалоги»), «Казанның Елга аръягы күрәзәчесе» («Пророк из казанского заречья»), «Казан университеты» исемле пьесалары Мәскәү, Ташкент һәм башка шәһәрләрнең театрларында куела. Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренә багышланган «Билгесез көн» («День икс») әсәре дә драматургның героик яңгырашлы, яңа сәнгать алымнарына корылган әсәре булды.

Аның «Намус хөкеме» (1971), «Язмышың хәл ителгәндә» (1976), «Үз-үзеңә хыянәт итсәң» (1979) драмалары Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелды.

Диас Вәлиев 1973 һәм 1978 елларда милли драматургия буенча уздырылган Бөтенроссия фестивалендә Беренче дәрәҗә дипломга лаек булды. Аңа 1981 елда — Татарстанның, 1983 елда Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәр бирелде.

1990 еллардан Д.Вәлиев иҗатында сәнгати-фәлсәфи публицистика өстенлек итә. Ул «Мәңгелеккә өч сәяхәт» («Три похода в вечность», 1990) исемле эсселар җыентыгы, «Өченче кеше, яки Фәрештә» («Третий человек, или Небожитель», 1994), «Мөртәд, яки Гольгофага чират» («Изгой, или очередь на Гольгофу», 1996), «Мин» («Я», 1999) романнарын яза.

Д.Вәлиев — 1973 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

### Басылган драма әсәрләре:

**Валеев Д.** Дарю тебе жизнь. (Продолжение): Драм. хроника в 3 ч. — М.: ВУОНТ, 1972. — 81 л.
**Валеев Д.** Охота к умножению: Драма в 3 д. — М.: ВУОАП, 1973. — 80 л.
**Валеев Д.** Пророк из казанского заречья: Трагикомедия в 2 д. — М.: ВАПП, 1975. — С. 173 .
**Валеев Д.** Диалоги: Пьеса в 7 сценах. — М.: ВАПП, 1976. — 57 л.
**Валеев Д.** Суд совести: Драма. — Казань: Таткнигоиздат, 1981. — С. 168.
**Валеев Д.** Диалоги: Пьесы. — М.: Сов. писатель, 1982. — 440 с.
**Валеев Д.** Сад: Повести. Пьесы. — Казань: Таткнигоиздат, 1984. — С. 224.
**Вәлиев Д.** Язмышның чарасы бер генә: Сәхнә әсәрләре. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. — 224 б.

**Аның турында:**

**Харисов М.** Ил язмышы — кеше язмышы // Социалистик Татарстан. — 1973. — 12 гыйнвар.
**Кашшаф Г.** Эре характерлар сурәтләгәндә / Кашшаф Г. Күңел көзгесе. — Казан, 1975. — 172–179 б.
**Илялова И.** Кеше турында кешелекле итеп // Социалистик Татарстан. — 1976. — 1 апрель.
**Гаффар Ә.** Язмыш хәл ителдеме? // Социалистик Татарстан. — 1976. — 18 декабрь.
**Мәхмүтов Һ.** Тормыш бүләк итәм // Татарстан яшьләре. — 1978. — 8 июнь.
**Золоторев Е.** Вөҗдан белән сөйләшү // Социалистик Татарстан. — 1978. — 20 июнь.
**Мәхмүтов Һ.** Диалоглар // Татарстан яшьләре. — 1978. — 13 июнь.
**Мәхмүтов Һ.** Үзеңә хыянәт итсәң // Социалистик Татарстан. — 1979. — 10 апрель.
**Зубков Ю.** Драматурги России. — М.: Современник. 1979. — С. 319.
**Балашова Н.** У истоков // Театр. 1981. № 4. С. 9–12.

## РАЗИЛ ВӘЛИЕВ (1947)

Разил Исмәгыйль улы Вәлиев 1947 елның 4 гыйнварында Татарстанның Түбән Кама (элеккеге Ширәмәт) районы Ташлык авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне туган авылында ала, Түбән Кама урта мәктәбен 1965 елда тәмамлый. Шул ук елда Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керә. Ике курсны тәмамлагач, Татарстан Язучылар берлеге юлламасы белән Мәскәүгә барып, М.Горький исемендәге Әдәбият институтында белем ала.

1972–1981 елларда Р.Вәлиев «Ялкын» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, әдәби бүлек мөдире, җаваплы сәркатибе вазифаларын башкара. 1981–1984 елларда ул Чаллы Язучылар оешмасының сәркатибе, 1984–1986 елларда Татарстан Язучылар берлегенең идарә рәисе урынбасары, 1986–2000 елларда Татарстан Республикасының Милли китапханә директоры булып эшли.

Разил Вәлиев шагыйрь, язучы, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе буларак танылды. Аның «Зәңгәр кабырчыклар» (1971), «Яшен тамыры» (1977), «Ядкарь» (1987), «Бер алманы бишкә бүләек» (1992), «Кышкы учак» (1994), «Сүзләрдән дисбе» (1996) шигырь җыентыклары; «Эт кояшы», «Яшисе килә» (1982) һ.б. повестьлары һәм «Мирас» (1990) романы дөнья күрде. Әдипкә «Яшисе килә» повесте һәм популяр җырлары өчен 1982 елда Муса Җәлил исемендәге Республика бүләге тапшырылды.

Р.Вәлиевнең иҗаты драматургия белән дә бәйле. Аның «Әйдә барыйк, кызлар карыйк!» (1988–1989), «И машина, машина, җитте минем башыма» (1990), «Куркыныч уен» («Шомбай», 1989) һ.б. пьесалары 4 томда басылып чыккан «Сайланма әсәрләр»дә (1999–2000) урын алды. Р.Вәлиев пьесаларына куелган спектакльләр К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында, шулай ук республиканың башка театрларында уңыш казанды.

Р.Вәлиев киңкырлы эшчәнлеге өчен «Планетада цивилизацияне, яшәешне һәм мәдәниятне саклауга һәм үстерүгә керткән хезмәтләре өчен» халыкара көмеш медаль белән бүләкләнде.

Р.Вәлиев — Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре (1990, 1997), Россия Гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле академигы (1997), Татарстан Югары Советы депутаты (1990–1995), 1995 елдан Татарстан халык депутаты, 2000 елдан Татарстан Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе.

Ул — 1979 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Вәлиев Р.** Сайланма әсәрләр: Сәхнә әсәрләре, мәзәкләр һәм тәрҗемәләр. — 3 т. — Казан: Милли китап, 2000. — 463 б.
**Вәлиев Р.** Әсәрләр 4 томда. — 3 т. Пьесалар, язмалар, әдәби тәрҗемәләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 478 б.

**Аның турында:**

**Галиев Н.** Язмышка рәхмәт // Казан утлары. — 1997. — № 1. — 154–159 б.
**Хәйри Ә.** Рухи мирасыбыз сакчысы // Мәдәни җомга. — 1997. — 21 февраль.
**Госманов М.** Алтын бусаганы атлаганда // Шәһри Казан. — 1997. — 21 февраль.
Татар энциклопедия сүзлеге / Баш мөхәррир Хәсәнов М.Х. — Казан: Татар энциклопедия институты, 2002. — 139 б.
**Даутов Р.** Балачак әдипләре: Р.Вәлиев һ.б. әдипләр турында. — Казан: Мәгариф, 2003.

## ЯРУЛЛА ВӘЛИ (1879–1937)

Ярулла Вәлиулла улы Вәлиев элекке Самара губернасының Бозаулык каласында сәүдәгәр гаиләсендә туа. Берара сәүдә эше белән шөгыльләнә. Шул ук вакытта язучы һәм драматург буларак та таныла. 1906–1918 елларда «Вакыт» басмаханәсе»нең мөдире һәм мөхәррире вазифаларын башкара.

Я.Вәлине драматург итеп «Оят, яки күз яше» (1902) һәм «Ачлык кушты» (1908) исемле пьесалары таныта. Драмалар 1907 һәм 1911 елларда «Сәйяр» театры артистлары тарафыннан сәхнәләштерелә һәм төрле шәһәрләрдә күп мәртәбәләр уйнала. Спектакльләргә карата татар һәм рус газеталарында хуплау мәкаләләре басылып чыга. «Ачлык кушты» пьесасы 1908 елда аерым китап булып дөнья күрә. Әсәрдә ачлык вакытында газиз кызларын чит-ят җирләргә сатып җибәрергә мәҗбүр ителгән бәхетсез гаилә тарихы гәүдәләндерелә. Гомумән, тормыштан алып язылган сәхнә әсәрләре белән Ярулла Вәли татар драматургиясенең формалашу этабында үзенчәлекле урын алып тора.

Революциядән соң Ярулла Вәли гаиләсе белән Уфада яши. Баштарак мөфтияттә, аннары бер оешмада хисапчы булып эшли. Кайчандыр татар дөньясын шаулатып алган әдип репрессияләр чорында кулга алына һәм аның эзе 1937 елдан югала. Хөкем карары билгесез.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Вәли Я.** Оят, яки күз яше: Драма 4 пәрдәдә. — Оренбург, 1902. — 66 б.
**Вәли Я.** Ачлык кушты: Драма 5 пәрдәдә. — Оренбург: Шәрык, 1908. — 35 б.

**Аның турында:**

**Рәми И., Даутов Р.** Әдәби сүзлек: Элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 69 б.
**Хәмидуллин Л.** Ачык фикерле зат... / Хәмидуллин Л. Ак төннәр хәтере. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 86–91 б.

## МӘХМҮТ ГАЛӘҮ (1886–1938)

Мәхмүт Галәү (Мәхмүт Галәветдин улы Мәрҗани) 1886 елның сентябрендә элекке Казан губернасы Арча кантоны Ташкичү авылында ярлы хәлфә гаиләсендә туа. Башлангыч белемне әтисеннән алгач, унбер яшендә Казанга килә һәм 1897–1903 еллар арасында бер кадими мәдрәсәдә укый. Мәдрәсәне тәмамлагач, ул 1904 елдан Әстерхан өлкәсенең татар бистәсендә балалар укыта башлый. Шул ук вакытта Бакуда чыга торган «Шәркый Рус» газетасына мәкаләләр яза, Әстерханда «Туп» журналын чыгаруда катнаша.

1907 елда М.Галәү Оренбургка күчә һәм нәшрияттә, типографиядә эшли. Үзе катнашкан газета-журналларда мәгариф эшенең торышы хакында җитди мәсьәләләр яктырта. 1911 елда беренче сыйныф шәкертләре өчен махсус «Төрки уку» китабын бастыра.

1914–1918 елларда Оренбургта «Белек» исемле китап нәшрияты һәм сәүдәсе ача. 1915–1917 елларда «Кармак» исемле сатирик журнал чыгара.

Октябрь революциясен М.Галәү Оренбургта каршылый һәм җаваплы эшләр башкара. 1925 елда Мәскәүгә наборщикларның үзәк мәктәбен оештырырга чакырыла. Шул елдан башлап ул Мәскәүдә яши һәм 1926 елдан бары иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

М.Галәүнең берничә драма әсәре мәгълүм: ул 1924 елда бер-бер артлы «Курчак туе», «Иван баҗай», халык җитәкчесе образын үзәккә алган «Пугач явы» һәм тарихи алмашынулар чорында татар зыялыларының катлаулы язмышын чагылдырган «Салам-торханнар» исемле пьесалар яза. Шулардан «Пугач явы» әсәре һәм «Иван баҗай» комедиясе 1926–1928 елларда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала.

Әдипнең 1912 елда «Ник язылганнар?» исемле тәрҗемә һәм оригиналь шигырьләр җыентыгы, 1926–1931 еллар арасында «Каяу», «Төеннәр», «Канлы тамгалар», «Чүлмәк тулгач», «Күпнең берсе» исемле хикәя җыентыклары нәшер ителә. М.Галәүнең «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» исемле зур күләмле әсәрләре 1930–1934 елларда русчага тәрҗемә ителеп, «Муть» һәм «Мухаджиры» исемнәре белән Мәскәү нәшриятларында басыла. Планлаштырылган эпопеяның соңгы ике томы язылмыйча кала.

Тәрҗемәче буларак ул А.Пушкин, Л.Толстой, Ю.Лермонтов әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

Сталинның шәхес культы М.Галәүне дә читтә калдырмый. Сорау алу өчен әдип Мәскәүдән Казанга кайтарыла һәм гомере 1938 елның 12 ноябрендә өзелә. Үзе белән бергә шәхси архивы, басылмаган әсәрләренең кулъязмалары да югала.

М.Галәүнең исеме 1956 елда реабилитацияләнә.

Ул 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Галәү М.** Пугач явы: XVIII гасырның соңгы яртысында булып узган вакыйгада. — М.: СССР халыкларының үзәк нәшр., 1926. — 143 б.

**Галәү М.** Салам-торханнар: Пьеса 3 пәрдәдә, 4 күренештә. — М.: Нәшрият, 1926. — 91 б.

**Галәү М.** Төеннәр: Хикәяләр һәм пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986, — 350 б.

**Аның турында:**

**Фәйзи Ә.** Мәхмүт Галәү / Фәйзи Ә. Әдипнең эрудициясе. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1973. — 113–118 б.

**Ганиева Ф.** Әдип гомере: Мәхмүт Галәүнең тууына 90 ел // Казан утлары, 1976. — № 9. — 133–144 б.

**Ганиева Ф.** Мәхмүт Галәү / Татар әдәбияты тарихы 6 томда. — 4 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 200–212 б.

## ГАРИФ ГАЛИЕВ (1903–1985)

Гариф Закир улы Галиев 1903 елның 10 маенда Татарстанның Азнакай районы Урманай авылында туа. Җиде яшьлек Гарифны заманы өчен алдынгы саналган Бәйрәкә мәдрәсәсенә укырга бирәләр, шунда ул беркадәр дөнья фәннәрен өйрәнә, әдәбиятны да бик яратып укый. 1917 елдан соң мәдрәсә каршында драма түгәрәге оештырылып, тирә-як авылларда спектакльләр куеп йөри башлыйлар. Гариф Галиев анда иң актив «артистларның» берсе була. Әдәбият-сәнгать белән мавыгуы Бөгелмә шәһәрендәге өчьеллык укытучылар семинариясендә укыганда тагын да көчәя, ул түгәрәкләр эшендә актив катнаша, шул чорда иҗатка омтылыш та уяна. 1921 елгы ачлык аны укуын ташлап туган авылына кайтырга мәҗбүр итә, анда авыл Советы сәркатибе булып эшли, Казанда чыга торган «Крестьян газетасы»на хәбәрләр яза. Армиядә хезмәт итеп кайткач, аны Бөгелмәдә чыга торган «Сабанчы» газетасына эшкә чакырып алалар. 1930 елдан ул Казанда яши, төрле газета-журнал редакцияләрендә җаваплы сәркатип булып эшли.

Утызынчы елларда Гариф Галиевнең иҗат эшчәнлеге активлаша. 1931–1941 еллар эчендә тугыз китабы дөнья күрә. Аның үз чоры өчен популяр әсәрләре «Фамилиясез кеше», «Бибкәй аланы» аерым китаплар булып басылып чыга.

Бөек Ватан сугышында ул фронт газеталарында җаваплы сәркатип була. Кызыл Йолдыз ордены, күп кенә медальләр белән бүләкләнә.

Гариф Галиев драматургия жанрында да актив иҗат итә. Аның дистәдән артык кечкенә күләмле пьесалары бар. Алар күбесе үзешчән сәнгать коллективлары тарафыннан яратып уйналалар. Аеруча «Хаттан башланды» дигән бер пәрдәлек комедиясе популяр була, рус һәм немец телләрендә басылып чыга.

Ул 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Галиев Г.** Ялкын: Колхоз сәхнәләре өчен бер пәрдәлек пьеса. — Казан: Татгосиздат, 1941. — 28 б.

**Галиев Г.** Началось с письма: Пьеса в 1 действии. — М.: Музфонд СССР, 1949. — 23 с.

**Галиев Г.** Одноактные пьесы. — Казань: Татгосиздат, 1962. — 39 с.

**Аның турында:**

**Иделле Г.** Гариф Галиев иҗаты турында берничә сүз / Иделле Г. Язучы һәм аның китабы. — Казан, 1964. — 114–123 б.

**Ихсанова Л.** Җир җаны: Г.Галиевкә — 80 яшь // Социалистик Татарстан. — 1983. — 11 май.

**Хәйри Х.** Яңа авыл җырчысы // Казан утлары. — 1983. — № 5. 153–154 б.

## ФӘНӘВИЛ ГАЛИЕВ (1960)

Фәнәвил Мөхлис улы Галиев 1960 елның 4 гыйнварында Арча районының Әзәк авылында туа. 1978 елда Тукай-Кырлай урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт мәдәният институтының режиссура бүлегенә укырга керә.

1982–1992 елларда К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында артист һәм режиссер булып эшли. 1993 һәм 1996 елларда Мәскәү МХАТ студиясендә артистлык осталыгын күтәрүдә, 2000 елда О.Табаков театры студиясендә режиссура буенча укуларда була.

Драматург буларак Ф.Галиев беренче адымнарын К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында куелган «Элмәктәге язмыш» пьесасы белән башлый. Хәзерге вакытка Ф.Галиевнең Татарстан, Башкортстан һәм Чуашстан республикаларында ике дистәгә якын пьеса, тәрҗемә һәм инсценировкалары куелды.

Әдипнең «Корт» пьесасы 2003 елда Татарстан Мәдәният министрлыгының Мәскәү тәнкыйтьчеләре белән берлектә үткәрелгән драматурглар семинарында «Иң яхшы пьеса» дип табылды.

Фәнәвил Галиевнең 2003 елда «Яңа татар пьесасы» конкурсында «Тутык кыңгырау» әсәре җиңүче пьесалар рәтенә керде һәм «Яңа татар пьесасы» җыентыгында басылды. Ә 2004–2005 елда үткәрелгән «Яңа татар пьесасы» конкурсында аның М.Галәүнең «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» романнары буенча эшләнгән инсценировкасы беренче урынны алды.

Фәнәвил Галиевнең пьесалары Әлмәт, Минзәлә, Чаллы, Казан яшь тамашачылар театр сәхнәләрендә, Туймазы, Чуашстан республикасы яшь тамашачылар һәм халык театрларында бара.

Әдипнең пьесаларында төрле темалар күтәрелә. «Хыялый буйдак» комедиясендә авторның мәхәббәт темасы яңа яңгыраш ала. Драматургның әсәрләрендә җитди иҗтимагый мәсьәләләргә зур игътибар бирелә. Ф.Галиев тарафыннан XX гасырның ахыры — XXI гасыр башы яшьләренең тормышка карашы, яшәү максаты, әхлак, тәрбия, намус төшенчәләренә мөнәсәбәте «Узма, яшьлек, заяга» пьесасында күрсәтелә. Балалар йортында тәрбияләнгән, гаилә бәхетен татымаган яшүсмерләрнең язмышы, аларның алдагы тормышы темасына «Хыялдагы дөнья» пьесасы багышлана. Тирән психологизм, фәлсәфилек аша драматург җәмгыятьнең әлеге балалар алдындагы җаваплылыгы хакында искәртә.

Әдипнең дини-фәлсәфи темага язылган «Фәрештә белән сөйләшү» әсәре дә дөнья күрде.

Ф.Галиевнең татар язучыларының чәчмә әсәрләрен сәхнәдә күрү теләге тормышка ашырыла. Әдип И.Салаховның «Тайгак кичү» романы буенча пьеса иҗат итә. Балалар дөньясы да автор игъти-

барыннан читтә калмый. Аның «Мисс убырлы», «Тегермәнче җыры», «Мияүбәк һәм Чигиетта», шулай ук М.Җәлилнең «Джим» шигыреннән пьеса эшләнде.

Ф.Галиевкә 2003 елда «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Ул — 2000 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Галиев Ф.** Тутык кыңгырау: Яңа татар пьесасы 3 томда. — 2 т. — Казан: Идел-Пресс, 2004. — 175–205 б.

**Галиев Ф.** Яңа ел әкияте: Чыршы бәйрәмен үткәрү // Ялкын. — 1995. — № 12. — 20–23 б.

**Галиев Ф.** М.Галәүнең «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» дилогиясе буенча эшләнгән инсценировка: Яңа татар пьесасы 3 томда. — 3 т. — Казан: Идел-Пресс, 2005. — 272–332 б.

**Аның турында:**

**Сәгъди Р.** Арча ягы егете // Арча хәбәрләре. — № 114. — 1999. — 17 ноябрь.

**Мөхәммәтова Р.** Мәхәббәтле сәхнә, сәхнәле мәхәббәт // Сәхнә. — 2004.

**Иванычева Л.** Легко ли Чехову заговорить по татарски // Казанские ведомости. — 1998. — № 216. — 14 ноябрь.

**Тарханова Ф.** Көлеп карыйк, ичмасам // Татарстан хәбәрләре. — 1992. — № 65. — 1 апрель.

Яшәвемнең кадере артты // Юлдаш. — 2006. — № 36. — август. (Фәнәвил Галиев белән әңгәмә.)

**Таңчулпан.** Мин хыялда яшим // Шәһри Казан. — 1997. — № 210. — 31 март.

## ӘКРАМ
## ГАЛИМОВ
## (1892–1913)

Әкрам Миңнегали улы Галимов 1892 елның 14 ноябрендә Казахстанның Кустанай шәһәрендә хәлфә гаиләсендә туа. Әкрамның әтисе — татар, әнисе казакъ кызы була. Булачак әдип ике телне дә яхшы үзләштерә. Ул унөч яшенә җиткәч, гаилә Троицк шәһәренә күчеп килә. Әкрам Кустанай һәм Троицк мәдрәсәләрендә белем ала. Троицкида казакъ телендә нәшер ителүче «Айкап» журналын оештыруда катнаша, 1911–1913 елларда журналның сәркатибе булып эшли. 1912–1913 елларда «Акмулла» (Троицк) татар сатирик журналының да төп авторларыннан һәм әдәби хезмәткәрләреннән берсе була. Татар һәм казакъ телләрендәге шигырьләре һәм мәкаләләре «Акмулла», «Шура», «Айкап», «Кармак» журналларында, «Идел» газетасында басыла.

Ә.Галимовның бердәнбер сәхнә әсәре — «Май мәсьәләсе» исемле комедиясе — 1913 елда татар телендә нәшер ителә. Пьеса сәхнәдә 1919 елда «Нур» артистлары тарафыннан уйнала.

Ә.Галимов бик яшьли — 1913 елның 7 августында вафат була.

**Басылган драма әсәре:**

**Галимов Ә.** Май мәсьәләсе, яхуд надан мулла. Көлке 1 пәрдәдә. — Троицк: Хезмәт, 1913. — 27 б.

**Аның турында:**

**Рәми И., Даутов Р.** Әдәби сүзлек: Элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 74–75 б.

**Ханзафаров Н.** Әкрам Галимов. Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы). Биобиблиографик сүзлек. — Казан, 2005. — 65–66 б.

## ӘХӘТ
## ГАФФАР
## (1948)

Әхәт Гаффар (Гаффаров Габделәхәт Габдрахман улы) 1948 елның 23 декабрендә (рәсми документларда — 1949 елның 1 гыйнварында) Татарстанның Балык Бистәсе районы Олы Әшнәк авылында дөньяга килә. Туган авылындагы сигезьеллык һәм Олы Солтан авылында урта мәктәпне тә-

мамлаганнан соң, 1966 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. 1971 елда кулына диплом алган яшь белгеч 1981 елга кадәр көндәлек матбугатта хәбәрче-корреспондент, «Казан утлары» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире булып эшли. Әдипнең мәкаләләре «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй»), «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газеталарында басыла. 1982–1987 елларда Ә.Гаффар Татарстан язучыларының Әлмәт оешмасын җитәкли. 1987–1990 елларда Татарстан Мәдәният фонды рәисе урынбасары, шуннан соң «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Мәгърифәт» газеталарында, «Казан», «Мирас» журналларында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире вазифаларын башкара.

1970 елларда Ә.Гаффар проза һәм драматургиядә көчен сыный. «Әҗәт» (1972) исемле беренче хикәясеннән соң «Яра» (1973), «Гозер» (1975), «Кашан җыры» (1977), «Су астындагы чишмә» (1980), «Бишек» (1981), «Яшиселәр алда әле» (1984), «Дәрья башы» (1986) һ.б. повестьлары дөнья күреп, аны тирән эчтәлекле, сәнгать алымнарына бай әсәрләр иҗат итүче язучы буларак таныта.

1983 елда әдипнең «Бабай чишмәсе» повесте нәшер ителгәннән соң әлеге әсәр «Юность» журналында (1983, № 2) чыккач, «Советская литература» журналында полякча басыла. Аннан чех, словак, немец, француз, испан, инглиз, венгр, япон телләренә дә тәрҗемә ителә. Ә.Гаффар «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» (1983), «Олы юлның тузаны» (1989), «Богау» (1998) романнары белән дә таныла.

1990–2000 еллар арасында Ә.Гаффарның «Нәсел» (1998), «Шулай яшәп ятмыш» (1999), «Дәрья башы» (2002), «Әллә тагын» (2003), «Энә күзе» (2005) һ.б. хикәяләре һәм повестьлары дөнья күрде.

Әдәбият мәйданында Ә.Гаффар үзен оста драматург икәнлеген раслады. Аның «Иртәгә улың булам» (1977), «Язлар моңы» (1978), «Җиләк вакыты бер генә» (1978), «Өч сорауга бер җавап» (1981), «Бер картлыкта, бер яшьлектә» (1981), «Мунча көне» (1982), «Сызылып таңнар атканда» (1984) һ.б. пьесалары Казан, Чаллы, Минзәлә, Оренбург һ.б. дәүләт театрларында сәхнәләштерелә.

Драматургның пьесаларында тарихи шәхесләр образлары да гәүдәләндерелә. Алар арасында Мулланур Вахитовка багышланган «Сызылып таңнар атканда», Габдулла Тукайның тормышын чагылдырган «Соңгы сәгать», Муса Җәлилнең батырлыгын тасвирлаган «Хөкем» драмалары бар. Әдипнең «Соңгы сәгать» (1986) пьесасы образлар системасы, композициясе, сәнгать алымнары белән аерылып тора. Биредә татар халкының бөек улының соңгы сәгате сурәтләнә. Әлеге сәгать эчендә авторның иҗат фантазиясе ярдәмендә Г.Тукай, үткәнгә — балалык елларына һәм киләчәккә сәфәр кылып, төрле чор әдипләре белән очраша. Әдипнең эчке дөньясын ачу өчен, Ә.Гаффар, үткәнгә кайту алымыннан файдаланып, кечкенә Апуш белән олы шагыйрь сөйләшүеннән Г.Тукайның еллар буе күңеленә җыелган уйларын, үпкә-сагышларын, сызлануларын укучыга һәм тамашачыга җиткерүгә ирешә.

Әхәт Гаффарның «Соңгы сөю» һәм «Хөкем» пьесалары, телеспектакль буларак, 1983 һәм 1986 елда Казан телевидениесе аша тапшырылды.

Әдипнең балалар өчен язылган «Кояш тотылганда» (1986) һәм дистәгә якын бер актлы пьесалары дөнья күрде.

Драматургның иҗтимагый-сәяси тормышка карашы төрле жанрларда чагыла. Әхәт Гаффар — иллегә якын памфлет, йөзләрчә публицистик мәкаләләр авторы. Әфганстандагы вакыйгаларны тәнкыйть призмасы аша үткәреп, әдип «771 аршын җир» (1991) публицистик китабын нәшер итә. Чечен сугышының кайтавазы авторның «Күзләремне тутырып» (2005) фаҗигасендә гадәти татар авылы тормышында сурәтләнә. Әлеге пьеса сугыштан имгәнеп кайткан солдатның мәхәббәт тарихы хакында.

Ә.Гаффар — 1985 елда Мәскәүдә русча басылып чыккан «Долг» китабы өчен М.Горький исемендәге Бөтенсоюз әдәби конкурсы лауреаты. 1990 елда аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Ул — 1975 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Гаффар А.** Один из четверых. Романтическая драма // М.: ВААП-информ, 1983.
**Гаффар Ә.** Кояш тотылганда: Драматик поэма // Ялкын. — 1980. — № 6 — 7.
**Гаффар Ә.** Язлар моңы: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. — 184 б.
**Гаффар Ә.** Сызылып таңнар атканда: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. — 296 б.

**Аның турында:**

**Приставкин А.** К народной поэтике // Мы — молодые. М.: 1976. С. 41.
**Скульская Е.** «Мы — молодые...» [«Долг»] // Сов. Эстония (Таллинн). — 1976. — 9 дек.
**Бәширова И.** Әҗәт // Казан утлары. — 1977. — № 1. — 157–168 б.
**Мостафин Р.** Төптәнрәк уйлаганда! // Казан утлары. — 1977. № 1. — 157–168 б.
**Гыймранова Д.** Язлар моңы: Ә.Гаффарның шул исемдәге пьесасы Минзәлә татар дәүләт драма театрында // Социалистик Татарстан. — 1978. — 29 август.
**Сверигин Р.** Төсләр һәм кешеләр // Казан утлары. — 1982. — № 7. — 165–167 б.
**Скарлыгина Е.** Долг // Лит. обозрение. — 1984. — № 7. — С. 81–82.
**Рощектаев В.** О долге и любви // Веч. Казань. — 1984. — 28 февр.
**Тур В.** Поиск // Совр. драматургия. М., 1984. — № 2.
**Егорова Н.** Смотри и помни: [«Глоток воды»] // Лит. Россия. — 1986. — 15 февр.
**Алексеева Т.** С верой в человека: [«Глоток воды»] // Лит. газета. — 1986. — 28 май.
**Төхфәтуллин Р.** Оптимистик трагедия // Социалистик Татарстан. — 1988. — 2 апрель.
**Бәдигый Х.** Күңел аҗаганнары: Әхәт Гаффар портретына штрихлар // Мәгърифәт. — 1998. — 5 декабрь.
**Гыйльманов Г.** Халыкчан иҗат иясе. Язучы Әхәт Гаффарга — 50 яшь // Казан утлары. — 1999. — № 1. — 118 б.
Татар әдәбияты тарихы 6 томда. — 6 т. — Казан: Раннур, 2001. — 368–373 б.
**Нуруллин Ф.** Талантлы әдип. Язучы Ә.Гаффар иҗатына бәяләмә // Мирас. — 2004. — № 8. — 65–68 б.
**Садә Г.** Язлар моңы ил урый // Шәһри Казан. — 2005. — 17 июнь.
**Рахман Г.** Ырынбурның «Язлар моңы» // Ватаным Татарстан. — 2005. — № 82.
Язлар моңы. Әхәт Гаффарның «Язлар моңы» драмасы Ырынбур татар дәүләт драма театрында // Мәдәни җомга. — 2005. — № 18.
**Әхмәтҗанов М.** Энә күзенә сыйган хәят // Мәдәни җомга. — 2006. — 1 декабрь.

## МӘҖИТ ГАФУРИ (1880–1934)

Мәҗит Гафури (Габделмәҗит Нургани улы Гафуров) 1880 елның 20 июлендә (яңа стиль белән 1 августта) Уфа губернасы Эстәрлетамак өязе Җилемкаран авылында (хәзер Башкортстанның Гафури районы) хәлфә гаиләсендә туа. Башта авыл мәдрәсәсендә, аннан күрше Үтәш авылы мәдрәсәсендә укый. Мәдрәсәдә укыганда 13 яшьлек Мәҗит зур кайгылар кичерә: бер-бер артлы әти-әнисе үлеп китә һәм аның өчен авыр тормыш башлана. Ул мәдрәсәдә бай малайларына аш пешереп, самавыр куеп, кулъязма китаплар күчереп яшәргә мәҗбүр була.

1896 елның көзендә Уфадагы «Госмания» һәм Кыешкы авылындагы мәдрәсәләргә кереп карый, ләкин тормыш авырлыгы аны кабат туган якларына кайтара. Җәйләрен байларга ялланып эшли, көз һәм кышларын мәдрәсәләрдә укый, авыл хәлфәләренә ярдәм итә. Урал таулары арасында Лапашты дигән урында чуен заводы төзелешендә балчык ташучы булып эшли.

1898 елда Троицк шәһәрендәге Зәйнулла ишанның «Рәсүлия» мәдрәсәсенә барып урнаша. Җәйләрен төрле эшләрдә ялланып йөри. Миллионер Яушевларның торф, Рәмиевләрнең алтын приискаларында эшли, казакъ авылларына барып балалар укыта.

Троицк мәдрәсәсендә укыганда, беренче әдәби тәҗрибәләре туа. 1902 елда «Ишан шәкертләре» шигыре, «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» исемле повесте, 1902–1904 еллар арасында «Себер тимер юлы», «Яшь гомерем» һ.б. дидактик поэмалары языла.

1905 елның августында М.Гафури Казанга килә һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый башлый. 1906 елны Уфаның «Галия» мәдрәсәсенә күчә һәм анда бер ел — рәсми шәкерт, ике ел ирекле тыңлаучы булып йөри. 1909–1912 еллар арасында фәкать язу эше белән генә шөгыльләнә. Казан һәм Уфа нәшриятларында әдипнең дистәгә якын шигырь китабы, тугыз хикәя җыентыгы, матбугатта күп кенә мәкаләләре басыла.

1912 елның языннан алып 1917 елның октябренә кадәр М.Гафури Уфада Кәримовларның «Шәрык» матбагасында корректор булып эшли.

Октябрь революциясен М.Гафури хуплап каршы ала. Совет чорында «Эшче» (1920) поэмасы, «Кара йөзләр» (1926) повесте, «Тормыш баскычлары» (1927), «Шагыйрьнең алтын приискасында» (1929) кебек автобиографик характердагы проза әсәрләре языла. («Кара йөзләр» повесте, сәхнә варианты итеп үзгәртелеп, 1955 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала.)

М.Гафури драматургия өлкәсендә дә көч сынап карый. Гражданнар сугышы һәм аннан соңгы тормышны төзү чорын тасвирлаган «Кызыл йолдыз» (1925) драмасы белән татар театры үсешенә үзенең өлешен кертә. 1925 елда татар театры тарафыннан сәхнәләштерелгән пьеса үз заманында җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алына һәм Башкортстан Мәгариф комиссариаты уздырган конкурста беренче дәрәҗә премия белән бүләкләнә.

Гафуриның егерменче елларда иҗат иткән икенче сәхнә әсәре — 1928–1929 елларда язылган «Эшче» операсының либреттосы. Операга музыканы Г.Әлмөхәммәтов, С.Габәши һәм В.Виноградовлар яза һәм ул 1930 елда Казанда сәхнәгә куела.

1923 елда М.Гафуриның егерме еллык иҗат бәйрәме зурлап уздырыла һәм шул уңай белән «Башкортстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелә.

Аның әсәрләре татар, башкорт, рус һәм башка телләрдә күп мәртәбәләр нәшер ителә.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Гафури М.** Әсәрләр. 4 томда. — 2 т. Шигырьләр һәм сәхнә әсәрләре (1917–1934). — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — 598 б.

**Аның турында:**

**Хисмәтуллин Г.** Мәҗит Гафури / Татар Совет әдәбияты тарихы: Очерклар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 345–370 б.

**Нигъмәтуллин Ә.** Мәҗит Гафури: Иҗаты турында очерк. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1969. — 94 б.

**Халит Г.** Тормыш һәм ирек җырчысы: М.Гафуриның тормышы һәм иҗаты турында очерк. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — 184 б.

Мәҗит Гафури: Тууына 100 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары / Редкол. Н.Юзиев һ.б. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. — 151 б.

**Рамазанов Г., Юзиев Н.** Мәҗит Гафури. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. — 4 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 50–67 б.

## ГАРИФ ГОБӘЙ (1907–1983)

Гариф Гобәй (Гариф Шакир улы Гобәйдуллин) 1907 елның 26 августында Казанның Бишбалта бистәсендә һөнәрче гаиләсендә туа. Гариф бик яшьли белем мәктәбе белән хезмәт мәктәбен бергә үтә: типографиядә хәреф җыючы, трамвай йөртүче, соңрак балалар йортында тәрбияче булып эшли. 1927–1930 елларда Татрабфакны тәмамлап, Казан педагогия институтына укырга керә. Институтны 1936 елда тәмамлап, берничә ел мәктәптә балалар укыта. Аннары Татиздатта, «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә, Татарстан радиокомитетында һәм 1941–1946 елларда радиокомитетның рәисе булып эшли. 1950–1953 елларда ул — Татарстан Язучылар берлеге рәисе. 1953 елдан башлап Г.Гобәй — профессиональ язучы.

Г.Гобәй утызынчы еллардан алып балалар әдәбияты өлкәсендә актив иҗат итә. Аның сыйнфый көрәш темасын яктырткан «Каланча» (1934), Германия балаларының фашизмга каршы көрәшен тасвирлаган «Без әле очрашырбыз» (1935), гражданнар сугышы вакыйгаларын чагылдырган «Маякчы кызы» (1938) һәм «Ялгыз йортта» (1939) исемле повестьлары языла. Аеруча «Маякчы кызы» повесте әдипкә зур популярлык китерә.

Ватан сугышы алдыннан Г.Гобәй драматургия жанрына да мөрәҗәгать итә. Гражданнар сугышы темасын яктырткан «Аклар лагеренда» (1937), уяулык, туган илгә тугрылык һәм патриотизм темасы белән сугарылган «Өч бөркет» (1941) исемле пьесаларын яза.

Ватан сугышы елларында совет халкының батырлыгын яктырткан «Замана балалары» (1946–1947), «Маратның язмышы» (1953–1955) повестьлары, тәрбия мәсьәләсен күтәргән «Ләйсән яңгыр» (1957–1960) һәм тарихи-революцион темага багышланган «Без үскәндә» (1956–1962) повестьлары татар балалар әдәбияты тарихында күренекле урын алып тора.

Г.Гобәй — әдәби тәрҗемә өлкәсендә, татар әдәбиятын дөнья әдәбияты җәүһәрләре белән баетуда да актив эшләгән әдип.

Г.Гобәйнең аерым әсәрләре рус, чуаш, уйгыр, казакъ телләренә тәрҗемә ителеп, Казан һәм Мәскәү нәшриятларында басыла.

Татар балалар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләрен югары бәяләп, Г.Гобәй хөкүмәт тарафыннан ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы (1950, 1957), Октябрь революциясе (1977), «Почет Билгесе» орденнары һәм берничә медаль белән бүләкләнә.

Ул 1938 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Аның турында:**


**Ибраһимова Ф.** Фикерләрем китапларымда // Казан утлары. — 1977. — № 8. — 128–133 б.
**Тәрҗеманов Җ.** Балалар дөньясы аксакалы // Ялкын. — 1977. — № 8. — 6–7 б.
**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 129–131 б.
Советские детские писатели: Библиограф. словарь. — М., 1961. О Г.Губае. С. 112.
**Иделле Г.** Любимый писатель наших дней. Г.Губаю 60 лет // Сов. Татария. — 1967. — 26 авг.


## ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ (1895–1955)

Татар совет драматургиясенә нигез салучыларның берсе Таҗи Кәлимулла улы Гыйззәтов 1895 елның 3 сентябрендә Татарстанның Әгерҗе районы Барҗы Умга авылында ярлы гаиләдә туа. Башта остабикәгә сабакка йөри, аннары үз авылларында ачылган яңача мәктәптә дә ике ел укып ала.

Җирсезлектән интеккән Кәлимулла абыйны авыр тормыш алпавыт урманын рөхсәтсез кисәргә мәҗбүр итә. Шуның өчен аны төрмәгә ябалар, каторгага сөрәләр. Боларга түзә алмыйча, ул авырый башлый һәм гүр иясе була. Әлеге хәлләрне Таҗи авыр кичерә. Шул ук вакытта бу вакыйгалар киләчәктә язылачак әсәрләрдә гәүдәләнәчәк сурәт һәм вакыйгаларга чыганак булып тора.

Гаиләдә ир затыннан иң өлкәне булып калган Таҗи, 1910 елда укуын ташлап, хезмәткә яллана. Башта Глушерма, Бондюг, Воткинск якларында сезонлы эшләрдә йөри, аннары 1913 елда Ижевск шәһәрендәге корал заводына урнашып, алты ел шунда эшли.

1917 елның җәендә егерме ике яшьлек Таҗины Ижевск шәһәрендә оешкан һәвәскәр театр труппасына суфлер итеп чакыралар. Акрынлап, суфлерлык эшеннән тыш, спектакльләрдә рольләр дә уйный башлый. Кызыл Армиядә хезмәт иткәндә дә (1919–1920) гаскәриләр оештырган үзешчән театрларда актив катнаша. Егетнең күренеп торган сәләтен үстерү өчен Самара шәһәрендәге татар драма студиясенә укырга җибәрәләр. Биредә ул актерлык һөнәрен камилләштерүдән тыш, рус, Европа театр сәнгате тарихы һәм әдәбияты белән якыннан таныша.

Студияне тәмамлагач, Таҗи Гыйззәт бер ел чамасы үзенең остазы Кәрим Тинчурин җитәкчелегендәге театр труппасы составында Оренбургта эшли. 1921 елгы ачлык вакытында труппа таралгач, Урта Азиянең мәгариф учреждениеләрендә, аннары Казанга килеп Татар дәүләт театрында хезмәт итә. 1923–1925 елларда Ульяновск шәһәренең Татар клубында артист һәм режиссер, 1925–1929 елларда Алабуга һәм Мәскәү татар театрларында артист, режиссер һәм башка вазифаларны башкарганнан соң, 1929 елның көзендә яңадан Казанга кайта һәм шунда төпләнеп кала. 1950 елга кадәр ул Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында артист һәм бер үк вакытта — утызынчы еллар уртасыннан башлап — театрның сәнгать советы әгъзасы булып эшли. Бөек Ватан сугышы чорында (1942–1944) Таҗи Гыйззәт Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе вазифаларын башкара.

Театрда егерме җиде ел эшләү дәверендә Таҗи Гыйззәт рус һәм дөнья әдәбияты классиклары, татар драматурглары, шул исәптән үзенең дә әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә катнашып, истә калырдай дистәләрчә оригиналь сәхнә образлары тудыра.

Шулай да ул, иҗади шәхес буларак, татар театр сәнгате тарихында иң беренче чиратта үзенең әдәби хезмәтләре — сәхнә әсәрләре белән данлыклы.

Драматург буларак Т.Гыйззәтне тормыш иптәше Мәликә Гыйззәтова бенефисына язылган «Талир тәңкә» (1922) пьесасы таныта. Революциягә кадәрге крестьяннар тормышыннан алып язылган, киеренке драматик конфликтка нигезләнгән әлеге драма 1923 елның мартында Татар дәүләт театры сәхнәсендә куела һәм тамашачы тарафыннан яратып кабул ителә, рус теленә дә тәрҗемә ителеп

басыла. Утызынчы елларда автор бу пьеса өстендә эшли, сюжет сызыкларын драматик яктан тагын да камилләштерә төшә, драмага яңа образлар, яңа вакыйгалар кертә, халыкчан рух өсти, әсәрнең исемен «Чаткылар» дип үзгәртә. Шул исем белән драма 1934 елдан башлап илдәге бөтен татар театрларын гизеп чыга.

Беренче әсәренең уңышыннан рухланып, Таҗи Гыйззәт 1923 елда тарихи темага «Каһәрле мөһер» драмасын, 1925 елда крестьяннарның азатлык өчен көрәшен сурәтләгән «Наемщик» пьесасының беренче вариантын яза. Өч пәрдәле комедия рәвешендәге «Наемщик» сәхнәдә уңыш белән барса да, бу вариант авторны канәгатьләндерми: ул аны 1927 елда яңабаштан музыкаль драма итеп яза. Яңа геройлар өстәп, әсәрнең социаль яңгырашын көчәйтә. С.Сәйдәшев музыкасы белән сәхнәгә куелган бу вариант зур уңыш казана. 1928 елда Татар дәүләт академия театрында, аннан соң Әстерхан, Оренбург, Мәскәү, Троицк кебек шәһәрләрдә куелып, «Наемщик» музыкаль драмасы татар драматургиясенең иң күренекле әсәренә әверелә. Ләкин спектакль матур узса да, тәнкыйть тарафыннан артык агитацион-турысызыклы булуы әйтелә. Тагын да камилләштерелеп, «Наемщик»ның иң популяр варианты утызынчы еллар ахырында язылa. 1940 елда опера өчен аның шигъри варианты да иҗат ителә.

Шул ук елларда Т.Гыйззәтнең заман темасына караган, совет авылында күмәкләшү өчен барган көрәшне тасвирлаган «Бөек борылыш» (1930), «Көрәш» (1931), «Акбаш вакыйгасы» (1932), «Ударник Мохтар» (1932), «Җиңү бәйрәме» (1933), «Фамилиясез тимерче» (1933), «Мактаулы заман» (1935) исемле 3–4 пәрдәле агитацион пьесалары дөнья күрә. Бу пьесалар үз вакытында авыл сәхнәләрендә, колхоз-совхоз театрларында еш куелып, үзләренең мөһим тәрбияви ролен үтиләр.

Бер үк вакытта гражданнар сугышы чорын, крестьяннарның ак бандаларга каршы көрәшен тасвирлаган «Бишбүләк» драмасы язылa. Салих Сәйдәшевнең музыкаль номерлары белән баетылган бу әсәр дә Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә озак еллар буе (премьерасы 1938 елда) зур уңыш белән бара һәм әдәби тәнкыйтьтә татар драматургиясенең бер казанышы итеп бәяләнә.

Т.Гыйззәтнең осталыгы тарихи-революцион пьесаларда тулырак ачыла. Драматург бу юнәлештә сүзен «Ташкыннар» (1936–1937), «Ялкын» (1940, икенче исеме «Фәрхиназ»), «Даулы көннәр» (1942), «Данлы көннәр» (1951) кебек әсәрләрендә дәвам итә. Пьесаларда аерым чорлар гәүдәләндерелә, татар халкының, крестьяннарның сыйнфый аңы формалашуы җанлы картиналарда чагылдырыла.

Фольклорга игътибар аеруча көчәйгән вакытта, Т.Гыйззәт, татар халкының «Җиде кыз» бәете мотивларына нигезләнеп, «Кыю кызлар» (1939) исемле комедия иҗат итә. 1940 елда Татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелеп, бу әсәр тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителә.

Драматург иҗатында чор таләп иткән патриотизм, Ватанны саклау темасы да зур урын тота. Акфиннар белән сугыш вакыйгаларын яктырткан «Таймасовлар» (1939) пьесасы 1941 елда Мәскәүдә булачак татар сәнгате декадасында күрсәтү өчен иҗат ителә. Пьеса Академия театрында 1941 елда куелып, Ватан сугышы елларында да репертуардан төшми.

Т.Гыйззәтнең «Төнге сигнал» (1941), «Изге әманәт» (1944), «Чын мәхәббәт» (1947) пьесаларында исә сугыш елларында совет кешеләренең батырлыгы, фидакарь көрәше, гыйбрәтле язмышлары сурәтләнә. Бу драмалар да Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә 1946 («Изге әманәт») һәм 1948 елларда («Чын мәхәббәт») тамашачы хозурына тапшырыла.

Т.Гыйззәт — татар театр сәнгатендә беренче музыкаль комедия «Башмагым» либреттосының авторы да. Бу әсәр Казан театрларында гына да бик күп мәртәбә уйнала, аны шулай ук Свердловск, Киев, Ташкент, Сәмәрканд һ.б. шәһәр тамашачылары да яратып кабул итә.

Сугыштан соң иҗат ителгән «Үрнәк адымнар» (1954), «Алсу таң» (икенче исеме «Мин-минлек корбаны», 1950), «Бердәнбер бала» (1953) кебек сәхнә әсәрләрендә әхлак проблемасы үзәктә тора.

Татар драматургиясенә 37 драма әсәре (шуларның 33 е төрле сәхнәләрдә уйнала) биргән Т.Гыйззәт музыкаль драма һәм комедия төрләрен үстерүгә дә зур өлеш кертә. «Наемщик», «Башмагым», «Бишбүләк», «Ташкыннар», «Чын мәхәббәт», «Төнге сигнал» әсәрләрендәге җыр текстларына С.Сәйдәшев һәм Җ.Фәйзи кебек бөек композиторлар көй язып, татар профессиональ музыкасы матур җырларга, яңача язылган бию көйләренә, ария, ариоза, увертюра һ.б. төрләргә дә байый.

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен драматург, актер һәм җәмәгать эшлеклесе Таҗи Гыйззәткә 1939 елда — «ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе», 1940 елда «РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Ул 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Гыйззәт Т.** Сайланма пьесалар. — 1 т. — Казан: Татгосиздат, 1954. — 415 б.
**Гыйззәт Т.** Сайланма пьесалар. — 2 т. — Казан: Татгосиздат, 1955. — 412 б.
**Гыйззәт Т.** Сайланма пьесалар. — 3 т. — Казан: Татгосиздат, 1956. — 334 б.
**Гыйззәт Т.** Чаткылар: Пьесалар (Олы яшьтәге балалар өчен). — Казан: Тат. кит. нәшр., 1969. — 308 б.
**Гыйззәт Т.** Ташкыннар: Пьесалар / Төз. К.Гыйззәт. — Казан. — Тат. кит. нәшр., 1985. — 432 б.
**Гыйззәт Т.** Сайланма әсәрләр: Драмалар / Төз. К.Гыйззәтов. — Казан: Тат. кит. нәшр., 2002. — 383 б.
**Гыйззәт Т.** Пьесалар / Төз. К.Гыйззәтов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 384 б.

**Аның турында:**

**Гыйззәт Т.** Мин ничек артист һәм драматург булдым / Гыйззәт Т. Сайланма әсәрләр. — 3 т. — Казан: Татгосиздат, 1956. — 19–38 б.
**Гыйззәт Б.** Драматург Таҗи Гыйззәт. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1957. — 111 б.
**Мәһдиев М.** Әйбәт кеше, олы драматург // Казан утлары. — 1990. — № 9.
**Ханзафаров Н.** Таҗи Гыйззәт / Татар әдәбияты тарихы 6 томда. — 5 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 416–432 б.
**Әхмәдуллин А**. Таҗи Гыйззәт иҗатының татар драматургиясе тарихында тоткан урыны / Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 59–65 б.
**Гыйззәтов К.** Таҗи Гыйззәт. Фикерләр. Истәлекләр. Хатлар. Бәхәсләр. — Казан: Мастер–Лайн, 2000. — 511 б.

## АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ (1928–2002)

Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев 1928 елның 17 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында туа. 1945 елда Сарман урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1948 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Белем алу белән бергә ул әдәби түгәрәк эшенә актив катнаша. Беренче иҗат тәҗрибәсе, әдәби процесска караган фикер алышулар, бәхәсләр шуннан башлана. Үз фикерле, талантлы татар яшьләренә репрессия дулкыннары да кагыла: әдип 1950–1955 елларда Казакъстанда булырга мәҗбүр. Казанга әйләнеп кайткач, укуын тәмамлап, ул үзен матбугат эшендә сынап карый: «Чаян», «Совет әдәбияты» журналларында эшли. 1961–1963 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый.

А.Гыйләҗев беренче әсәрләрен студентлык чорында ук яза башлый. 1948 елны «Безнең хикәяләр» исемле җыентыкта авторның «Ян, учагым, ян!» дигән беренче хикәясе басылып чыга.

А.Гыйләҗев — үзен проза остасы итеп таныткан әдип. Аның «Өч аршын җир» (1962), «Зәй энҗеләре» (1963), «Урталыкта» (1963), «Урманнар артында яшел болын» (1969), «Язгы кәрваннар» (1972), «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» (1973), «Мең чакрым юл» (1977–1978), «Җомга көн кич белән» (1979), «Әтәч менгән читәнгә» (1979–1980), «Балта кем кулында?» (1989), «Йәгез, бер дога!» (1995) һ.б. повесть, романнары бар.

Күпсанлы хикәя, повесть, публицистик мәкаләләр авторы каләмен драматургиядә дә сыный. Әдипнең кабатланмас «Җиз кыңгырау» (1960), «Киек Каз Юлы» (1960), «Көзге ачы җилләрдә» (1961), «Яланаяклы кыз» (1964), «Җиргә тапшырылган серләр» (1967), «Әңгер-меңгер» (1970), «Сары чәчәк ата көнбагыш» (1974), «Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз» (1975), «Хушыгыз, тургайлар» (1978), «Әгәр бик сагынсаң» (1980), «Шикәрем син, балым син» (1981), «Әткәй җырлый да, җылый да» (1982) һ.б. пьесалары иҗат ителә.

А.Гыйләҗевнең пьесалары Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры сәхнәләрендә уңыш белән бара. Шулай ук Татарстанның Әлмәт, Минзәлә, Чаллы театрлар репертуарларында үз урыннарын били. Язучының драмалары, комедияләре, трагедияләре рус, башкорт, авар, чуаш, словак һ.б. телләргә тәрҗемә ителеп, дөнья күреп, тамашачы һәм укучы күңелен яулап ала.

Әдипнең проза әсәрләре дә спектакль буларак халыкның күңелен җәлеп итте: «Китмәгез, тургайлар!» (драматик повесть), «Өч аршын җир» (повесть, трагедия), «Яра» (повесть) һ.б.

А.Гыйләҗевнең драма әсәрләре аерым китап буларак та дөньяга чыга: «Пьесалар» (1969), «Җиз кыңгырау» (1975), «Кар астында кайнар чишмә» (1979), «Әгәр бик сагынсаң» (1984), «Дус кызым кияүгә чыга» (1988).

Әдәбиятны һәм театр сәнгатен үстерүгә керткән өлеше өчен әдип 1978 елда Татарстанның, 1985 елда Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәргә лаек була. «Җомга көн кич белән» һәм «Әтәч менгән читәнгә» повестьлары өчен 1983 елда аңа Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге тапшырыла. 1987 елда язучы РСФСРның Максим Горький исемендәге Дәүләт бүләген ала. 1993 елда Аяз Гыйләҗевкә «Татарстанның халык язучысы» дигән мактаулы исем бирелә.

Ул 1961 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**


**Гыйләҗев А.** Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1969. — 500 б.
**Гыйләҗев А.** Җиз кыңгырау: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1975. — 302 б.
**Гыйләҗев А.** Кар астында кайнар чишмә: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. — 223 б.
**Гилязов А.** Три аршина земли: драма в 3-х д. — М.: ВААП, 1977. — 75 л.
**Гилязов А.** Дюжина красавиц (Двенадцать девушек): драма в 2 д. / Пер. Л. Моисеева — М.: ВААП, 1978. — 70 л.
**Гилязов А.** Один потерянный день: пьеса в 2-х д. / Пер. с рус. С. Бараникова — Братислава, 1977. — 47 л. (на словац. яз.).
**Гыйләҗев А.** Әгәр бик сагынсаң: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. — 294 б.
**Гыйләҗев А.** Дус кызым кияүгә чыга: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. — 439 б.


**Аның турында:**


**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 149–153 б.
**Әхмәдуллин А.** Яңалыкка омтылып: Аяз Гыйләҗев драматургиясенә бер караш // Социалистик Татарстан. — 1989. — 11 март.
**Галимуллин Ф.** Таза орлыклар // Казан утлары. — 1996. — № 2. — 181–182 б.
**Ахунов Г.** Язучы һәм заман // Казан утлары. — 1998. — № 1. — 119–126 б.
**Даутов Р.** Балачак әдипләре. — Казан: Мәгариф, 2002. (Аяз Гыйләҗев турында 78–86 б.)
**Гыйmранова Д.** Бай иҗат мирасы калдырган әдип // Шәһри Казан. — 2003. — 31 гыйнвар.
**Галимуллин Т.** Человек будущего // Татарстан. — 2003. — № 2. — С. 52–57.
**Сверигин Р.** Аяз Гыйләҗев (Татар әдәбияты тарихы 6 т.). — Казан: Раннур, 2001. — 185–200 б.


## МАНСУР ГЫЙЛӘҖЕВ (1961)

Мансур Аяз улы Гыйләҗев 1961 елның 29 гыйнварында Казанда күренекле татар язучысы Аяз Гыйләҗев гаиләсендә туа. Балалык елларыннан ук ул сынлы сәнгать, рәсем сәнгате һәм театр белән кызыксына. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казанның инженер-төзүчеләр институтының архитектура факультетына укырга керә һәм белгечлек алгач, Мәскәүнең проектлар төзү институтына эшкә билгеләнә. Мәскәүдә яшь белгеч драмалар язу белән мавыга башлый. Аның беренче пьесалары «Кәгазьдәге шау-шу», «Бәби арбасы», «Метеорит», «Ай капкасы» һ.б. татар һәм рус театрларының игътибарын җәлеп итә. 1986 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры М.Гыйләҗевнең «Рәхәт яшибез!!!» спектаклен сәхнәләштерә. Тормышның актуаль мәсьәләләренә багышланган бу сатирик комедиясе тамашачы тарафыннан җылы кабул ителә. Шул ук елда М.Гыйләҗев Мәскәүдән Казанга күчә һәм үзен язучылык эшенә багышлый.

1988 елда М.Гыйләҗев Д.Сираҗиев белән Ч.Айтматовның «Плаха» романын «Ахырзаман» исемендә сәхнәләштерәләр. Моннан соң әдипнең Татар дәүләт академия театрында «Бичура» (1989), «Казан егетләре» (1991), «Тагын Казан егетләре» (1993) пьесалары куела. Әлеге әсәрләрдә татар халкының гореф-гадәтләре, көнкүреше гәүдәләнеш таба.

1988–1995 елларда М.Гыйләҗев Бөтенсоюз һәм Россия күләмендә үткәрелгән драматурглар семинарларында актив катнаша. Драматургның пьесалары белгечләр тарафыннан югары бәяләнә.

2002 елда Татар дәүләт академия театры М.Гыйләҗевнең «Баскетболист» комедиясен (режиссеры М.Сәлимҗанов) сәхнәгә куя. Тормышчан материалга нигезләнгән әсәр милләт язмышын яктырткан иң уңышлы комедияләрнең берсе булды. Милләтнең чишмә башы булган татар авылының әкренләп бетүенең сәбәпләрен драматург эчкечелектә, кешеләрнең авылдан шәһәргә китеп кире әйләнеп кайтырга теләмәвендә, яшьләрнең гасырлардан гасырларга, буыннардан буыннарга күчеп килгән гореф-гадәтләрне санга сукмавында, катнаш гаиләләрдә һ.б. күрә. Кызыклы һәм мавыктыргыч вакыйгаларга корылган пьесада милли, иҗтимагый-мәдәни, фәлсәфи проблематика төрләрен аерып чыгарырга була. Язучы фикере символлар, метафоралар, сатира һәм сарказм аша да аңлашыла. Бу спектакль, Марсель Сәлимҗанов тарафыннан куелган соңгы әсәр буларак, җәмәгатьчелек тарафыннан спектакль-васыять рәвешендә кабул ителде.

2003 елда М.Гыйләҗев драматург Р.Хәмид белән Г.Исхакыйның «Кәләпүшче кыз» әсәре нигезендә «Курчак туе» пьесасын иҗат итәләр. Шул ук елда драматург Аяз Гыйләҗевнең «Яра» повестен Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында сәхнәләштереп, әсәр зур уңыш казана.

Әдипнең пьесалары шулай ук Казанның Курчак театрында «Патша кәләше» (1989), «Кәвеш кигән песи» (1994), «Сказание о Казани» (2003); Әлмәт драма театрында «Сафиулла» (1996), «Милли Миллениум» («Свадебное платье», 2006); Чаллы шәһәренең драма һәм комедия театрында «Дон Жуан Балчыклыда» (1997); Башкортстанның «Нур» театрында «Бичура» (2002) һәм «Өзелгән юллар» (2002); Минзәлә театрында «Яратылыш» (2002); Казанның татар яшьләр театрында «Алтынбәк һәм Су кызы» (2002); К.Тинчурин исемендәге Татар драма һәм комедия театрында «Бала баласы балдан татлы» (2003); Симферополь татар драма театрында «Казан егетләре» (2004); Туймазы татар дәүләт драма театрында «Люблю, обожаю! — Твой генерал» (2006) һ.б. уңыш белән бара.

Драматургның 2005 елда рус телендә «Словарь любви» дип исемләнгән пьесалар җыентыгы дөнья күрде. Китапта «Как стать миллионером?», «Баскетболист», «Рана», «Бурлак» («Последний мираж») һ.б. сәхнәдә куелган әсәрләре тупланган.

М.Гыйләҗев татар милли кинематографиясен үстерү юлында да күп эшчәнлек алып бара. 2002 елда аның сценарие буенча төшерелгән «Күктау» фильмы дөнья күрде. «Рамай» киностудиясендә әдип баш мөхәррир һәм продюссер вазифаларын башкара.

М.Гыйләҗев 2006 елда «Татарстанның атказанган сәнгатькәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Ул — 1990 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, 2002 елдан Россиянең Театр әһелләре әгъзасы булып санала.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Гилязов М.** Лунные врата: Пьесы. — Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. — С. 189.
**Гыйләҗев М.** Бичура: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. —287 б.
**Гилязов М.** Словарь любви: Пьесы. — Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. — С. 400.

**Аның турында:**

**Әхмәдуллина Э.** «Казан егетләре» нең кайтуы // Шәһри Казан. — 2001. — 26 гыйнвар.
**Клюева М.** «Привокзальная площадь» как утро татарского кино // Аргументы и факты. 2001 — № 32.
**Батулла Р.** Баскетболист // Звезда Поволжья. — 2002. — 28 февраля.
**Әхмәдуллина Э**. Һәр Баткаклыкның үз Сократы булса иде... // Мәдәни җомга. — 2002. — 6 март.
**Саттарова А.** Современная татарская драматургия 1985–2000 гг. Концепция эпохи и героя (О М.Гилязове на с. 85–89). — Казань: Gumanitarya, 2003. — С. 150.

## ГАЛИМҖАН ГЫЙЛЬМАНОВ (1957)

Галимҗан Хәмитьян улы Гыйльманов 1957 елның 1 февралендә Башкортстанның Дүртөйле районы Әсән авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. 1974 елда авылларындагы урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Укуын

тәмам итеп, аспирантурада фәнни тикшеренүләр алып бара һәм 1983 елда «Татар балладасы: башлангычы һәм үсеш этаплары» темасына кандидатлык диссертациясе яклый.

Г.Гыйльманов 1986 елдан Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият редакциясендә, соңрак балалар-яшүсмерләр редакциясендә редактор, редакция мөдире булып эшли. 1989–1990, 1999–2005 елларда Татарстан Язучылар берлегендә җаваплы сәркатип хезмәтен башкара. Бу елларда ул Казан дәүләт университетында лекцияләр, махсус курс, семинарлар да алып бара. 1999, 2002 елларда Татарстан Язучылар берлегенең XIII һәм XIV корылтайларында әдип, берлек идарәсенә сайланып, берлекнең рәис урынбасары һәм аппарат җитәкчесе итеп билгеләнә. 2005 елдан ул — Татарстан Министрлар Кабинеты Аппаратының мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү бүлеге баш консультанты.

Г.Гыйльманов үзен әдәбият галиме, язучы, шагыйрь, драматург, тәнкыйтьче, киң җәмәгать эшлеклесе итеп танытты.

1994 елда аның «Тозлы яңгыр» исемле хикәяләр, повестьлар, нәсерләр, парчалар тупланган беренче проза китабы дөнья күрә. 1999 елда язылган «Албастылар» һәм 2000 елда иҗат ителгән «Оча торган кешеләр» әсәрләре татар әдәбиятына яңалык алып киләләр.

Балалар өчен язылган пьесалары арасында «Убырлы карчык — әбием», «Булат нигә яхшы укый?», «Минем исемем Бүрек», «Көмеш тарак», «Шүрәлеләр ни атлы?», «Кәнфитләр патшалыгында», «Убырлы карчык, Шүрәле һәм Гөлүсә» һ.б. кызыклы образлар системасы белән аерылып тора.

«Убырлы карчык — әбием» пьесасы 1998 елда Татарстан Мәдәният министрлыгы уздырган «Татар пьесасы» конкурсында лауреат булды.

Аның «Кыш бабайда сер бар», «Шүрәлеләр ни атлы?», «Миңа дус кирәк!» пьесалары буенча телефильмнар төшерелгән.

«Кар кызының бәхете», «Шүрәлеләр ни атлы?», «Кыш бабайда сер бар» пьесалары (режиссеры Нуриәхмәт Сафин) Казан татар яшьләр театрында куелды.

Әдип олылар өчен язылган «Бала — бәгырь ите» исемле психологик драма авторы буларак та билгеле.

Бу драма Халык театрлары арасындагы Республика конкурсында Апас район Халык театры куелышында лауреат исемен яулады.

Г.Гыйльманов 1994 елда Татарстан Президентының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. 2002 елда ул Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге бүләгенә лаек була. 2003 елда әдипкә «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Г.Гыйльманов — 1992 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Гыйльманов Г.** Көмеш тарак: Балалар өчен пьесалар, шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. — 207 б.

**Аның турында:**

**Исмәгыйлева Р.** Кыш бабайның сере нидә? // Сабантуй. — 1999. — 20 гыйнвар.

**Галимов Ф.** Кар кызының мәхәббәте // Мәдәни җомга. — 2001. — 5 гыйнвар.

**Нигъмәтуллина Р.** Кар кызы да ярата белә // Сабантуй. — 2001. — 20 гыйнвар.

**Нигматуллина Ю.** «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве (о Г.Гильманове на с. 143–150). — Казань: ФЭН, 2002. — 176 и др.

## ХӘБИБРАХМАН ЗӘБИРИ (1881–1942)

Хәбибрахман Зәбири (Хәбибрахман Габделвәли улы Зәбиров) 1881 елда Чистай өязе Зирекле авылында (хәзерге Яңа Чишмә районы) урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Башта Чистай мәдрәсәсендә, 1898 елдан Казанда Галләм хәзрәт мәдрәсәсендә укый.

Х.Зәбири 1901 елдан Алабуга өязендә мөгаллимлек итә, соңрак Әхмәт бай Хөсәенов ярдәме белән Алабугада башлангыч татар мәктәбе ача, аннары, Оренбургка күчеп, «Хөсәения» мәдрәсәсендә физика, татар теле һәм әдәбияты укыта.

Х.Зәбири 1903–1917 еллар арасында татар мәктәпләре өчен физика, тарих, татар теле, ислам дине буенча егермеләп дәреслек бастыра.

1906 елда аның бердәнбер драма әсәре — «Төшенү, яхуд Указ бәласе» комедиясе дөнья күрә. «Указ бәласе» исеме белән 1907 елның августында И.Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге «Сәйяр» театр труппасы артистлары тарафыннан уйнала һәм озак еллар буе сәхнәдә куелып йөри.

Х.Зәбири Октябрьгә кадәр Уфа һәм Казан шәһәрләрендә яши. 1906 елда ул «Сабах» китап нәшрияты хуҗаларыннан берсе, ә 1908 елда Казанда нәшер ителгән «Тәрбия» журналы идарәсендә җаваплы сәркатип була.

Февраль һәм Октябрь инкыйлабларыннан соң Х.Зәбири «Өмет», К.Якуб исемендәге басмаханәләрдә эшли. Утызынчы елларда ул өч мәртәбә кулга алына. Соңгысында 1942 елның 14 гыйнварында тоткынлыкта вафат була. Исеме 1959 елның 29 сентябрендә аклана.

**Басылган драма әсәре:**

**Зәбири Х.** Төшенү, яхуд Указ бәласе: Комедия 4 пәрдәдә. — Казан: Мәгариф, 1906. — 43 б.

**Аның турында:**

**Рәми И., Даутов Р.** Әдәби сүзлек: Элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 99 б.

**Ибраһимова Ф.** Хәбибрахман Зәбири (1881–1942) / Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. — Казан, 2005. — 92–94 б.

## РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛА (1962)

Ркаил Зәйдулла (Ркаил Рафаил улы Зәйдуллин) 1962 елның 23 гыйнварында хәзерге Чуашстан республикасының Комсомол районы Чичкап авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. 1979 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1983–1989 елларда башта «Татарстан яшьләре» газетасы белән хезмәттәшлек итә, «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә эшли. 1989 елда яшьләр өчен «Идел» журналы ачылгач, Р.Зәйдулла журналның бүлек мөхәррире итеп билгеләнә.

Мәктәптә укыган вакытта ук Р.Зәйдулла шигырьләр яза башлый. 1977 елдан башлап әдипнең шигырьләре «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталарында, «Ялкын» һәм «Казан утлары» журналларында нәшер ителә. Язучының аерым шигырь цикллары, хикәяләре, юмористик язмалары «Чаян» журналында, «Идел» альманахында басыла.

1984 елда шагыйрьнең «Кояшлы күзләр» исемле беренче шигырь җыентыгы дөнья күрә. Тәнкыйть, җыентыкны уңай бәяләп, әдәбиятка үзенчәлекле, кызыклы фикерле әдипнең килүен таный. «Күрәзә» (1988), «Урыс кышын озату» (1993) шигъри җыентыклары авторга уңыш китерә.

Р.Зәйдулланың әдәби эшчәнлеге проза, драматургия, әдәби тәнкыйть, публицистика белән дә бәйле. Аның тарихи темага багышланган «Тимер Буга», «Тәңре кылычы», «Шаһгали» һ.б. әсәрләре бар.

Драматургия өлкәсендә әдипнең беренче зур уңышы — «Саташкан сандугач» драмасы. Әлеге әсәр, атаклы режиссер М.Сәлимҗанов тарафыннан 2001 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелгәннән соң, зур популярлык казана. Драмада заман проблемалары, әхлак призмасы аша үткәрелеп, уйланырлык фәлсәфи җирлек тудырыла. Тормышларында хаталар кылган, әмма соңында бәхет төшенчәсенең асылын аңлаган геройлар язмышы тамашачыга һәм укучыга якын булды. Моннан соң Р.Зәйдулланың тарихи-фәлсәфи тематикага багышланган «Хан һәм шагыйрь» тарихи риваяте һәм «Кол Шәриф» тарихи фаҗигасе дөнья күрәләр. 2003 елда татар дра-

матургиясен һәм театр сәнгатен үстерү максаты белән үткәрелгән бәйгедә Р.Зәйдулланың Рөстәм Сабиров белән бергәлектә иҗат ителгән «Хөкемдар» пьесасы икенче дәрәҗәдәге премиягә лаек була. Шулай ук авторның иҗат хәзинәсендә «Соңгы татар», «Пачпортлы шүрәле», «Ашина» һ.б. драмалар да бар.

Р.Зәйдулла үткен каләмле публицист буларак та билгеле.

Р.Зәйдулла Республиканың Муса Җәлил (1990) һәм Татарстан Язучылар берлегенең Фатих Хөсни исемендәге (2005) бүләкләре лауреаты да. Аның әсәрләре, инглиз, төрек, үзбәк, рус, чуаш телләренә тәрҗемә ителеп, төрле басмаларда дөнья күрде.

Ул — 1988 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**


**Зәйдулла Р.** Саташкан сандугач: Драма // Мәйдан. — 2003. — № 1. — 14–36 б.

**Зәйдулла Р.** Кол Шәриф: Тарихи фаҗига: Пьеса // Идел. — 2002. — № 9. — 10–27 б.

**Зәйдулла Р.** Хан һәм шагыйрь: Тарихи риваять: Пьеса // Казан утлары. — 2001. — № 7. — 47–66 б.

**Зайдулла Р.** Сумашедший соловей. Драма. Пер. Роза Кожевникова // Идель. — 2002. — № 6. С. 3–20.

**Зәйдулла Р., Сабиров Р.** Хөкемдар: Яңа татар пьесасы 3 томда. — 2 т. — Казан: Идел-Пресс., 2004. — 242–284 б.


**Аның турында:**


**Корбан Р.** Күрәзәче // Шәһри Казан. — 1990. — 26 октябрь.

**Заһидуллина Д.** Тәңре кылычы кайчан иңә? // Мәдәни җомга. — 2000. — 18 июль.

**Хуҗәхмәт Ф.** Сандугачлар саташмасын // Мәдәни җомга. — 2001. — 22 июль.

**Зайнуллина Г.** «Операция», «Зыялы»: Рецензия на спектакль «Саташкан сандугач» // Звезда Поволжья. — 2001. — № 25 (78). — 22–27 июнь.

**Саттарова А.** Современная татарская драматургия 1985–2000 гг. Концепция эпохи и героя. — Казань: Gumanitarya, 2003. (о Р.Зайдулле на с. 105–109). — С. 150.

**Сабиров Р.** Властитель: Драма в 3 действиях. По мотивам рассказа Р.Зайдуллы «Хан и поэт» // Идель. — 2003. — № 6. С. 2–22.

**Әхмәтҗанов М.** Халыкны милли үзаң яшәтә // Шәһри Казан. — 2004. — 23 июнь.


## ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА (1928–2005)

Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Иске Теләнче авылында игенче гаиләсендә туган. Башлангыч белемне Минзәлә районының Югары Тәкермән авылында ала, җидееллык мәктәпне Хуҗәмәт авылында тәмамлый. 1945–1949 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Югары уку йортыннан диплом алып чыккач, Татарстан радиокомитетында әдәби тапшырулар мөхәррире, 1952–1963 елларда Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегендә редактор вазифаларын башкара. 1983 елдан Гөлшат Зәйнашева эшчәнлеген иҗатка гына багышлый.

Аның беренче шигырьләре, җырлары, эстрада әсәрләре илленче еллар ахырында күмәк җыентыкларда басылып чыгалар. Г.Зәйнашева бигрәк тә җыр жанрында актив иҗат итә.

Әдибә каләмен драматургия өлкәсендә дә сыный. Аның «Бәхет кошым», «Кем гүзәл?», «Ирексездән әрәмтамак», «Рамай», «Яшел сумка» һ.б. пьесалары языла. Г.Зәйнашеваның «Гайфи бабай, өйлән давай!», «Җаным җәл түгел сиңа» комедияләре К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә уңыш казанды. Соңгы елларда ул «Тузган тораклар бетсен!», «Күктән төшкән кияү», «Язмышлар һәм ялгышлар», «Нәрсә булды безгә?» дигән пьесалар язды.

Татар җыр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г.Зәйнашевага 1988 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде. Татар шигърияten үстерүгә зур өлеш керткән әдибә Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия булды.

Г.Зәйнашева 1969 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Зәйнашева Г.** Очраклы хәлләр түгел: Бер пәрдәлек пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1964. — 40 б.
**Зәйнашева Г.** Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. — 175 б.
**Зәйнашева Г.** Сайланма әсәрләр: Җырлар, шигырьләр, пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 283 б.

**Аның турында:**

**Юсупова Р.** Менәргә иде Урал тауларына... Г.Зәйнашева белән әңгәмә // Сөембикә. — 1992. — № 1. — 12–13 б.
**Гаташ Р.** Моңнар бәйрәме // Казан утлары. — 1998. — № 1. — 115–116 б.
**Әгъләмов М.** Җырлады һәм җырлаячак // Татарстан яшьләре. — 1991. — 9 апрель.

## ШАҺИМОРАТ ЗӘЙНИ (1913–1980)

Шаһиморат Зәйни (Зәйни Әхмәт улы Шаһиморатов) 1913 елның 7 мартында хәзерге Оренбург өлкәсенең Тоцк районы Кондызлытамак авылында мулла гаиләсендә туа. 1933 елда Ташкентта икееллык педагогия институтын һәм 1936 елда Казан театр техникумын тәмамлагач, Республика халык иҗаты йортында үзешчән сәнгать түгәрәкләрен оештыручы методист-режиссер булып эшли. Бөек Ватан сугышы башлану белән, ул сугышка китә һәм пулеметчылар взводы командиры ярдәмчесе, батальон парторгы сыйфатында Мәскәүне, Сталинградны саклау сугышларында катнаша, бөтен Европаны үтеп, Германия җирләренә кадәр барып җитә. Сугыштагы батырлыклары өчен орден, медальләр белән бүләкләнә.

Армиядән кайткач, Шаһиморат Зәйни җиде елга якын Халык иҗаты йорты директоры булып эшли, 1953 елдан фәкать иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Беренче әсәрләре — «Шүрәле» драма-балладасы (1938), «Мәч-Мәчин» (1939), «Айтуган» (1941), «Кечкенә партизаннар» (1947), «Таң — Чулпан улы» (1956), «Бәхет кошы» (1956) — Курчак театры өчен язылган пьесалар була һәм алар Курчак театры сәхнәләрендә күп еллар уңыш белән баралар.

Илленче еллардан башлап драматург үзешчән театрлар, халык театрлары, профессиональ театрлар өчен дә пьесалар иҗат итә башлый. Шул чор әдәбиятының актуаль темаларына багышланган, әһәмиятле проблемалар куйган әсәрләре 1950–1960 елларда авторның нәтиҗәле эшчәнлеген дәлиллиләр. Аеруча популяр әсәрләре: «Хәзрәт үгетләргә килә» (1955), «Тугыз гашыйк» (1957), «Хәят» (1958), «Таң җыры» (1960), «Дәһшәтле минутлар» (1961), «Йөрәк давыллары» (1962), «Уеннан уймак» (1963) драмалары, җитмешенче елларда язылган «Гөмбәз асты серләре», «Әй әшнәләр, әшнәләр!» комедияләре жанрлары ягыннан да төрле һәм кызыклы булып, театрларда куелып торалар.

Бу әсәрләрнең күбесе үз вакытында Минзәлә драма театрында, хәзерге Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә куела. Шул ук вакытта Шаһиморат Зәйни рус һәм дөнья драматургиясенең күп кенә танылган әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә, театрлар репертуарын баетуга, төрлеләндерүгә дистәдән артык тәрҗемә хезмәте белән дә өлеш кертә.

Ул 1963 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Шаһиморат З.** Мәч-Мәчин: Курчак театрлары өчен драматик баллада 4 пәрдәдә, 6 картинада. — Казан: Татгосиздат, 1939. — 51 б.
**Шаһиморат З.** Таң җыры: Драма 4 пәрдәдә, 8 картинада. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1969. — 83 б.
**Шаһиморат З.** Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1973. — 239 б.
**Шаһиморат З.** Гөмбәз асты серләре: Пьесалар җыентыгы. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. — 184 б.

**Аның турында:**

**Мөсәгыйть Ф.** Уеннан уймак. З.Шаһиморат пьесасы Татарстан Республикасы күчмә театры сәхнәсендә // Социалистик Татарстан. — 1963. — 4 июнь.

**Мөхәммәтшин Г.** Әй әшнәләр, әшнәләр! З.Шаһиморат пьесасы Татарстан республикасы күчмә театры сәхнәсендә // Социалистик Татарстан. — 1968. — 14 декабрь.

**Ишморат Р.** Тынгысыз йөрәк // Социалистик Татарстан. — 1973. — 7 март.

**Ишморат Р.** З.Шаһиморатның тууына 70 ел // Казан утлары. — 1983. — № 3. — 179 б.

## ХӘЛИМ ҖӘЛӘЛОВ (1940)

Хәлим Бәдретдин улы Җәләлов (Хәлим Җәләй) 1940 елның 27 апрелендә Татарстанның Балык Бистәсе районы Олы Солтан авылында туа. Урта мәктәпне көмеш медаль белән тәмамлап, 1957 елда Казан авыл хуҗалыгы институтының механика факультетына укырга керә. Беркадәр вакыт укыгач, читтән торып уку бүлегенә күчә һәм Казан киез итек комбинатында эшли башлый.

Мәктәп елларында ук «артист» булып танылган Хәлим Җәләлов, әлбәттә инде, үзешчән сәнгать дөньясында кайный, Вахитов исемендәге клубның сәхнәсендә куелган һәр спектакльдә иң актив башкаручы да, оештыручы да була. Әдәбият һәм театр дөньясы, ниһаять, аны тулысынча үзенә буйсындыра — 1961 елда институттан да, эштән дә китә, Казан дәүләт театр училищесына укырга керә. Остазлары — актер да, режиссер да булган, үзләре әсәрләр язган, тәрҗемә иткән күренекле шәхесләр — Хөсәен Уразиков, Ширияздан Сарымсаков, Габдулла Шамуков була.

Табигате белән гаять кызыксынучан, җитез, сәләтле Хәлим Җәләй мәктәп елларыннан ук шигырьләр яза, рәсемнәр ясый. Шуңа күрәдер ул театр сәнгатенең көчен, матурлыгын җиңел үзләштерә. Училищены кызыл диплом белән тәмамлаган, студент елларында ук сәхнәдә уйнаган егетне 1965 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына эшкә чакыралар һәм хәзерге көндә дә Хәлим Җәләлов — бу театрның танылган артисты.

Хәлим Җәләлов төрле характердагы күп дистәләрчә рольләр башкара, татар драматурглары һәм рус, дөнья классик драматургиясе буенча куелган спектакльләрдә уйнап кына калмый, байтак әсәрләрне тәрҗемә итә. Мәсәлән: Ч.Айтматовның «Ахырзаман», А.Галинның «Сагыш», Г.Ибсенның «Өрәкләр», А.Островскийның «Кичеккән тәүбә», Ж.-Б.Мольерның «Дон Жуан, яки Ташкунак» әсәрләре. Радио һәм телевидение фондында күп кенә ул укыган-башкарган әсәрләр язылып алынды һәм саклана: «Йөзек кашы» (Ф.Хөсни), «Дим буенда» (С.Җәләл), «Минһаҗ маҗаралары» (Т.Миңнуллин), «Матурлык» (Ә.Еники), «Кеше китә — җыры кала» (М.Мәһдиев), «Тын океанда көрәш» (З.Хәким) һәм татар шагыйрьләренең шигырьләре.

Хәлим Җәләй балалар һәм яшүсмерләр өчен дистәгә якын әкият-поэмалар язды. Бу әсәрләре Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, Казан дәүләт курчак театрында куелдылар һәм әле дә яратып уйналалар: «Тылсымлы йозак», «Шәрә бүре», «Шомбай эшләпәсе», «Турай батыр», «Корчаңгы тай һәм таз малай», «Пәриле күл буенда» h.б.

1992 елда аңа «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

### Басылган драма әсәрләре:

**Җәләлов Х.** Корчаңгы тай һәм таз малай: Әкият-поэма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

**Җәләлов Х.** Шәрә бүре: Әкият-поэма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.

**Җәләлов Х.** Турай батыр: Әкият-поэма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

**Җәләлов Х.** Пәриле күл буенда: Әкият-поэма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

### Аның турында:

**Мөхәммәтова Р.** Театрда әкияткә урын бар: Театр артисты Х.Җәләй турында // Сабантуй. — 2000. — 15 апрель.

**Баттал Ф.** Сәнгатьнең олы солтаны: Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләйгә — 60 яшь // Ватаным Татарстан. — 2000. — 28 апрель.

Якташлар ихтирамы — зур куаныч: Артист Хәлим Җәләлов белән әңгәмә / Әңгәмәдәш Л.Хәбибуллина // Шәһри Казан. — 2000. — 28 апрель.

**Кыдашева З.** Таш астыннан чыккан Җәләй: Татарстанның халык артисты Хәлим Җәләлов турында // Татарстан яшьләре. — 2000. — 29 апрель.

# МУСА
# ҖӘЛИЛ
# (1906–1944)

Муса Җәлил (Муса Мостафа улы Җәлилов) 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә.

Муса алты яшеннән авыл мәдрәсәсенә укырга керә, гаилә шәһәргә күченгәч, укуын «Хөсәения»дә дәвам иттерә. Мәдрәсәдә уку елларында (1914–1917) матур әдәбият әсәрләрен яратып укый, үзе дә шигырьләр язып, мәдрәсәдәге кульязма журналга урнаштыра бара.

Сәхнәгә куяр өчен пьесалар да яза башлый. Ләкин аны буйга, яшькә кечкенә дип, сәхнә эшенә катнаштырмыйлар. 1917 елда «Кызыл йолдыз» газетасында «Кечкенә Җәлил» имзасы белән «Бәхет» шигыре басылып чыга.

1922 елның көзендә М.Җәлил Казанга килә. Башта ул «Татарстан» газетасы редакциясендә эшли, 1923 елның көзендә татар рабфагына укырга керә. 1924 елда оешкан «Октябрь» әдәби түгәрәгендә әгъза булып тора һәм Казандагы әдәби җыелышларда, кичәләрдә актив катнаша. 1925 елда исә «Барабыз» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә.

Рабфакны бетергәч, ике ел үз авылында комсомол ячейкасы сәркатибе булып эшли. Озак та үтми, ул «Кечкенә иптәшләр» исемле журналда эшләү өчен Мәскәүгә чакырыла. Редактор булу белән бергә, киң күләмдә оештыру эшләре алып бара, бер үк вакытта ул 1927–1931 елларда I Мәскәү дәүләт университетының әдәбият-сәнгать факультетында укып югары белем ала.

1925, 1929 елларда М.Җәлилнең Татар дәүләт академия театрында «Бибкәй кыз» һәм «Гудок» дигән пьесалары сәхнәләштерелә.

1933–1934 елларда М.Җәлил Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Коммунист» газетасының әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли. 1934 елда аның күп кенә шигырьләрен үз эченә алган «Орденлы миллионнар» дигән зур җыентыгы басыла һәм шул ук елны «Стихи Мусы Джалиля» исеме белән беренче мәртәбә рус телендә чыга.

1935 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында Татар операсы студиясенең әдәби бүлек мөдире булып эшли башлый. Кыска вакыт эчендә опера сәнгатенең үзенчәлекләрен өйрәнә, студиядә зур оештыру эшләре алып бара, үз тирәсенә дистәләрчә шагыйрьләрне һәм композиторларны туплап, либреттолар язарга булыша. 1938 елда студиядә укуын тәмамлап Казанга кайткач та опера театрының әдәби бүлек җитәкчесе булып эшен дәвам итә.

Композиторлар белән аралашу, музыка дөньясы белән тыгыз бәйләнеш тоту М.Җәлил иҗатында яңа үзгәрешләр тууга сәбәп була: әдипнең иҗатында бөтенләй яңа жанр — драматик поэма жанры барлыкка килә. Фольклор мотивларына таянып иҗат ителгән «Алтынчәч» (1939) драматик поэмасында автор халык, Ватан язмышы һәм ирек өчен көрәш темасын яктырта. Композитор Н.Җиһанов белән берлектә тудырылган «Алтынчәч» операсының премьерасы 20 июльдә була. Ләкин армия сафында булган М.Җәлил анда катнаша алмый.

М.Җәлилнең икенче драматик поэмасы — «Илдар» (1941) әсәре — сугыш алды әдәбиятында таралыш алган Ватанны ярату, саклау темасына багышланган. Соңыннан «Илдар» әсәре нигезендә дә Н.Җиһанов үзенең атаклы операсын иҗат итә.

Үзенең «Алтынчәч» һәм «Илдар» исемле драматик поэмалары белән М.Җәлил татар опера театрының үсешенә кабатланмас зур өлеш кертә.

1941 елның июль аенда М.Җәлил армиягә алына. Курс өлкәсенә алты айлык хәрби курсларга укырга җибәрелә. 1941 елның декабрендә өлкән политрук М.Җәлил Мәскәү аша фронтка китә. Ул Төньяк-көнбатыш фронтта чыга торган «Отвага» исемле газетаның алгы сызыктагы хәрби корреспонденты итеп билгеләнә. 1942 елның июнендә Волхов фронтында каты яраланган хәлендә М.Җәлил дошман кулына эләгә. Шул көннән башлап шагыйрьнең немец тоткынлыгындагы газаплы тормышы башлана.

М.Җәлил һәм аның көрәштәшләренә 1944 елның февралендә Дрезденда суд була һәм алар үлем җәзасына хөкем ителә. Шул елның 25 августында Плетцензее төрмәсендә унбер җәлилченең башы киселә.

Ватан сугышында күрсәткән ныклыгы һәм батырлыгы өчен шагыйрь Муса Җәлилгә 1956 елның 2 февралендә Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Фашист тоткынлыгында иҗат иткән «Моабит дәфтәрләре» исемле шигырьләр циклы өчен ул 1957 елның 22 апрелендә Ленин премиясенә лаек була.

М.Җәлил 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Җәлил М.** Әсәрләр 4 томда. — 2 т. Шигырьләр. Либреттолар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. — 592 б.

**Җәлил М.** Әсәрләр 4 томда. — 2 т. Шигырьләр (1941–1944); Либреттолар; Шагыйрь архивыннан. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 382 б.

**Аның турында:**

**Кашшаф Г.** М.Җәлил: Герой шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында очерк. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1961. — 456 б.

Муса турында истәлекләр / Төз. һәм әдәби эшкәртүче Г.Кашшаф. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1964. — 310 б.

Үлемсезлек таңында. Муса Җәлил турында истәлекләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1971. — 102 б.

**Кашшаф Г.** Татар операсының үсеше / Кашшаф Г. Күңел көзгесе: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1975. — 10–14 б.

**Юзиев Н.** Муса Җәлил / Татар әдәбияты тарихы 6 томда. — 5 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 65–87 б.

**Фазылҗанов Р.** Г.Камал исемендәге театр сәхнәсендә Муса Җәлил образы / Тел, әдәбият һәм халык иҗаты мәсьәләләре, 2 нче чыгарылыш. — Казан, 2002. — 261–268 б.

**Мостафин Р.** Батыр үлә, үлмәс ат алып: М.Җәлил турында яңа мәгълүматлар // Сөембикә. — 2004. — № 2. — 14–15 б.

**Мостафин Р.** Тарихларда укып ятларлык... / Җәлил М. Әсәрләр 5 томда. — 1 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 10–42 б.

**Бикмухаметов Р.** Муса Джалиль. — М.: Сов. Россия, 1966. — С. 133.

**Мустафин Р.** По следам оборванной песни. — М.: Известия, 1974. — С. 510.

**Исанбет Ю.** Муса Джалиль и татарская музыка. — Казань: Тат. кн. изд-во, 1977. — С. 160.

## РӘШИДӘ ҖИҺАНШИНА (1917–2003)

Рәшидә Габдуллаҗан кызы Җиһаншина 1917 елның 17 октябрендә Казан шәһәрендә туа. Әтисе, кырыс табигатьле булса да, яңалыкка омтылучан, аеруча театр сәнгатенә гашыйк кеше була. Ул һәр яңа спектакльгә гаиләсен дә алып бара, кызы Рәшидәне дә Вахитов исемендәге алдынгы мәктәпкә бирә. Фатих Хөсни, Сәет Шәкүровлар укыган, тагын күп кенә танылган кешеләрне укыткан бу мәктәптә Рәшидә рухланып, сәнгать дөньясына омтылып белем ала.

1932 елда ул Татар театр техникумына укырга керә. Зифа Басыйрова, Нәҗип Гайнуллин, Усман Әлмиевләр белән бергә укый, студентлык еллары Казанда әдәбиятның, сәнгатьнең аеруча күтәренкелек кичергән чорына туры килә.

1936 елда Рәшидә Җиһаншина, техникумны тәмамлап, Татар академия театрына эшкә килә һәм бөтен гомерен театр сәнгатен үстерүгә багышлый, татар халкының талантлы, яраткан актрисасы булып танылa. Аның күпкырлы таланты, беренче чиратта, ул башкарган рольләрдә чагыла. Өч дистәдән артык образ иҗат итә ул: татар, рус, дөнья драматургиясендәге иң характерлы геройларны уйный, һәрберсенең язмышын үз йөрәге аша үткәрә. Характерлар төрлелеген, Рәшидә Җиһаншинаның талант диапазонын, киңлеген күрсәтү өчен «Ташкыннар»дагы Гөлчирәне (Т.Гыйззәт), «Канкай улы Бәхтияр»дагы Екатерина II (Т.Миңнуллин), «Моңлы бер җыр»дагы Ана (Т.Миңнуллин), «Әлдермештән Әлмәндәр»дәге Хәмдебануны (Т.Миңнуллин) искә төшерү дә җитә.

1990 елда театрда «Инсаният» труппасы оеша һәм Рәшидә Җиһаншина труппаның җитәкчесе итеп сайлана. Труппа, нигездә, ветеран актерлардан тора, аларга уйнар өчен кызыклы, эчтәлеге һәм геройларның яше белән туры килә торган пьесалар кирәк була. Татар драматургиясенә хас булганча, театр үзе бу юлы да сәхнә әсәрләре иҗат итүгә рухландыра — Рәшидә Җиһаншина бер-бер арт-

лы пьесалар яза башлый. «Сөйдергеч бөти», «Кодагыйлар» комедияләре, «Көтелмәгән кунак», «Ветераннар» пьесалары, «Улларым» мелодрамасы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелалар. Әсәрләр татар әдәбиятына хас әхлакый саф, нык ихтыярлы, сабыр-түзем геройларны гәүдәләндерәләр, хәзерге заманга хас булган проблемаларны күтәрәләр. Бу пьесалар, бер китапка тупланып, басылып та чыктылар (Казан, Матбугат йорты, 2000. — 170 б.).

**Аның турында:**


**Илялова И.** Судьба актрисы: о Рашиде Зиганшине // Сов. Татария. — 1987. — 15 марта.

**Усманова Р.** Актриса на все времена: об артистке Рашиде Зиганшиной и ее книге «Жизнь моя — театр» // Респ. Татарстан. — 1997. — 16 октября.

**Ибатуллина-Гатова И.** Живая легенда: Рашида Зиганшина // Казань. — 2002. — № 3–4. — С. 26.

**Зәйнашева Г., Ихсанова Л.** Ветераннар йолдызлыгы: «Инсаният» труппасы // Мәдәни җомга. — 1995. — 18 март.


## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ (1887—1938)

Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов 1887 елның 12 мартында Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе Солтанморат авылында туа. Әтисе Гыйрфан, заманының алдынгы карашлы кешесе буларак, балаларын укытуга зур игътибар бирә. Әнисе Хәсәнә, укымышлы шәһәр кызы, булачак әдипкә башлап үзе хәреф таныта.

Беренче белемнәрен әти-әнисеннән алганнан соң, Галимҗан ике кыш Солтанмораттан биш-алты чакрым ераклыктагы Кешәкле авылы мәдрәсәсендә укый. Шул ук вакытта туган авылындагы өч класслы земство мәктәбендә башлангыч белем ала.

1898 елда абыйсы Шакирҗан белән Оренбургтагы Зәки мулла мәдрәсәсенә укырга килә, 1905 елгы революция тәэсирендә мәдрәсәләрдә иске тәртипләргә каршы баш күтәрүләрдә катнашканы өчен аннан куыла. Бераздан, укуын дәвам итәр өчен, Уфадагы яңа ачылган «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә, ләкин өч елдан бу мәдрәсәдән дә китәргә мәҗбүр була. Булачак язучы казакъ далаларында җир сөрә, Дагстан чүлләрендә нугайлар арасында балалар укыта, Урал заводларында эшли.

Г.Ибраһимовның әдәбияттагы беренче адымнары нәкъ шул чакларда башлана. Аның бер-бер артлы «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907), «Гыйшык корбаннары» (1908), «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1908), «Татар хатыны ниләр күрми» (1910) исемле әсәрләре языла.

1909 ел ахырында университетка керү теләге белән ул Казанга килә. Ләкин «сәяси ышанычсыз» саналган яшь татар әдибенә югары уку йортларына кереп уку мөмкинлеге табылмый: ул үзлегеннән күп укый, фән нигезләрен, тарих һәм фәлсәфәне өйрәнә, дөнья әдәбияты классиклары белән таныша.

Казанда яшәгән чорда Г.Ибраһимовның иҗат активлыгы аеруча көчәя. Ул «Яз башы», «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Сөю — сәгадәт» дигән хикәяләре, «Яшь йөрәкләр» (1912) исемле романы белән татар әдәбиятында яңа романтизмга нигез ташлары сала. Әдәби тәнкыйть һәм публицистик язмаларында татар әдәбиятының барышына, аерым жанрлар үсешенә, татар сәнгатенә, милли театрга, әдәби телгә, тарихка бәйләнешле күптөрле әһәмиятле мәсьәләләрне яктырта.

Г.Ибраһимов 1912 ел ахырларында Киевка китә һәм университетка ирекле тыңлаучы булып керә. Мөселман студентларының яшерен сәяси оешмасында катнашканы өчен 1913 елның 17 апрелендә кулга алына. Аңа Лукьяновск губерна төрмәсенең сәяси тоткыннар камерасында утырып чыгарга туры килә.

1913 елның көзеннән 1914 елның февраленә кадәр ул Казанда нәшер ителүче «Аң» журналының сәркатибе булып эшли. Яңадан Киев, Одесса һәм Сухуми шәһәрләрендә берничә ай яшәп алганнан соң, 1915–1917 елларда Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә. Бу чорда әдәби әсәрләр («Көтүчеләр» (1913), «Табигать балалары» (1914), «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914), «Безнең көннәр» (1914)) һәм тәнкыйть, публицистик мәкаләләр язудан тыш, гыйльми-педагогик хезмәтләр өстендә дә актив эшли. Аның «Татар сарыфы» (1911), «Татар нәхүе» (1911), «Татар имлясы» (1914), «Яңа әдәбият» (1914), «Әдәбият дәресләре» (1914), «Татар телен ничек укытырга» (1916) исемле ки-

таплары татар теле һәм әдәбияты методикасы башлангычы булу белән бергә, тел һәм әдәбият беленә нигез салалар.

Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы елларында да Г.Ибраһимов иҗат белән шөгыльләнә, үзен аямыйча, дәүләт һәм җәмәгать эшләрендә актив катнаша. М.Вахитов белән Үзәк Мөселман комиссариатында эшли, комиссариат тарафыннан чыгарылган «Чулпан» газетасында редактор була. Татар язучыларыннан беренче булып В.И.Ленин белән очраша.

Октябрь революциясеннән соң ул «Яңа кешеләр» (1920), «Кызыл чәчәкләр» (1921), «Тирән тамырлар» (1926), «Татар хатыны ниләр күрми» (II варианты), «Казакъ кызы» (1923), «Безнең көннәр» (II варианты) әсәрләрен яза.

Г.Ибраһимов драма жанрында актив эшләмәсә дә, татар театрының үсешенә үзенең тәнкыйть мәкаләләре белән ярдәм итеп тора. Октябрь революциясенә кадәр ул Ф.С.-Казанлының «Ямьсез тормыш» («Йолдыз», 1915, 25 гыйнвар) һәм Г.Исхакыйның «Мөгаллимә» («Тормыш», 1915, 26 февраль) спектакльләренә рецензияләр язып бастыра.

1920 елда Г.Ибраһимов үзенең бердәнбер драма әсәре — «Яңа кешеләр»не тәмамлый һәм Октябрь бәйрәменә багышлап, пьеса шул ук елның 8 ноябрендә сәхнәдә уйнала. Әсәр тамашачы тарафыннан җылы каршы алына һәм тәнкыйтьчеләр дә уңай бәя бирә. «Яңа кешеләр» драмасы революция темасына язылган әсәрләр арасында күренекле урын тота.

Совет чорында да Г.Ибраһимов татар театрын үстерү эшендә якыннан катнаша. Ул яңа куелган спектакльләргә рецензияләр язудан тыш, Ш.Усманов, Ф.Бурнаш, К.Әмири һ.б. әдипләрнең пьесаларын аерым чыгышларда уңай бәяли. Классик драматурглар Г.Камал, М.Фәйзи, Г.Коләхмәтовлар иҗатының югары идея-эстетик дәрәҗәсен билгеләп, аларның татар әдәбияты тарихында зур урын тотуы турында яза.

Гыйльми үзәк рәисе сыйфатында Г.Ибраһимов театрның репертуарын яхшыртуда, конкурслар уздыруда, драма әсәрләрен бастырып таратуда һ.б. зур эшләр башкара.

Г.Ибраһимов татар операсының тууына да зур өлеш кертә. Мәсәлән, «Эшче» операсына нигез итеп М.Гафури поэмасы аның киңәше буенча сайлап алына. 1926 елда татар театрының 20 еллык юбилей бәйрәмен зурлап уздыру өчен дә ул күп көч куя. Юбилей кичәсендә татар драматургиясенең һәм театрының үсеш юлларын тирән итеп яктырткан доклад белән чыгыш ясый.

Гомумән, мәкаләләр, рецензияләр һәм «Яңа кешеләр» драмасы Г.Ибраһимовның татар драматургиясе һәм театры үсешенә зур өлеш керткәне турында сөйли.

Алтмышынчы елларда әдипнең күренекле ике проза әсәре Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела. «Татар хатыны ниләр күрми» повесте Х.Сәлимҗанов инсценировкасында (режиссерлары П.Исәнбәт) 1960 елда, «Тирән тамырлар» романы (режиссерлары М.Сәлимҗанов, П.Исәнбәт) 1969 елда тамашачыга күрсәтелә.

Г.Ибраһимовның тормыш юлы фаҗигале төстә тәмамлана. Гомеренең соңгы дистә елы, каты авыру сәбәпле, Кырымда — Ялтада уза, әмма шул хәлендә дә аңа хаксызга «халык дошманы» дигән ярлык тагыла. Әдипнең гомере 1938 елның 21 гыйнварында Казанның Пләтән төрмәсе шифаханәсендә өзелә. Архангель зиратына күмелүе турында мәгълүматлар бар, әмма кабере билгесез.

Ул 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Ибраһимов Г.** Әсәрләр 8 томда. — 3 т. Кызыл чәчәкләр. Алмачуар. Тирән тамырлар. Яңа кешеләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1975. — 456 б.

**Аның турында:**

**Хәсәнов М.** Галимҗан Ибраһимов: Тормыш һәм иҗат юлы. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1964. — 332 б.

Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1966. — 424 б.

**Әхмәдуллин А.** Г.Ибраһимов һәм татар драматургиясе / Әхмәдуллин А. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — 165–177 б.

Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. — Казан: Фикер, 2002. — 272 б.

## ХӘБИР

## ИБРАҺИМ
## (1958)

Хәбир Ибраһим (Хәбир Кәбир улы Ибраһимов) (әдәби тәхәллүсе — Ахир) 1958 елның 19 ноябрендә Апас районының Борнаш авылында туа. 1976 елда Борнаш урта мәктәбен тәмамлап, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетына укырга керә. 1980 елда югары уку йортын тәмамлаганнан соң, Апас мәдәният йортына эшкә кайта. Методист булып эшли. Апас халык театрында уйный, төрле рольләр башкара. Шул вакытта беренче мәртәбә кечкенә драма әсәрләре яза башлый. Халык театрында уйнау киләчәктә аңа сәхнәне белергә, диалоглар төзергә ярдәм итә. Әлмәндәр авылы клубында директор булып эшләгән чорда Х.Ибраһимов яшьләр театры оештыра. Ә.Гаффарның «Язлар моңы» әсәрен куеп, район бәйгесендә дипломант исеменә лаек була.

1986 елда ул Казанга килеп, Союзара үзешчән сәнгать йортында методист булып эшли. 1990 елда «Идел» журналында беренче шигырьләре басылып чыга.

«Адым» театр студиясе (сәнгать җитәкчесе Р.Фатыйхов) яшь драматургның «Җырлап керәбез, җырлап чыгабыз» исемле беренче драма әсәрен сәхнәләштерә. Шул елларда Х.Ибраһим Казан телевидениесендә редактор булып эшли башлый, «Җомга көн кич белән», «Афәрин» тапшыруларын әзерли һәм алып бара. Телевидениедә эшләгән чорда аның пьесалары буенча «Дәмдинов һәм Дәмин маҗаралары», «Калай әтәч» исемле телеспектакльләр төшерелә. 1993 елда Әлмәт татар дәүләт драма театры аның «Артык гомер» (режиссеры З.Туишева) исемле драмасын куя. Минзәлә татар дәүләт драма театры «Кызыма килер 100 кеше» (режиссеры Л.Садриев, комедия, 1996), «Газиз ярым» (режиссеры Б.Бәдриев, драма, 1998), «Җиденче кияү» (режиссеры М.Мөбарәков, комедия, 2005) әсәрләрен сәхнәләштерә. 1997 елда К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры аның «Бәхетле килен» комедиясен куя (режиссеры З.Харисов). Түбән Кама драма театры төрле елларда драматургның «Бәхетле килен», «Җырлап керәбез, җырлап чыгабыз», «Канатлы бозау», «Хатыным-алтыным», «Мөхлис һәм Иблис» исемле драма әсәрләрен сәхнәләштерә. Аның 2003 елда Казан дәүләт яшьләр театрында «Килмешәк» (режиссеры А.Зарипов), Эстәрлетамак башкорт дәүләт драма театрында «Хатыным-алтыным», 1995 елда Уфа «Нур» театрында «Төнге шаяру» (режиссеры Р.Фатыйхов) пьесалары куела.

2002 елда Казан телевидениесе драматургның иң уңышлы саналган «Ялгыз тәкәрлек» драма әсәре буенча (режиссеры Г.Ширгазин) 3 серияле фильм төшерә.

Хәбир Ибраһим — «Татар пьеса»сы (1998), «Яңа татар пьеса»сы (2005) бәйгеләрендә лауреат. Ул өч китап авторы: «Аһәң» (2001), «Йокыга талган гүзәл» (2002), «Газиз ярым» (2006).

Хәбир Ибраһимов журналист буларак та танылa. Әдип төрле елларда «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» газеталарында, «Татарстан», «Идел» журналларында бүлек редакторы булып эшли.

Ул — 1994 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Ибраһим Х.** Газиз ярым. Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр. — 2006.

**Аның турында:**

**Мөкатдисов Р.** Артык гомер — артык буламы?: Әлмәт театрында куелган «Артык гомер» драмасы турында // Татарстан хәбәрләре. — 1995. — 17 май.

**Мөбарәков М.** Җитлегү / Түбән Кама театрында куелган «Мөхлис һәм Иблис» трагифарсы турында // Шәһри Казан. — 2001. — 5 гыйнвар.

**Сәгъдәтшин К.** Тәкәрлек моңы // Ватаным Татарстан. — 2002. — 17 декабрь.

**Гаязов А.** «Ялгыз тәкәрлек» телефильмын карагач // Шәһри Казан. — 2003. — 17 октябрь.

## ГАЗИЗ
## ИДЕЛЛЕ
## (1905–1985)

Газиз Иделле (Габделгазиз Сәлах улы Усманов) 1905 елның 26 декабрендә Әстерхан шәһәренең татарлар яшәгән Тияк бистәсендә туа. Башлангыч белемне мәхәллә мәдрәсәсендә ала, икееллык рус-татар мәктәбендә укый. Бик яшьли хезмәт эшчәнлеген башлап җибәрә: пароходлар ремонтлау, такта яру заводларында, аптекада, төрле эшләрдә эшли.

1923 елда ул Свердловск (хәзерге Екатеринбург) шәһәренә килеп урнаша, индустриаль техникумга укырга керә. Татар телендә чыга торган «Сабан һәм чүкеч» газетасы, «Шәпи агай» исемле сатирик журнал редакцияләрендә корректор булып эшли. Шул чорда аның беренче хикәяләре, очерклары, фельетоннары языла. 1926 елда Газиз Иделле Казанга килә һәм «Безнең юл», «Атака», «Совет әдәбияты» журналларында эшләгәндә, ул журналларда аның беренче хикәяләре, очерклары басыла.

1930–1940 елларда Газиз Иделле Кызыл Армия сафларында хезмәт итә, армия матбугатына мәкаләләр яза, дивизия газетасының редакторы булып эшли. Армиядән кайткач та озак еллар журналистлык эшчәнлеген дәвам итә.

Бөек Ватан сугышы елларында, «Совет Татарстаны» газетасының махсус хәбәрчесе буларак, Г.Иделле фронтларга командировкаларга бара, фронт газетасында эшли, азат ителгән төбәкләрдән репортажлар яза.

Газиз Иделле журналист буларак туплаган тормыш тәҗрибәсен, үткен каләмен язучылык эшендә дә уңышлы файдалана — беренче чиратта ул повесть һәм хикәяләре белән танылa: «Ерак чытырманлыда», «Рәүфнең балачагы», «Комсызлык», «Очрашулар», «Күпер», «Терсәк» һ.б. әсәрләре басылып чыга.

Шул ук елларда ул драма әсәрләре дә яза, һәм алар язучының төрле җыентыкларына кертеләләр. 1937 елда аның «Дәүләт Бәдриев» драмасы аерым китап булып басылып чыга һәм шул ук елда Татар дәүләт академия театрында куела.

Газиз Иделле бик актив иҗат итә һәм әдәби хезмәтнең төрле тармакларында нәтиҗәле эшли: публицистика, әдәби тәнкыйть, тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләре игътибарга лаек. Яңа чыккан китаплар, театр сәхнәләрендә куелган спектакльләр турында көндәлек матбугатта мәкаләләр, рецензияләр бастыра. Бу тәнкыйть мәкаләләре «Язучы һәм аның китабы» (1964) исеме белән аерым китап булып басылып та чыга. Рус әдәбиятының күренекле язучылары булган А.Фадеев, П.Павленко, Б.Полевой, В.Лаврентьевның проза һәм драма әсәрләрен тәрҗемә итүе — шулай ук әдипнең күпкырлы иҗат эшчәнлегенә дәлил.

Г.Иделле 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Иделле Г.** Дәүләт Бәдриев: Драма 5 пәрдәдә, 6 картинада. — Казан: Татгосиздат, 1937. — 95 б.
**Иделле Г.** Тормышка мәхәббәт: Хикәяләр, пьеса, мәкаләләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. — 388 б.
**Иделле Г.** Ул көннәр: Хикәяләр һәм пьеса. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1967. — 162 б.
**Иделле Г.** Күргәннәрем, белгәннәрем: Пьеса, повесть һәм хикәяләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1975. — 279 б.

**Аның турында:**

**Әпсәләмов Г.** Газиз Иделле // Совет әдәбияты. — 1956. — № 3. — 97–102 б.
**Минский Г.** Алтмышны каршылаганда // Казан утлары. — 1965. — № 12. — 129–131 б.
**Миңнуллин Ф.** Алгы сызыкта: Г.Иделлегә — 60 яшь // Социалистик Татарстан. — 1965. — 25 декабрь.
Хезмәт шатлыгы: Г.Иделлегә — 70 яшь // Казан утлары. — 1975. — № 12. — 118 б.
**Ишморат Р.** Каләмдәш дустыбыз // Социалистик Татарстан. — 1975. — 31 декабрь.
**Миннуллин Ф.** Юбилей писателя // Сов. Татария. 1965. 25 дек.
**Ахунов Г.** Старший друг и товарищ // Сов. Татария. 1976. 6 янв.

## РАХМАН
## ИЛЬЯС
## (1908–1943)

Рахман Ильяс (Габдрахман Вәкил улы Ильясов) 1908 елның 15 мартында хәзерге Апас районы Карамасар авылында туа. Октябрь революциясеннән соң әтисе гаиләсе белән Грозный шәһәренә күчеп китә, нефть промыселларында эшли. Яшүсмер Габдрахман биредә гомуми белем алуын дәвам

иттерә, 1924 елда нефть промыселында слесарь өйрәнчеге булып эшли башлый. 1925–1927 елларда ФЗӨ мәктәбендә белемен күтәрә. 1929 елда аны Грозныйдагы Шәрекъ халыклары клубы идарәсенә рәис итеп билгелиләр.

1931 елда Р.Ильяс Казанда Татар коммунистлар университетына укырга керә. Укыган чагында ук аның исеме газета-журнал битләрендә еш күренә башлый. Ел ярым белем алгач, ул янә Грозныйга кайтып 1933 елга кадәр газетада эшли. Аннан кабат Казанга килеп, газета редакцияләрендә, Татарстан радиокомитетында әдәби хезмәткәр, редактор, Татарстан Язучылар идарәсендә әдәби консультант вазифаларын башкара. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә, рота командиры сыйфатында күп сугышларда катнаша. Ут эчендә дә язучылык эшен ташламый. 1942 елда аның «Бабай» исемле бер хикәя һәм бер пьесадан торган җыентыгы басыла. Тагын пьеса язу турында хыяллана. Ләкин язучы, Украина далаларында дошман пулясыннан авыр яраланып, 1943 елның 23 августында һәлак була. Үлгәннән соң, сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Р.Ильяс әдәбиятка утызынчы еллар башында килә. Үзен драматургия жанрында сынап, колхоз тормышына багышланган «Әндәр карт» исемле пьеса яза. Әмма аның бу пьесасы үзенең сәнгатьчә эшләнеше, характерларның бирелеше ягыннан йомшак әсәр була. Шул ук елны аның Кавказ халыкларының гореф-гадәтләрен, көнкүрешен сурәтләгән «Таулар арасында» исемле хикәяләр җыентыгы басыла. Р.Ильяс бу китабы аша үзен талантлы язучы итеп таныта. Шул уңыштан рухланып, ул «Зәйнүш дускай», нефтьчеләр тормышына багышланган «Фонтан» (1939), «Танышлар» (1939) исемле пьесалар иҗат итә. Р.Ильяс татар драматургиясе тарихына тагын ике сәхнә әсәре — «Танышлар» һәм Грозный нефтьчеләренең гражданнар сугышында катнашуын тасвирлаган «Таулар тетри» (1941) дигән драмалары белән кереп кала. Алар барысы да үз вакытында матбугатта басыла.

Прозаик буларак, Р.Ильяс заманының актуаль мәсьәләләрен яктырткан «Горизонт» повестен, «Кем гаепле?» (1930), «Шәрифҗамал» (1932), «Чыныгу» (1933) һ.б. хикәяләр яза.

Үзенең кыска гына иҗат гомерендә Рахман Ильяс татар әдәбиятына дистәләрчә проза һәм драма әсәре калдыра.

Ул 1938 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**


**Ильяс Р.** Зәйнүш дускай: Пьеса. — Казан: Татгосиздат, 1934. — 61 б.

**Ильяс Р.** Әндәр карт: Колхоз сәхнәләре өчен 3 картиналы инсценировка. — Казан: Татгосиздат, 1934. — 32 б.

**Ильяс Р.** Танышлар: Пьеса 6 картинада. — Казан: Татгосиздат. — 1939. — 48 б.

**Ильяс Р.** Фонтан: Драма 3 пәрдәдә, 6 картинада. — Казан: Татгосиздат, 1940. — 106 б.


**Аның турында:**


Рахман Ильяс: Тууына 50 ел // Совет әдәбияты. — 1958. — № 10. — 125 б.

**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 205–206 б.


## ГАБДРАХМАН ИЛЬЯСИ (1856—1895)

Татар әдәбиятында беренче драма әсәре авторы Габдрахман Мөхәммәтдәмин улы Ильясов 1856 елда Казанда сәүдәгәр гаиләсендә туа. Мөхәммәтдәмин ага гомеренең соңгы елларында банкрот булып бурычка керә һәм ул бурычларны түләү мәшәкате улы Габдрахман өстенә төшә: атасыннан калган йорт-җирне сатып, Габдрахман шул бурычларны түли һәм үз кул көче белән хезмәт итеп яши. Төрле байларда конторщик, хисапчы булып эшли. Хезмәт хакы бик түбән булу сәбәпле, гомеренең соңгы елларын мохтаҗлыкта уздыра.

Г.Ильяси, Казанның Күл буе мәдрәсәсендә белем алу белән бергә, үзлегеннән һәм аерым укытучыларга йөреп, русча өйрәнә, рус әдәбияты белән таныша, рус театрларына йөри, драматургия мәсьәләләре белән кызыксына. Бу фактлар Г.Ильясиның үзендә дә язучылык сәләте уянуга сәбәп

була. К.Насыйри белән берлектә, авылларга чыгып, табигать күренешләрен, халык иҗаты материалларын өйрәнәләр. Аяз вакытларда төннәрен телескоптан йолдызлар да күзәтәләр.

Г.Ильяси мәдәни-агарту эшләрендә дә катнаша. 1880 елларда татар телендә газета чыгаруны оештырырга омтылып карый. Ләкин бу теләге хөкүмәт тарафыннан бастырыла. Ул тарихи вакыйгалар язылган кулъязмалар өстендә эшли. Казан университеты янындагы Археология, тарих, этнография җәмгыятенең әгъзасы булып тора, җыелышларында чыгышлар ясый, рус галимнәре белән аралаша.

Г.Ильясиның әдәби мирасы зур түгел. Аның басылып чыккан ике әсәре билгеле: «Бичара кыз» (1887), «Яшь кыз вә хатыннарга һәдия» (1887). Ундүрт биттән торган икенче кечкенә китапчыкта автор балаларны, бигрәк тә яшь кызларны ничек тәрбияләү турында фикер уздыра.

Егерме дүрт битлек «Бичара кыз» драмасы белән Г.Ильяси гаиләдәге искелек кануннарына, хатын-кызның хокуксызлыгына ризасызлык белдерә, яңа карашларны яклап чыга. «Бичара кыз» драмасы 1887 елда Казан университеты типографиясендә басыла. Әсәр композицион яктан катлаулы түгел. Драма әсәре буларак, ул башлангыч хәлдә генә. Персонажларның эш-хәрәкәте дә җәелдерелми. Драманың тарихи әһәмияте үз чорының актуаль проблемаларыннан берсен күтәреп чыгуында һәм татар әдәбиятына яңа, үсәргә сәләтле булган бер жанрны башлап җибәрүендә булды.

«Бичара кыз» драмасы беренче мәртәбә 1898 елда Касыйм шәһәрендә уйнала.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Ильяси Г.** Бичара кыз: Фаҗига. Драма 2 фасыл, 4 пәрдәдә. — Казан, 1887. — 24 б.

**Ильяси Г.** Бичара кыз / Гайнуллин М. Татар әдәбияты. XIX йөз. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1968. — 541–547 б.

**Аның турында:**


**Гайнуллин М.** Габдрахман Ильяси / Гайнуллин М. Татар әдәбияты. XIX йөз. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1968. — 535–540 б.

**Әйди Т.** Биектау йолдызлары // Казан утлары. — 1997. — № 5. — 153–154 б.

**Закирова Л.** Милли драмаларда аң үсеше: XIX йөз ахыры драмаларына күзәтү // Мәйдан. — 2003. — № 8. — 97–100 б.


## НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ (1900–1993)

Нәкый Исәнбәт (Нәкый Сираҗетдин улы Закиров) 1900 елның 10 гыйнварында элеккеге Уфа губернасы Златоуст өязе (хәзерге Башкортстанның Салават районы) Малаяз авылында мулла гаиләсендә туа. Авыл мәктәбендә башлангыч белемне алганнан соң, 1910–1917 елларда Уфадагы «Хөсәения», соңыннан Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә белем ала. 1917–1920 елларда туган төбәк авылларында татар теле һәм әдәбиятын укыта. Бу елларда Н.Исәнбәт шулай ук Уфа Халык мәгарифе институтында һәм Харьков университетының халык мәгарифе факультетында укый. Соңыннан Мәсәгут педагогия курсларында, Уфадагы урта белем бирү мәктәбендә, театр училищесында тел һәм әдәбият дәресләре алып бара.

1929 елда Н.Исәнбәт Татарстанга күчеп килә. 1940 елдан ул үзенең эшчәнлеген татар халкы тарихын өйрәнүгә, халык авыз иҗаты әсәрләрен туплап фәнни тикшерүгә, аларны халыкка җиткерүгә, иҗатка багышлый.

Мәдрәсәләрдә укыган вакытта ук, Н.Исәнбәт шигырьләр яза башлый. Беренче иҗат үрнәкләре аның 1914 елда Казанда балалар өчен нәшер ителгән «Ак юл» журналында дөнья күрә. 1914–1916 елларда аның «Әмирхан хәзрәт» комедиясе, «Сукбай», «Укытучы кыз» исемле беренче поэмалары һәм шигырьләре басыла. 1925 елда әдипнең «Чаң» исемле революцион пафос белән сугарылган шигырьләр җыентыгы халыкка ирешә. «Уракчы кыз», «Син сазыңны уйнадың», «Бормалы су» һ.б. лирик шигырьләре дә халык күңеленә үтеп, көйгә дә салына.

Н.Исәнбәтне драматург буларак таныткан әсәре — «Һиҗрәт» (1923) сатирик комедиясе. Аның «Культур Шәңгәрәй» (1925), «Пикуләй Шәрәфи» (1927), «Портфель» (1929) һ.б. комедияләре дә тиз арада популярлык казана.

1928–1929 елларда фольклор экспедициясе вакытында Н.Исәнбәт Алтын Урда дәүләтенең тарихын чагылдырган «Идегәй» дастанының берничә вариантын язып алып, Башкортстандагы фәнни-тикшеренү институтына тапшыра. Бу вакыттан башлап, Н.Исәнбәт бу дастанны өйрәнүгә, аны халыкка җиткерүгә күп тырышлык куя. Эпосның 17 вариантыннан файдаланып, үз вариантын төзеп, махсус мәкалә белән бергә 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында бастырып чыгара. 1941 елда Н.Исәнбәтнең «Идегәй» трагедиясе Г.Камал исемендәге Татар академия театры сәхнәсендә куела. Шул ук вакытта «Идегәй» дастаны С.Липкин тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителә башлый. Әмма ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августында кабул иткән карары нигезендә «Идегәй» эпосы һәм аның буенча язылган Н.Исәнбәтнең «Идегәй» трагедиясе әдәби мәйданнан юк ителә. «Идегәй» дастаны, сәхнә әсәре буларак, татар халкына 53 елдан соң гына әйләнеп кайта. 1994 елда дастанга, тарихи чыганакларга һәм Н.Исәнбәтнең «Идегәй» фаҗигасенә нигезләнгән Ю.Сафиуллинның «Идегәй» трагедиясе дөнья күрә һәм татар җәмәгатьчелек тарафыннан зур вакыйга буларак кабул ителә.

Татар халык авыз иҗаты әсәрләренә нигезләнеп язылган драма әсәрләре арасында шулай ук «Хуҗа Насретдин» (1939), «Җирән Чичән белән Карачәч сылу» (1942), «Кырлай егете» (1968), «Хәйләкәр Дәлилә яки «Мең дә бер кичә»дән бер кичә» (1978) һ.б. санарга мөмкин. Аның «Хуҗа Насретдин» комедиясе татар драматургиясе тарихында классик әсәрләрнең берсе булып санала. 1940 елда беренче тапкыр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелганнан соң, илебезнең төрле театр труппалары тарафыннан XX гасыр дәвамында һәм XXI гасыр башында да яратылып башкарыла. Ике меңнән артык куелган спектакль халыкның күркәм сыйфатларын туплаган Хуҗа Насретдин образы белән тамашачыны үзенә җәлеп итә.

Драматург тормышның авыр иҗтимагый якларын яктырту белән бергә («Миркәй белән Айсылу» (1936), «Болак арты республикасы» (1940) һ.б.) пьесаларында тарихи шәхесләр образларын да тудыра: «Гөлҗамал» (1943), «Мулланур Вахитов» (1946), «Муса Җәлил» (1956). Татар театрының туу тарихы һәм беренче татар актрисасы — Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның тормышы һәм артистлык эшчәнлеге «Гөлҗамал» драмасында чагылыш таба.

Әдипнең гаилә һәм иҗтимагый тормышны яктырткан «Рәйхан» (1949), «Гүзәл» (1950), «Зифа» (1954) һ.б. пьесалары бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмыйлар. Аның «Әбүгалисина», «Хуҗа Насретдин» әсәрләре Казан курчак театры репертуарында үз урынын алды.

Н.Исәнбәт тарафыннан татар халкының бай халык авыз иҗаты мирасын барлау, өйрәнү, системага салу, аны бастырып чыгару юлында зур эшчәнлек алып барылды. Өч томда дөнья күргән «Татар халык мәкальләре» өчен 1968 елда галимгә Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге тапшырылды.

Әдип тәрҗемә итү өлкәсендә дә көчен сыный. Ул А.Пушкин, Ж.Мольер, В.Шекспир, А.Грибоедов әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Мәсәлән, А.Пушкинның «Каменный гость» («Таш кунак»), Ж.Мольерның «Тартюф», В.Шекспирның «Гамлет», «Король Лир» һ.б.

Әдәбият, сәнгать, фән өлкәләрендәге эшчәнлеге өчен Н.Исәнбәт 1957 елда — Татарстанның, 1959 елда Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәргә ия була. 1957 елда аңа Ленин ордены, 1969 елда Хезмәт Кызыл Байрагы, 1980 елда Халыклар Дуслыгы орденнары бирелә. Н.Исәнбәт 1986 елда «Татарстанның халык язучысы» дигән мактаулы исемгә лаек була.

Н.Исәнбәт 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Исәнбәт Н.** Сайланма әсәрләр: Пьесалар. — 2 т. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1963. — 506 б.
**Исәнбәт Н.** Сайланма әсәрләр: Пьесалар. — 3 т. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1967. — 455 б.
**Исәнбәт Н.** Хуҗа Насретдин: 3 пәрдәлек комедия. — Казан: Татгосиздат, 1941. — 152 б.
**Исәнбәт Н.** Гүзәл: 5 пәрдәлек драма. — Казан: Татгосиздат, 1952. — 83 б.
**Исәнбәт Н.** Комедия һәм драмалар. — Казан: Таткнигоиздат, 1953. — 450 б.
**Исәнбәт Н.** Зифа: Комедия 4 пәрдәдә. — Казан: Таткнигоиздат, 1956. — 115 б.
**Исәнбәт Н.** Сәхнә әсәрләре. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1958. — 344 б.
**Исәнбәт Н.** Кырлай егете: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — 328 б.

**Исанбет Н.** Тюляк. Опера в 5 действиях. Либретто Н.Исанбета. — Казань, 1945. — С. 23.
**Исанбет Н.** Муса Джалиль: Трагедия в 4 д. / Пер. М.Машакова. — Алма-Ата: Казгослитиздат, 1962. — С. 112.

**Аның турында:**

**Шамуков Г.** Нәкый Исәнбәт: Язучының тормыш юлы һәм иҗаты. Монография. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. — 76 б.
**Ханзафаров Н.** Нәкый Исәнбәт драматургиясе: жанр, конфликт һәм герой проблемалары. Монография. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. — 192 б.
**Шамуков Г.** Исәнбәт драматургиясе // Казан утлары. — 1969. — № 12.
**Илялова И.** Аксакал татарского искусства: Н.Исанбету 80 лет // Вечерняя Казань. — 1980. — 14 январь.
**Гимранова Д.** Современное прочтение классики // В кн.: Сцена и время. — Казань, 1982. — С. 76–91.

## ГАЯЗ ИСХАКЫЙ (1878–1954)

Гаяз Исхакый (Мөхәммәтгаяз Гыйләҗетдин улы Исхаков) 1878 елның 23 февралендә Казан губернасының Чистай өязе Яуширмә авылында татарның мәгърифәтле вә мәдәни рухани гаиләсендә дөньяга килә. Әтисеннән башлангыч белемне алгач, 1890 елда аны Чистай мәдрәсәсенә укырга җибәрәләр. Биредә өч ел укыганнан соң, 1893 елда Мөхәммәтгаяз әтисе рөхсәте белән аны ташлый һәм Казандагы Күл буе мәдрәсәсендә, 1898–1902 елларда Казан Татар укытучылар мәктәбендә белем ала.

Әлеге мәктәпне тәмамлагач, Г.Исхакый Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә укытучы булып урнаша. Биредә ул дәресләр бирү белән генә чикләнми, әдәби-музыкаль кичәләр, мәдәни мәҗлесләр һ.б. чаралар да үткәрә.

Бер елдан соң Г.Исхакый «Хөсәения» мәдрәсәсеннән китә һәм 1903 елның җәендә, Казанга кайтып, университетка керергә әзерләнә. Әтисе кинәт авырып китү сәбәпле, туган авылында мулла булып тора. Әмма бераздан, муллалыгын ташлап, яңадан Казанга килә һәм көрәш-сәясәт дөньясына чума.

1905 елгы революция йогынтысында Г.Исхакый сәясәтче булып таныла. Ул татар эсерлар партиясен оештыра, аны җитәкли һәм «Таң йолдызы» исемле революцион эчтәлекле газета чыгара. 1906 елның 18 маеннан чыга башлаган әлеге матбугат органында Г.Исхакыйның журналист-публицист таланты ачыла. Анда басылган мәкаләләрендә ул татарларның колониаль изелүдә яшәвен күрсәтә, милли һәм социаль азатлык мәсьәләләрен күтәреп чыга, татар, рус һәм башка халыкларны патша самодержавиесенә каршы көрәшкә чакыра. «Таң йолдызы» ябылганнан соң, Г.Исхакый журналистлык эшчәнлеген шулай ук татар эсерлары органы булган «Тавыш» газетасында дәвам итә.

1906 елда Дәүләт думасына сайлаулар вакытында крестьяннар арасында хөкүмәткә каршы пропаганда алып барганы өчен, Г.Исхакый беренче мәртәбә кулга алына. Чистай төрмәсендә утырган ике ай вакыт эчендә ул «Зиндан» исемле автобиографик повестен яза.

Г.Исхакыйның сәяси эшчәнлеге көннән-көн активлаша һәм 1907 ел башында ул кабат кулга алына, Архангель губернасына өч елга сөргенгә җибәрелә. 1908 елның җәендә ул сөргеннән кача, башта Петербургта яши, аннан Төркиягә китә.

1911 елның ахырында Г.Исхакый, Петербургка кайтып, чит кеше паспорты белән яши башлый. 1912 елның 25 гыйнварында яңадан кулга алына һәм сөрген срогын тутыру өчен яңадан Пинегага озатыла. Бу юлы сөргендә 1913 елның 4 апреленә кадәр була. Аннан Романовлар династиясенә 300 ел тулу уңаеннан ясалган амнистия нигезендә Казанга кайтмау шарты белән чыгарыла.

Г.Исхакый Петербургта яши башлый. Аның сәяси карашларында кискен үзгәреш барлыкка килә. Ул, сыйнфый көрәшне читтә калдырып, алгы планга милли азатлык көрәшен куя, «милләтне саклау» байрагы астында берләшергә чакыра. Үзенең идея-карашларын «Ил» газетасы аша җиткерә.

«Ил» бераз вакыт Петербургта чыкканнан соң Мәскәүгә күчә, әмма анда бер елдан артык яши алмый. 1915 елның 27 мартында, «сәяси яктан зарарлы» дип табылып, патша власте органнары тарафыннан туктатыла. «Ил» газетасыннан соң Мәскәүдә «Сүз» (1915–1916), «Безнең юл» (1916–1917) газаталары чыгарыла.

Әдип 1917 елның Февраль революциясен шатланып каршы ала, Бөтенроссия мөселманнарының II съездын әзерләүдә, үткәрүдә актив катнаша. Съездда ясаган докладында Россия составында татарлар өчен милли-мәдәни мохтарият төзү мәсьәләсен күтәрә. Әлеге идея съезд делегатлары тарафыннан хуплана. Милли-мәдәни мохтарият мәсьәләсе Идел-Урал төбәгендә яшәүче татар-башкортларның дәүләтчелеген билгеләүгә кайтып кала.

1917 елның 20 ноябрендә Уфада эшли башлаган Милли Мәҗлес «Идел-Урал» штаты төзелү турында фәрман чыгара. Әмма мөстәкыйль дәүләт төзү идеясе тормышка ашырыла алмый. Чөнки хакимияткә килгән большевиклар Милли Мәҗлес делегатларын, башка милли хәрәкәт оешмаларын куып тарата, җитәкчеләрен кулга ала, газета-типографияләрен яптыра.

Г.Исхакый моның белән килешә алмый, чөнки аңа үз илендә иҗат итү, сәясәт белән шөгыльләнү өчен юл ябыла. Ул, Ватанын ташлап, чит илгә — мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр була.

Версаль солых конференциясенә делегат итеп сайланган Г.Исхакый Ерак Көнчыгыш аша 1919 елда Парижга килеп җитә. Франциядә бераз торганнан соң, Берлинда һәм Варшавада яши. Польша хөкүмәте үтенече буенча Ерак Көнчыгышта озак вакытлы командировкаларда була. Бу форсатны да ул андагы милли азатлык хәрәкәтен җанландыру өчен файдалана. 1939 елда Гитлер Германиясе Польшага басып кергәч, ул Төркиягә күчеп килә һәм гомеренең соңгы көненә кадәр шунда кала.

Мөһаҗирлектә чагында Г.Исхакый әдәби иҗатын да, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген дә актив дәвам итә. Төрле илләргә таралган татар эмигрантлары белән очраша, алар белән элемтәдә яши. Китап бастыру, газета-журналлар чыгару буенча актив эшли. 1920–1930 елларда Варшава, Берлин шәһәрләрендә «Милли юл», «Яңа милли юл», 1935 елда Кытайда «Милли байрак» исемле газета-журналлар чыгара. Ул мәкаләләрендә совет режимын тәнкыйтьли, татар милләтенең киләчәге өчен борчылуын белдерә, телне, милли мәдәниятне саклау проблемаларын күтәрә.

Г.Исхакый 1954 елның 22 июлендә 76 яшендә Әнкара шәһәрендә вафат була. Үзенең васыяте буенча Истанбулда Әдернәкапы зиратында күмелә.

XX йөз башы татар әдәбиятын ул «Теләнче кызы», «Мулла бабай», «Остазбикә», «Сөннәтче бабай» һ.б. бик күп проза әсәрләре белән баета. Г.Исхакый драма жанрында да актив эшли. 1906 елның 21 апрелендә Уфада рәсми куелган беренче сәхнә әсәре дә Г.Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» драмасы була. Иҗатының мәгърифәтчелек чорында язылган «Өч хатын белән тормыш» (1900) драмасында, сентиментальлеккә төренгән «Ике гыйшык» (1902) комедиясендә әдип шул чорның актуаль проблемаларын: рухи әхлаксызлык, наданлык, бозыклык, хатын-кызның хокуксызлыгы кебек мәсьәләләрне яктырта. Казан төрмәсендә язылган «Алдым-бирдем» (1907) драмасында, гаилә, көнкүреш проблемалары белән генә чикләнеп калмыйча, милләт хәле-тәрәккыяте, социаль каршылыклар, сәясәт кебек сораулар да мөһим урын тота.

«Алдым-бирдем» драмасы «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан беренче тапкыр Җаек шәһәр театрында 1908 елның 31 гыйнварында С.Гыйззәтуллина-Волжская бенефисында уйнала. Бенефис иясе Галия ролен бик тырышып башкара. Спектакльдә Ибраһим ролендә В.Мортазин-Иманский, Хәлил бай ролендә Г.Кариев шулай ук уңышлы чыгыш ясыйлар. Шул көннән башлап «Алдым-бирдем» бик актив уйнала торган спектакль булып китә. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсенә драма кабат 1994 елда (режиссеры П.Исәнбәт) күтәрелә.

Тарихи-революцион эчтәлекле «Тартышу» (1908, басыла 1917) һәм халыкчылык идеяләрен үткәргән «Мөгаллим» (1908) драмаларында Г.Исхакый халык бәхете өчен тартышуның төрле юлларын яктырта. «Мөгаллим» пьесасы «Сәйяр» труппасы тарафыннан 1910 елның 7 мартыннан күрсәтелә башлый. Башта ул Оренбургның Халык йорты сәхнәсендә бара. Казан тамашачылары аны 18 июньдә Панаев бакчасының ябык театрында карыйлар. «Мөгаллим» «Сәйяр» труппасы репертуарында еш уйнала һәм матбугатта да махсус рецензияләрдә (Г.Камал, Ф.Әмирхан) чагылыш таба.

Г.Исхакый үзен комедия жанры остасы буларак та таныта. Кадимчеләрнең схоластик фикерләү рәвешеннән һәм томана халыктан каһкаһә белән көлгән «Җәмгыять» (1909) һәм «Кыямәт» (1909) комедияләре үзенчәлекле сюжет-композициягә корылган. Көлке тудыру максатында ислам дине мифологиясеннән алынган образ, сурәтләр, градация, сүз уйнату, каршы кую кебек алымнар уңышлы файдаланылган. Ике комедия дә «Сәйяр» труппасы тарафыннан 1911 елда сәхнәләштерелә.

Романтик эчтәлекле «Мөгаллимә» (1913) драмасы беренче тапкыр 1914 елның 16 августында Түбән Новгородта Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында куела. Зыялылар тарафыннан төрлечә каршы алынса да, «Мөгаллимә» татар сәхнәсе репертуарында лаеклы урын ала һәм Октябрьгә кадәрге чорда бик еш куела. Артистлар Г.Болгарская (Фатыйма), В.Мортазин-Иманский (Габдулла), Г.Кариев

(Карт хәзрәт), Б.Болгарский (Остабикә), К.Тинчурин (Артист), С.Байкина (Әсма) уеннары аша Г.Исхакый әсәренең фәлсәфи фикере ачык чагылыш таба.

Милләтчелек чорында язылган «Зөләйха» (әсәр 1907 елда Чистай төрмәсендә языла башлый, 1911 елда Истанбулда дәвам ителә, 1912 елда Петербургта тәмамлана; 1917 елда сәхнәдә куела, 1918 елда басыла) тарихи драмасында рус дәүләтенең һәм миссионерларының татарларны көчләп чукындыру, милли-колониаль изү сәясәте фаш ителә. Драма 1912 елда язылып бетсә дә, аны нәшер итү һәм сәхнәгә кую бик кыен булып чыга. Җәмәгатьчелек «Зөләйха» трагедиясе белән кулъязма хәлендә таныша. Һәм, ниһаять, 1917 елда әсәрне басарга рөхсәт бирелә, шул ук елның 17 мартында Большой театрда атаклы драма куела. Уенда иллегә якын кеше катнаша, махсус декорацияләр ясала. С.Габәши тарафыннан пьеса өчен язылган музыка композиторның үз җитәкчелегендә уйнала һәм киң җәмәгатьчелек тарафыннан бик хуплап каршы алына. Халык соравы буенча, «Зөләйха» шул ук елның 27 мартында кабат күрсәтелә. Г.Исхакыйның Казанга килү уңаеннан 7 апрельдә «Зөләйха» өченче тапкыр уйнала. Спектакль авторның үз постановкасында куела һәм тагын да көчлерәк яңгыраш ала. Гомумән, Октябрь инкыйлабына кадәр «Зөләйха» драмасы егерме тапкыр сәхнәгә менә. Совет чорында «онытылып» торган пьеса 1992 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсенә кабат кайтарыла (режиссеры П.Исәнбәт) һәм, аңа нигезләнеп, 2004 елда «Рамай» студиясе тарафыннан кинофильм да төшерелә.

Г.Исхакый мөһаҗирлектә яшәгәндә дә иҗат эшен туктатмый. Сугышлар, инкыйлаблар чорында төрки халыклар күргән афәтләр «Дулкын эчендә» (1920–1937) драмасында куе буяулар белән тасвирланса, «Җан Баевич» (1923) комедиясендә руслашып, европалашып, тәрәккыйпәрвәр булып, тарихта эз калдырырга теләгән татарлардан усал да, шаян да көленә. «Җан Баевич» утызынчы елларда ук Ерак Шәрыкта, Финляндиядә сәхнәләштерелә. Бу спектакльне утызынчы еллар урталарында Кытайда, Японияда булган Г.Исхакый үзе дә карый һәм тамашага, актерлар уенына югары бәя бирә. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә «Җан Баевич» комедиясе беренче тапкыр 1995 елда (режиссеры П.Исәнбәт) куела.

Г.Исхакыйның соңгы әсәре — Казан ханлыгының оешу, яшәү тарихын, рус-татар мөнәсәбәтләрен сурәтләгән «Олуг Мөхәммәд» тарихи драмасында (1944–1947) Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыкларының дөнья тарихында тоткан урынына югары бәя бирелә.

Г.Исхакый драматургиясе татар сәхнәсен һәм әдәбиятын милли идея, яңа жанр һәм уникаль әсәрләр белән баетты.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Исхакый Г.** Зиндан: Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 670 б.

**Исхакый Г.** Олуг Мөхәммәд: Тарихи драма // Мирас. — 1991. — № 1. — 27–51 б.; 1992. — № 1. — 39–66 б.

**Исхакый Г.** Дулкын эчендә: Драма // Мирас. — 1992. — № 4. — 52–72 б.; № 5. — 52–66 б.

**Исхакый Г.** Әсәрләр 15 томда. — 4 т. Пьесалар (1900–1918). — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 496 б.

**Аның турында:**

**Мәхмүтов Һ., Илялова И., Гыйззәт Б.** Октябрьгә кадәрле татар театры. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. — 399 б.

**Нуруллин И.** Гаяз Исхакый: Әдипнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлегенә кыскача бер күзәтү / Исхакый Г. Зиндан. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 5–18 б.

**Мәхмүтов Һ., Гайнанова Л.** Зарыгып көткән мирас / Исхакый Г. Зиндан. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 636–660 б.

**Сәхапов М.** Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты. Монография — Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. —528 б.

**Әхмәдуллин А.** Гаяз Исхакый һәм татар драматургиясе // Мирас. — 1995. — № 1, 2. — 57–65 б.

**Мусин Ф.** Гаяз Исхакый: Тормышы һәм эшчәнлеге. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. — 191 б.

**Хәсәнов М.** Татар Ренессансының бөек каһарманы / Исхакый Г. Әсәрләр 15 томда. — 1 т. Повестьлар һәм хикәяләр (1899–1908). — Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. — 5–30 б.

**Ханзафаров Н.** Гаяз Исхакыйның татар театры һәм драматургиясендәге урыны / Гыйльми язмалар. — Казан: ТДГИ, 1999. — 3 чыгарылыш. — 14–16 б.

**Арсланов Г.** Гаяз Исхакый һәм татар театры // Казан утлары. — 1999. — № 9. — 172–177 б.

Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы. — Казан: Фикер, 2000. — 296 б.

**Миңнегулов Х.** Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 367 б.
**Ганиева Р.** Гаяз Исхакый иҗаты: Югары уку йортларының татар филологиясе студентлары өчен киңәйтелгән махсус курс программасы. — Казан: КДУ нәшр., 2005. — 38 б.

## РИЗА ИШМОРАТ (1903—1998)

Риза Фәхретдин улы Ишморатов 1903 елның 1 ноябрендә Башкортстанның Яңавыл районы Бәдрәш авылында туа. Башта үз авылларында, аннары Янбарыс мәдрәсәсендә һәм Савыштагы русча-татарча земство мәктәбендә башлангыч белем ала. 1916–1918 елларда укуын Минзәләдә һәм Уфаның «Госмания» мәдрәсәсендә дәвам иттерә. 1920 елда Уфадагы педагогик курсларны тәмамлагач, эчке иминлек гаскәрләрендә хәрби хезмәткәр, аннары Актаныш төбәгендә укытучы һәм Минзәләдә тәрбияче булып эшли.

1923 елның көзендә Риза Ишморат Казанга килә һәм театр техникумына укырга керә. 1926 елда аны тәмамлагач, Татар дәүләт академия театрында режиссер булып эшли. Шушы елларда аның драматургия өлкәсендәге эшчәнлеге башлана. Беренче әсәрләреннән саналган «Өтек философ» (1926) һәм «Йокы патшалыгында» (1926) исемле комедияләрен режиссер буларак үзе сәхнәләштерә.

1927–1930 елларда Риза Ишморат Ленинградта театр сәнгате буенча Югары курсларда укый һәм Казанга кайта. Утызынчы елларда аның заман таләпләрен яктырткан «Пожар» (1929), «Мәдинә» (1930), «Тургай» (1932), «Ил өчен» (1936), «Ватан» (1938), «Гөлзадә» (1940) кебек драмалары язылa. Алар татар һәм башкорт сәхнәләрендә кат-кат уйналып, тамашачының мәхәббәтен казана. Күпчелеге Р.Ишморат тарафыннан сәхнәгә куелган бу пьесалар утызынчы еллар татар театрында билгеле бер эз калдыра. Гомумән, театр эшлеклесе буларак, Р.Ишморат бу елларда гаять актив эшли. Ул төрле оешмаларда җитәкче урыннарны били, мәсәлән, Татар дәүләт академия театрының режиссерлар коллегиясен җитәкли. Режиссер буларак та нәтиҗәле эш башкара — К.Тинчуринның «Беренче чәчәкләр», «Алар өчәү иде» пьесаларын, В.Киршонның «Икмәк», «Гүзәл эретмә» драмаларын, Г.Иделленең «Дәүләт Бәдриев» исемле һ.б. уннарча әсәрләрне сәхнәгә куя.

Ватан сугышы елларында Риза Ишморат «Ватан намусы өчен» исемле фронт газетасында башта хәрби корреспондент, аннары газетаның җаваплы редакторы сыйфатында Воронеждан алып Берлинга кадәр авыр сугыш юлы уза. Берлиндагы урам сугышлары вакытында авыр яралана. Сугышчан хезмәтләре өчен ул күпсанлы орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә.

Р.Ишморат сугышның икенче елында, әле үзе фронтка киткәнче, «Кайту» (1942) исемле пьесасын язып, сәнгатьчә төгәлләнгән һәм тормышчан характерлар тудыра. Сугыш чорында «Дошман лагеренда» (1941), «Ватан кызлары» исемле әсәрләре туа.

Сугыштан соңгы пьесаларында драматург тормышның төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итә, сәхнәгә төрле-төрле һөнәр кешеләренең образларын чыгара. Аның драматургиясе жанр ягыннан да төрләнә; героик драма, лирик комедия, сатирик комедия кебек жанрларда әсәрләр иҗат итә: «Якты юл» (1947), «Якын дус» (1949), «Шайтан таягы» (1954), «Иске дуслар» (1957), «Серле моң» (1959), «Шаулыйлар дулкыннар» (1964). Тарихи шәхесләргә багышланган «Давылга табан» (1963), «Үлмәс җыр» (1955), «И мөкатдәс моңлы сазым» (1982) драмаларында В.Ульянов, М.Җәлил һәм Г.Тукай образларын тудыра.

Риза Ишморат пьесалары Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында түбәндәге елларда уйнала: «Өтек философ» (1926), «Йокы патшалыгында» (1926), «Яңача үлем» (1927), «Данлы чор» (1930), «Якты юл» (1947), «Якын дус» (1950), «Яңа Бистәдә» (1952), «Серле моң» (1960), «Алар дүртәү иде» (1962), «Тормыш дулкыннары» (1979).

Р.Ишморат — кырыкка якын сәхнә әсәре авторы. Аның күп кенә әсәрләре татар театрыннан тыш рус, башкорт, казакъ, үзбәк һ.б. милләт театрлары сәхнәләрендә дә уйнала.

Әдип язучы-публицист, тәрҗемәче, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, истәлекләр авторы буларак та билгеле. Аның туган-үскән яклары, андагы кешеләрнең авыр һәм мактаулы хезмәте турында язган «Сайрасын тургайлар» (1982) исемле документаль повесте укучылар тарафыннан хуплап каршы алына.

Әдәбият һәм театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Риза Ишморат 1953 елда — Татарстан АССРның, 1983 елда РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәргә лаек була.

Ул шулай ук Хезмәт Кызыл Байрагы ордены (1973) һәм ике тапкыр (1957, 1963) «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә.

Ул 1938 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Ишморат Р.** Сайланма әсәрләр 2 томда. — 1 т. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1966. — 429 б.

**Ишморат Р.** Гүзәл син, Хәят: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1973. — 216 б.

**Ишморат Р.** Давылга табан. Үлмәс җыр. Алар дүртәү иде (Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен). — Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. — 200 б.

**Ишморат Р.** Моңлы сазым: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1983. — 352 б.

**Ишморат Р.** Килер ул якты көн: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. — 350 б.

**Аның турында:**

**Иделле Г.** Данлы чор, үлмәс җыр турында уйланулар / Иделле Г. Язучы һәм аның китабы. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1964. — 106–113 б.

**Әхмәдуллин А.** Язучының гражданлык йөзе / Әхмәдуллин А. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — 196–202 б.

**Галимуллин Ф.** Тормыш имтиханы // Казан утлары. — 1988. — № 11. — 173–174 б.

**Кумысников Х.** Театрга багышланган гомер: Язучы, драматург Р.Ишморатка — 90 яшь // Татарстан хәбәрләре. — 1993. — 30 октябрь.

**Мәҗитов З.** Олы юл: Драматург Р.Ишморатка — 90 яшь // Шәһри Казан. — 1993. — 30 октябрь.

Риза Ишморатның тууына 100 ел // Казан утлары. — 2003. — № 10. — 177 б.

**Харис Р.** Ишморат алмагачы: Риза Ишморатның тууына 100 ел // Мәдәни җомга. — 2003. — 31 октябрь.

**Риза Ишморат.** Истәлекләр / Төз. Рөстәм Ишморатов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 239 б.

**Кумысников Х.** Театрга багышланган гомер. Язучы, драматург Риза ага Ишморатка — 90 яшь // Татарстан хәбәрләре. — 1993. — 30 октябрь.

**Ханзафаров Н.** Татарская комедия. — Казань: Фэн. — 1996. — С. 266.

## РӘИСӘ ИШМОРАТОВА (1917–1997)

Рәисә Гыйниятулла кызы Ишморатова (Чебдарова) 1917 елның 20 июлендә Татарстанның Чистай шәһәрендә туа. Җидееллык мәктәп һәм рабфакны тәмамлагач, Мәскәүдә азык-төлек институты каршындагы курсларда укый, 1937 елда Казан тегермәннәр трестында лаборант булып эшли.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Рәисә Ишморатова Арчадагы госпитальгә урнаша, 1943 елда фронтка җибәрелә, 1945 елга кадәр Украинада Дәүләт куркынычсызлыгы комитетында оператив бүлектә хезмәт итә. Казанга кайткач, шушы системада эшләп ала, 1952 елдан әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Беренче пьесасын ул 1952 елда яза. «Бай кияү» исемле бу әсәр Әлмәт профессиональ театрында сәхнәләштерелә. Бу уңыштан канатланып, тагы әсәрләр язылa — «Омтылыш», «Директор хатыны», «Фирая», «Куркыныч авыру», «Өйрәнелгән гадәт буенча», «Туганнар» пьесалары Татарстан һәм Башкортстан һәвәскәр драма түгәрәкләрендә яратып уйналалар.

1955 елда Рәисә Ишморатова студент яшьләр тормышы турында «Тормыш юлында» дигән дүрт пәрдәлек драма яза. Бу әсәре дә Татарстан республика Күчмә театрында (хәзер К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры), Башкортстан дәүләт академия театрында, Ауыргазы, Салават күчмә театрларында, Чуашстан, Мари Эл театрлары сәхнәләрендә куела.

1960–1970 елларда инде Рәисә Ишморатова тамашачылар белән очрашып, тормышның төрле якларын өйрәнеп иҗат итә, әсәрләре дә татар драматургиясендә лаеклы урын ала. «Әйтер идем йөрәк серемне» комедиясе, «Яшьлек канат җәйгәндә» пьесасы Республика театрларында куелган уңышлы спектакльләрдән саналалар, китап булып басылып чыгалар.

Ул 1977 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Ишморатова Р.** Тормыш юлында: Пьесалар. — Казан: Таткнигоиздат. — 1950. — 190 б.

**Ишморатова Р.** Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 112 б.

**Ишморатова Р.** Яшьлек канат җәйгәндә: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1971. — 303 б.

**Аның турында:**

**Кумысников Х.** Халык талантлары // Социалистик Татарстан. — 1963. — 9 июль.
**Хәбибуллин Ф.** Әйтер идем йөрәк серемне // Социалистик Татарстан. — 1964. — 31 декабрь.
**Зайнашева Г.** Наш друг Раиса // Сов. Татария. — 1967. — 26 окт.
**Зубаирова Д.** В творчестве — ее жизнь // Сов. Татария. — 1977. — 19 июня.
**Ихсанова Л.** Әйтер сүзе бар // Социалистик Татарстан. — 1977. — 19 июнь.

## ИСХАК КАЗАКОВ (1876–1939)

Исхак Мостафа улы Казаков 1876 елның 26 декабрендә Казан шәһәрендә бөлгән сәүдәгәр гаиләсендә туа. Мәдрәсәнең башлангыч классларын, рус шәһәр мәктәбен тәмамлап, 1893 елда Казан Татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. 1897 елдан элекке Вятка губернасы Сарапул өязе Кадабашы авылына укытучылык эшенә җибәрелә. Өч елдан соң Тәтештәге урыс-татар мәктәбенә күчерелә. Озакламый шушы мәктәпнең директоры итеп билгеләнә. Укучылар арасында хөкүмәткә каршы пропаганда алып баруда гаепләнеп, 1911 елның июнендә кулга алына һәм гаиләсе белән бергә ике елга башта Сембер, соңрак Оренбург губернасына сөргенгә җибәрелә.

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, И.Казаков 1917 елга кадәр солдат хезмәтендә була, Оренбург, Пермь, Нарва, Юрьевта хезмәт итә. Февраль һәм Октябрь инкыйлаблары вакыйгаларында актив катнаша, революцион күтәрелешләрнең инициаторы була. 1917 елда Мәскәүдә һәм Казанда уздырылган I һәм II Бөтенроссия мөселманнар съездында катнаша. 1917 елның сентябрендә демобилизацияләнеп, Тәтештә укытучылык эшен дәвам итә.

Совет чорында Казанда җитәкче урыннарда эшли. 1918–1919 елларда Үзәк Мөселман Комиссариатында коллегия әгъзасы, 1919–1921 елларда шул ук комиссариат коллегиясенең нәшрият бүлеге башлыгы, 1921–1923 елларда Татарстан Халык Комиссарлары Советы һәм Үзәк Башкарма Комитеты рәисе урынбасары вазифаларын башкара. Гомеренең соңгы елларында ТАССР социаль тәэминат халык комиссариатында идарә рәисе булып эшли. 1937 елда партиядән чыгарыла һәм кулга алына, 1939 елда төрмәдә үлә. Исеме һәм иҗаты 1957 елда реабилитацияләнә.

И.Казаковның ике пьесасы мәгълүм: «Казанга сәяхәт» исемле ике пәрдәле комедиясе 1909 һәм 1920 елларда ике тапкыр басыла. Заманында сәхнәдә еш уйнала, мәдрәсә һәм авыл сәхнәләрендә дә куела. Икенче әсәре — бер пәрдәле «Заман туе» (1920) исемле комедия.

Педагогик тәҗрибәсенә таянып, 1913–1914 елларда ул мәктәпләр өчен дә «Мөгаллиме рус» (1901) дәреслеге, «Рус мәктәбе» (1909), «Өйдә гимназия» (үзлегеннән укучылар өчен кулланма), барысы 8 кисәктән торган хезмәтләр яза һәм бастырып чыга.

Совет чорында «Казан—Чулман—Кара Идел төбәгенең үзәге» (1923), «Политграмота әлифбасы» (1925), «Җәмгыятьне өйрәнү методлары» (1926) һ.б. очерк һәм публицистик китаплары нәшер ителә.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Казаков И.** Казанга сәяхәт. — Казан, 1909.

**Казаков И.** Замана туе: Мәзәк 1 пәрдәдә. — Казан мәркәз мөселман хәрби һәйәте хозурлыгындагы сәяси шөгъбәнең нәшере, 1920. — 44 б.

**Казаков И.** Казанга сәяхәт. — Казан: Корылтай, 1920. — 30 б.

**Казаков И.** Казанга сәяхәт: Комедия. / Күңелле сәхнә. — 1958. — № 10. — 74–99 б.

**Аның турында:**

**Рәми И., Даутов Р.** Әдәби сүзлек: Элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 118–119 б.

Халык бәхете өчен көрәшүчеләр (җыентык). Икенче китап. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1985. — 171–174 б.
**Казаков Х.** Казаков Исхак Мустафиевич // Борцы за счастье народное. — Казань, 1983. — С. 162–165.
**Хузеева Л.** «Мне нужна только свобода и свобода» // Гасырлар авазы — Эхо веков. — 2002. — № 1–2. — С. 101–106.

## СӘЕТ КАЛЬМЕТОВ (1918–1992)

Драматург Сәет Гани улы Кальметов 1918 елның 10 апрелендә Башкортстанның Яңавыл эшчеләр поселогында туа. Яшүсмер малай Ташкентка туганнары янына китә, шунда җидееллык мәктәпне һәм сәнгать студиясен тәмамлый. Башта Ташкент, аннан соң 1939–1941 елларда Чиләбе татар театрларында художник-декоратор, ә Бөек Ватан сугышы башлангач, агитплакатлар чыгаручы художник булып эшли. 1943 елның җәендә ул үз теләге белән фронтка китә, Берлинга кадәр сугышчан юл уза.

Сугыштан кайткач, Сәет Кальметов 1959 елга кадәр Ютазы, Буа колхоз-совхоз театрларында режиссер, художник булып эшли. 1947 елда үзенең беренче сәхнә әсәрен — «Безнең кияү» исемле бер пәрдәлек комедиясен яза. Пьеса Буа, Мамадыш театрларында куела. Драматургның икенче әсәре — «Тын алан шаулый» (1951) тагын да зуррак уңыш казана һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында уйнала. Шул ук театрда авторның 1953 елда «Нуриянең дуслары» комедиясе куела. Шуннан соң ул Әлмәт драма театры белән иҗади хезмәттәшлектә 1950–1960 елларда «Соңгы очрашу», «Йолдызлар балкый», «Ышанычлы юлдаш», «Уйланырсың, кодагый», «Зәкия», «Сөенеч һәм көенеч» исемле драма һәм комедияләрен яза.

Сәет Кальметовның дистәдән артык драма әсәрләре төрле елларда «Үсү юлында» һәм «Күңелле сәхнә» кебек күмәк җыентыкларда һәм авторның үз китапларында басылып килә.

С.Кальметов 1965 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Кальметов С.** Шулай да була: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1972. — 140 б.
**Кальметов С.** Тын алан шаулый: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. — 176 б.

**Аның турында:**

**Ахунов Г.** Усал телле драматург: С.Кальметовка — 50 яшь // Казан утлары. — 1968. — № 5. — 143 б.
**Ахунов Г.** Каләмдәшебез бәйрәме // Социалистик Татарстан. — 1968. — 20 апрель.
**Зарипов Х.** Тын алан шаулый: С.Кальметовка — 60 яшь // Казан утлары. — 1979. — № 4. — 179–180 б.
**Әминов Ю.** Тормыш белән күзгә-күз // Социалистик Татарстан. — 1978. — 20 апрель.
**Камалов Б.** Иҗат ләззәте юлдаш булсын // Татарстан яшьләре. — 1978. — 20 апрель.
**Ишмуратов Р.** Расскажу о своем друге // Сов. Татария. — 1968. — 30 мая.

## ГАЛИӘСГАР КАМАЛ (1879–1933)

Галиәсгар Галиәкбәр улы Камалетдинов 1879 елның 6 гыйнварында (искечә 1878 елның 25 декабрендә) Казанда үз кул көче белән көн күрүче вак һөнәрче гаиләсендә туа. Сабый вакытын бабасында — әнисенең туган авылы Түбән Масрада (хәзер Арча районына керә) уздыра, алты яшендә авыл мәдрәсәсенә йөри башлый. Аннары, Казанга кайтып, «Госмания», «Халидия» мәдрәсәләрендә укый. 1893–1900 елларда шул заманның алдынгы карашлы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә, шул ук вакытта өч класслы рус мәктәбендә башлангыч белем ала.

Мәдрәсәдә укыган чакта ук әдәбият, театр сәнгате белән мавыга, рус спектакльләренә йөри. «Фауст» китабын, Ф.Халидинең «Рәдде бичара кыз»ын бик яратып укый. Үзе дә, иҗат дәрте уянып,

1898 елда «Бәхетсез егет» (I вариант) исемле тәүге драмасын яза. Беренче уңышы белән канатланып, төрек язучысы Н.Кәмалның «Кызганыч бала» драмасын татарчалаштыра. Бу елларда үз чорының актуаль мәсьәләсен яктырткан «Өч бәдбәхет» исемле пьесасы да дөнья күрә.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлап, Г.Камал 1901 елда «Мәгариф көтепханәсе» оештыра һәм китап басу, тарату эше белән шөгыльләнә башлый. 1905 елдан татар журналистикасын булдыру-үстерү эшенә алына, газета-журналлар чыгаруны оештыра. Башта «Казан мөхбире» исемле газетада эшли, аннары 1906 елның февралендә «Азат» газетасына күчә, аның фактик редакторы була. Шул ук елның июнендә бу газетаның исеме «Азат халык» дип үзгәртелә һәм ул бөтенләй Г.Камал редакторлыгында чыга башлый. Ләкин «Азат халык»ның гомере озын булмый: унбиш саны чыкканнан соң, ул демократик рухтагы мәкаләләр өчен патша цензурасы тарафыннан туктатыла һәм 1906 елда нашире Г.Камал хөкемгә тартыла.

Аннары ул журналист һәм публицист Һ.Максуди чыгара торган «Йолдыз» газетасына эшкә килә һәм биредә 1917 елның октябренә кадәр эшли. Шулай ук 1908–1909 елларда Г.Тукай белән берлектә татар телендә беренче сатирик журнал — «Яшен»не чыгара. Бу журналның редакторы булу өстенә, Г.Камал язучы, карикатурист-рәсем төшерүче булып та актив катнаша. «Яшен» ябылгач, «Ялт-йолт» көлке журналында да эшен шул юнәлештә дәвам итә.

Г.Камал — татар милли театрын үстерү эшенә зур көч куйган шәхес. Ул, театр репертуарын драма әсәрләре белән баетудан тыш, «Сәйяр» труппасында артист һәм режиссер булып та эшли. Татар театры тарихында актерлар династиясен башлап җибәрә: энеләрен һәм сеңлесен сәхнәгә алып килә. Соңрак улы Әнәс тә драматург, сәләтле режиссер һәм артист булып китә.

1906 елның 22 декабрендә Казанда Яңа клуб бинасында беренче рәсми спектакль — Г.Камалның тәрҗемә әсәре «Кызганыч бала» сәхнәләштерелә. Әдипнең якыннан катнашуы һәм практик ярдәме белән оештырылган әлеге ачык спектакль куелу көне татар мәдәнияте тарихына татар профессиональ театрының туу датасы булып теркәлә.

Профессиональ театр туу Г.Камалны иҗатка рухландыра. 1907—1912 еллар аралыгында үзенең иң көчле, сәнгатьчә иң камил булган әсәрләрен яза. Нигездә, ул драматургиянең ике жанрында иҗат итә. «Бәхетсез егет» (1907, икенче варианты), «Уйнаш» (1910, «Өч бәдбәхет»нең үзгәртелгән варианты), «Дәҗҗал», «Каениш», «Көндәш», «Өйләнәм — ник өйләндем» кебек драмаларында җәмгыятьтәге әхлакый түбәнлек, кешелексезлек проблемалары яктыртыла. «Беренче театр» (1907), «Бүләк өчен» (1908), «Банкрот» (1911), «Безнең шәһәрнең серләре» (1912) исемле комедияләре үз чорының актуаль мәсьәләсен, тормышчан вакыйгаларны сәхнәгә күтәрү белән аерылып тора. Г.Камал үзен комик ситуация, сатирик тип тудыру остасы итеп таныта. Аның драмаларына композицион бөтенлек, халыкчанлык хас. Әсәрләр «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәләштерелеп, халык арасында популярлык казана.

Г.Камал театр репертуарын рус һәм дөнья классикларының әсәрләрен татарчага тәрҗемә итеп тә баета: Н.Кәмал — «Кызганыч бала» (1900), А.Н.Островский — «Яшенле яңгыр» (1914), Мольер — «Саран» (1915), «Ирексездән табиб» (1916), «Скапен хәйләләре» (1924), Н.В.Гоголь — «Ревизор» (1916), Г.Хәмид — «Һинд кызы» (1918), А.Дюма — «Чәчәкле хатын» (1924) һ.б. Бу тәрҗемә пьесалар шул еллардагы театр сәхнәләрендә кат-кат уйналып, татар сәнгатен идея-эстетик яктан баета, аның үсешенә уңай йогынты ясый.

Октябрь революциясеннән соң Г.Камал «Эш», «Эшче», «Кызыл көрәшче» газеталарында чор таләпләренә буйсынып язылган күпсанлы сәяси, сатирик шигырьләр-декламацияләр бастыра. Егерменче елларда һәм утызынчы еллар башында «Тәкый гаҗәб, яки Ахыры заман», «Могҗиза», «Ысул кадимче», «Җантаһир белән Җанзөһрә» исемле сатирик комедияләр, «Хафизәләм-иркәм» (1921–1922), «Күзсез мастерлар» (1930), «Өч тормыш» (1930) исемле драмалар, кечкенә күләмле эстрада әсәрләре яза. «Хафизәләм-иркәм» әсәре Татар академия театры сәхнәсендә 1922, 1949 елларда уйнала.

1923 елда Г.Камалга иҗат эшенең 25 еллык бәйрәме уңае белән Хезмәт Батыры, ә 1926 елда «Татарстанның халык драматургы» дигән мактаулы исемнәр бирелә.

**Басылган драма әсәрләре:**


**Камал Г.** Әсәрләр 3 томда. — 1 т. Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. — 406 б.

**Камал Г.** Әсәрләр 3 томда. — 2 т. Пьесалар, эстрада әсәрләре, шигырьләр (1905–1933). — Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. — 544 б.

**Камал Г.** Әсәрләр 3 томда. — 3 т. Хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр, истәлекләр (1900–1933) / Томны төзүче, текст һәм искәрмәләрне әзерләүчеләр З.Рәмиев һ.б. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. — 416 б.

**Камал Г.** Әсәрләр. — 1 т. Драматургия әсәрләре (1898–1933) / М.Гайнуллин сүз башы. — Казан: Татгосиздат, 1950. — 438 б.

**Камал Г.** Сайланма әсәрләр: Пьесалар, хикәяләр, истәлекләр / Төз. Р.Корбан. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 302 б.

Татар классик драматургиясе: Галиәсгар Камал. Мирхәйдәр Фәйзи / Ф.Ганиева кереш мәкаләсе белән. — Казан: Хәтер, 2004. — 463 б.

**Аның турында:**

**Камал Ә.** Халык драматургы Г.Камал. — Казан: Татгосиздат, 1950.

**Камал Ә.** Гүзәл тормыш сәхифәләре. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1958. — 78 б.

**Абдуллин И.** Г.Камал драмаларының теле. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1968. — 198 б.

**Гайнуллин М.** Галиәсгар Камал (1879–1933). Тормышы һәм иҗат юлы. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1978.

Галиәсгар Камал турында истәлекләр / Төз. Р.Даутов. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. — 192 б.

Галиәсгар Камал: Язучының 100 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы / Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм тарих инс-ты. Редкол.: А.Әхмәдуллин һ.б. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. — 224 б.

**Гыйззәт Б.** Галиәсгар Камал / Татар әдәбияты тарихы 6 томда. — 3 т. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 383–402 б.

Галиәсгар Камал. Альбом / Төз. Г.Камал II, ред. И.Г.Камал, җав. ред. һәм кереш сүз авт. Г.Кашшаф. — Казан: Титул, 2003. — 123 б.

Галиәсгар Камал: Әдип һәм заман: язучының 125 еллыгына багышланган мәкаләләр җыентыгы / ТФА, ТӘҺСИ / Редкол. — М.Арсланов (төз.-ред.) һ.б. — Казан: ИЯЛИ АН РТ, 2005. — 155 б.

**Ханзафаров Н.** Татарская комедия. — Казань: Фэн. — 1996. — С. 266.

## ӘНӘС
## КАМАЛ
## (1908–1978)

Әнәс Камал (Әнәс Галиәсгар улы Камалетдинов) 1908 елның 20 февралендә Казанда татар драматургиясе классигы Галиәсгар Камал гаиләсендә туа. Кече яшьтән үк әдәбият һәм сәнгать белән кызыксына башлый. Үзенең беренче комедиясе «Хуҗа Насретдин әфәнде»не язганда аңа әле 13 яшь тә булмый. 1924 елда артист Ш.Фәхриев бенефисына «Чегән бәете» нигезендә «Чегән егете белән качкан мулла кызы Хәмидә» дигән 4 пәрдәле драма иҗат итә. 1925 елда исә Әнәс Камал агасы артист Габдулла Камал I өчен өч пәрдәле «Җизнәкәй» дигән музыкаль комедия яза. Әсәрне Габдулла Камал үзе оештырган вакытлы күчмә труппада сәхнәгә куя. Кызганыч, Ә.Камалның тәүге әсәрләре әле матбугатта басылмый, шуңа да карамастан аның өметле генә яшь драматург икәнлеге билгеле була.

«Сәйяр» труппасының Габдулла Кариев, Касыйм Шамил кебек өлкәннәре Әнәс Камалны сигез яшендә чагында ук сәхнәгә менгерәләр. Әнәс труппаның «Шәрык клубы»нда уздырылган кичәләрдә концерт номерларында, хорларда катнаша, шигырьләр сөйли. 1918 елдан аңа рольләр дә бирә башлыйлар. «Сәйяр» труппасы Татар дәүләт театрына әйләнгәч, театр каршында Касыйм Шамил җитәкчелегендә балалар труппасы оештырыла. Кечкенә Әнәс труппага артист итеп алына, аның спектакльләрендә актив катнаша һәм 1927 елга кадәр шунда эшли.

Әдәбиятка һәм сәнгатькә булган мәхәббәт Әнәс Камалны 1928 елда Казан сәнгать техникумының театр бүлегенә алып килә. Шунда укыган вакытта 1929 елда Г.Нагаев оештырган эшче дәүләт театрында әдәби бүлек мөдире булып эшли. Театр өчен кече формалы әсәрләр яза.

1931 елда техникумны тәмамлаганнан соң, Ә.Камал Татарстанда яңа оешкан беренче районара колхоз-совхоз театрына сәнгать эшләре җитәкчесе итеп җибәрелә һәм шунда 1934 елга кадәр режиссер да, артист та, художник та, хәтта соңрак директор да була. Шул ук вакытта иҗат эшчәнлеген дә туктатмый. Ул аеруча бер пәрдәлек пьеса һәм комедияләр язучы драматург буларак танылa. Ә.Камалның 1931 елда «Ике көч» һәм «Давыл» әсәрләрен эченә алган беренче җыентыгы дөнья күрә.

1935 елда беренче колхоз-совхоз театры нигезендә Минзәлә профессиональ театры оешканнан соң, Ә.Камал Казанга кайта һәм 1955 елга кадәр «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журна-

лы редакциясендә әдәби хезмәткәр, Татарстан китап нәшриятында редактор һәм Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант вазифаларын башкара. Бу елларда драматургның иҗат активлыгы тагы да арта. Бер-бер артлы «Үз кеше», «Туй», «Яз якынлаша», «Иске Казанда», «Сәлам хат», «Март бураннары» дигән күп пәрдәле һәм бер пәрдәле әсәрләре языла. Ватан сугышыннан соң, язучы Халикъ Садри белән бергә «Юллар» һәм «Бәхет нурлары» исемле зур күләмле әсәрләр тудыралар. Бу әсәрләр барысы да вакытында Казан, Мәскәү, Әстерхан, Ташкент, Баку, Кучмә, Минзәлә, Буа театрлары сәхнәләрендә куелып уңыш казана. Болардан тыш, Әнәс Камал үзешчән сәнгать түгәрәкләре өчен 20 дән артык берәр пәрдәле комедия, драмалар яза.

Драматург, авыл тормышын тасвир иткән пьесалар язу белән бергә, балалар өчен дә сәхнә әсәрләре тудыра. Ул Татар дәүләт курчак театры өчен Г.Тукайның мәшһүр «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» дигән сатирик поэмасы нигезендә «Кисекбаш» (1951) исемле пьеса язып куйдыра һәм аерым китап итеп бастырып чыгара. Күренекле балалар язучысы А.Гайдарның «Школа» («Мәктәп») исемле повестен һәм башка язучыларның әсәрләрен тәрҗемә итә.

Ә.Камал этисе Г.Камал («Гүзәл тормыш сәхифәләре», 1958) һәм башка күренекле тарихи шәхесләр турында тирән эчтәлекле хикәяләр һәм истәлекләр иҗат итә.

Ул 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Камал Ә.** Клуб пьесалары. — Казан: Татгосиздат, 1941. — 278 б.

**Камал Ә.** Комедияләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1955. — 80 б.

**Камал Ә.** Сайланма пьесалар (Авторның биографик белешмәсе белән). — Казан: Тат. кит. нәшр., 1958. — 207 б.

**Камал Ә.** Комедияләр һәм скетчлар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1966. — 123 б.

**Камал Ә.** Беренче тургайлар: Пьесалар һәм истәлекләр / Р.Ишморат сүз башы. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. — 240 б.

**Камал Ә.** Март бураннары: Пьесалар, хикәяләр, истәлекләр / Р.Даутов кереш сүзе. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. — 272 б.

**Аның турында:**

**Зәйни Ш.** Драматург үткән юл // Казан утлары. — 1968. — № 3. — 154–156 б.

Әнәс Камалга — 70 яшь // Казан утлары. — 1978. — № 2. — 181 б.

**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 235–236 б.

## ШӘРИФ КАМАЛ (1884–1942)

Шәриф Камал (Шәриф Камалетдин улы Байгилдиев) 1884 елның 27 февралендә элекке Пенза губернасы Инсар өязе (хәзерге Мордва республикасы Рузаевка районы) Пешлә авылында мулла гаиләсендә туа. Башта үз авылы мәдрәсәсендә укый, 12 яшендә күрше Ләбәҗә кадим мәдрәсәсенә җибәрелә. Шәкерт чагыннан ук үз көнен үзе күрә башлый: шул елларда яңа салына башлаган Мәскәү — Казан тимер юлында төрле эшләрдә эшли, 1900 елларда, сәүдәгәрләргә ялланып, Рига якларына барып чыга. Белем алу теләге аны Төркия, Мисыр якларына илтә. Ләкин матди хәле авыр булу сәбәпле, 1903 елда кабат Россиягә кайта һәм Украинадагы күмер шахталарында, Каспий диңгезе буендагы балык промыселларында үз кул көче белән көн күрә.

1905 елгы революцияне Ш.Камал Петербургта мөгаллим булып каршылый. Шул ук вакытта ул «Нур» исемле беренче татар газетасы редакциясендә корректор булып эшли һәм әлеге матбугат битләрендә беренче мәкаләләрен бастыра. 1906 елда аның «Сада» («Аваз») исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

Илдә кара реакция еллары башлангач, Ш.Камал үз авылларына кайта һәм 1910 елга кадәр мәдрәсәдә балалар укыта. Шунда беренче хикәясе «Уяну»ны яза һәм Оренбургка «Шура» журналына җибәрә. Озакламый хикәя басылып та чыга.

1910 елда Ш.Камал, гаиләсен ияртеп, Оренбургка күчеп килә. «Шура» редакциясендә хисапчы, аннары «Вакыт» газетасының корректоры, соңрак әдәби хезмәткәре булып эшли.

Оренбургта яшәү дәверендә Ш.Камал зур активлык белән иҗат итә: утыздан артык хикәя, дистәләрчә фельетон һәм мәкалә, атаклы «Акчарлаклар» (1914) повестен һәм «Хаҗи әфәнде өйләнә» (1915) сатирик комедиясен яза. Комедия 1917 елда «Сәйяр» театры труппасы (режиссер Ш.Сарымсаков) тарафыннан сәхнәләштерелә.

Октябрь революциясен Ш.Камал Оренбургта каршылый һәм иҗатын да яңа тормышны саклау эшенә багышлый.

1925 елның көзендә Ш.Камал Казанга җибәрелә һәм «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә партия бүлеге мөдире итеп билгеләнә. Соңыннан Татарстан мәдәнияте йортында гыйльми сәркатип (1928), Главлит хезмәткәре (1929–1932), Татар дәүләт академия театрының әдәбият бүлеге мөдире (1933–1935) вазифаларын башкара. Гомеренең соңгы елларында язучылык эше белән генә шөгыльләнә.

Совет чорында «Таң атканда» (1927), «Матур туганда» (1937) кебек зур күләмле романнар язу белән бергә, Ш.Камал күпсанлы драма әсәрләре дә иҗат итә. 1928–1934 еллар арасында аның борбер артлы «Ут» (1928), «Козгыннар оясында» (1929), «Таулар» (1931), «Томан арты» («Габбас Галин», 1934) исемле әсәрләре языла. 1910 елда язылган «Козгыннар оясында» хикәясе 1929 елда режиссер С.Вәлиев тарафыннан сәхнәләштерелә. Башта ул Казанның Зур рус театрында куела һәм рус сәхнәсендә уйналган беренче татар пьесасы булып санала.

Бөек Ватан сугышы башлангач та Ш.Камал зур иҗади планнар белән яши, трилогия язу өчен актив рәвештә материал туплый, «Сафура» исемле пьеса иҗат итә башлый. Ләкин 1942 елның 22 декабрендә әдип кинәт вафат була.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Ш.Камалның түбәндәге пьесалары куела: «Хаҗи әфәнде өйләнә» (1927, 1959), «Ут» (1928, 1954), «Козгыннар оясында» (1929, 1936, 1948), «Таулар» (1931), «Томан арты» (Габбас Галин)  (1934, 1942), «Карчыга» (1959).

Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ш.Камал 1940 елда Ленин ордены белән бүләкләнә. Аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә. 1939 елда Казан шәһәр Советына депутат итеп сайлана.

Ш.Камал 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**


**Камал Ш.** Әсәрләр. 2 нче басма. — 2 т. Драмалар. — Казан: Татгосиздат, 1950. — 343 б.

**Камал Ш.** Әсәрләр 4 томда. — 2 т. Драмалар. — Казан: Татгосиздат, 1952. — 344 б.

**Камал Ш.** Хаҗи әфәнде өйләнә: Комедия 3 пәрдәдә, 4 картинада. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1954. — 68 б.

**Камал Ш.** Сайланма әсәрләр 3 томда. — 3 т. Пьесалар. Роман. Мәкаләләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. — 415 б.


**Аның турында:**


**Кашшаф Г.** Шәриф Камал. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1940. — 141 б.

**Гайнуллин М., Вәзиева Җ.** Ш.Камал: Тормышы һәм иҗаты / Гайнуллин М., Вәзиева Җ. Татар әдәбияты. XX йөз. 2 нче кисәк. Казан: Тат. кит. нәшр., 1954. — 203–232 б.

**Нигъмәти Г.** Ш.Камал — драматург / Нигъмәти Г. Сайланма әсәрләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1958. — 147–153 б.

**Хисмәтуллин Г.** Шәриф Камал / Татар совет әдәбияты тарихы: Очерклар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 403–439 б.

**Нуруллин И.** Ш.Камал иҗаты: Мәкаләләр. — Казан: Казан университеты нәшр., 1963. — 70 б.

**Нигъмәтуллин Ә.** Шәриф Камал. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1964. — 172 б.

**Нигъмәтуллин Ә.** Шәриф Камал / Татар әдәбияты тарихы 6 томда. — 4 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 401–415 б.

**Ханзафаров Н.** Татарская комедия. — Казань: Фэн. — 1996. — С. 266.


## ГАБДУЛЛА
## КАРИЕВ
## (1886–1920)

Габдулла Хәйрулла улы Кариев (Миңлебай Хәйруллин) 1886 елның 8 маенда элекке Чистай өязе Күлбай Мораса авылында дөньяга килә. Туган авылында белем алганнан соң, 1896 елдан күрше Такталы авылы мәдрәсәсендә укый башлый. Гадәттән тыш сәләтле һәм зирәк, инде уникe яшендә Коръәнне яттан белгән шәкерткә Такталы мәдрәсәсе мөдәррисе Зариф мулла, «мужик исеме йөртмә» дип, Габдулла исемен бирә. Шуннан соң Миңлебай Хәйруллин халык арасында Габдулла Кариев буларак танылa.

1904 елда Габдулла Җаек шәһәрендәге «Мотыйгия» мәдрәсәсенә укырга керә. Бирeдә ул Габдулла Тукай, Камил Мотыйгый кебек атаклы кешеләр белән аралаша һәм дуслаша.

1907 елда Габдулла Кариев Түбән Новгород шәһәрендә булачак «Сәйяр» артистлары белән очраша һәм тормышын гомерлеккә театр белән бәйли.

Күпкырлы талант иясе Г.Кариев татар театрын һәм мәдәниятен үстерүгә зур көч куя. Ул, артист буларак, сәхнәдә кабатланмас образлар иҗат итә. Мәсәлән, Кәрим («Бәхетсез егет»), Хәмзә («Беренче театр»), Әхмәтҗан («Бүләк өчен»), Мөхәммәтша («Соңгы сәлам») һ.б. — болар һәрберсе үзенчәлекле, тик артист Кариевка гына хас осталык белән эшләнгән монументаль сәхнә образлары булып тора.

Озак еллар «Сәйяр» труппасының җитәкчесе һәм директоры булып эшләгән Г.Кариев милли репертуар булдыруга аеруча зур игътибар бирә. Татар халкының талантлы драматурглары Г.Камал, М.Фәйзи, К.Тинчурин, Г.Исхакый, Ф.Әмирханнар белән тыгыз элемтәдә тора һәм театр репертуарын аларның әсәрләре белән тулыландыра. Шулай ук дөнья классиклары әсәрләрен кую өчен рус режиссерларын да чакырта.

Яшь театр репертуарын баету нияте белән, Г.Кариев татар артистлары тормышын һәм чиккән михнәтләрен тасвирлаган «Артист» исемле комедия яза. Бу комедиясе белән ул әдәбиятка артистлар тибын алып килә. Пьесадагы образларның прототиплары тормыштан алына: артист Сакмарский образында Г.Кариев, аны туры юлга өндәүче абыйсы Ислам — Г.Кариевның туганнан туган Латыйф абыйсы, ә Шәңгәрәйский образында артист Бари Болгарский тормышы чагыла. «Артист» комедиясе күп тапкыр сәхнәдә уйнала, 1914 елда аерым китап булып басыла.

1912 елда Г.Кариевның сәнгать юлындагы зур хезмәтләрен хөрмәт итеп, татар зыялылары һәм киң җәмәгатьчелек аны «татар театрының атасы» дигән мәртәбәле сүзләр белән бәяли.

Революциядән соң кабынып киткән гражданнар сугышы вакытында Г.Кариев Уфада яшәп ала, иҗади эшчәнлеген туктатмый, 1919 елның азагында Казанга кайта һәм хәрби коллегия каршында төзелгән татар театрына эшкә керә. Ләкин аңа монда эшләү насыйп булмый: артист тиф белән авырып китә һәм 1920 елның 28 гыйнварында 34 яшендә вафат була.

Татар театрына нигез салучы Г.Кариев үзе төзегән театр мәктәбе традицияләрен сәхнә сәнгатен тирән белүче К.Тинчуринга ышанып тапшырып калдыра.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Кариев Г.** Артист: Татар пьесалары. Антология. Беренче китап. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1987. — 232–247 б.

**Аның турында:**

Габдулла Кариев турында мәкаләләр, истәлекләр, документлар / Төз. Х.Гобәйдуллин. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. — 232 б.

**Арслан Г.** «Татар театрының атасы»: Г.Кариевның тууына 110 ел // Ватаным Татарстан. — 1996. — 21 май.

**Исхакый Г.** Артист Габдулла Кариев // Казан утлары. — 1999. — № 11. — 173–176 б.

**Гыймранова Д.** Бөек актер // Шәһри Казан. — 2003. — 20 июнь.

**Ханзафаров Н.** Габдулла Кариев. Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. — Казан, 2005. — 128–129 б.

## ГАФУР
## КАЮМОВ
## (1959)

Гафур Шәкүр улы Каюмов 1959 елның 2 мартында Татарстанның Арча районы Яңа Сәрдә авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, армия сафларында хезмәт итә. 1979–1983 елларда Казан театр училищесында актерлык осталыгы бүлегендә укый. Укуын тәмамлауга, аны Республика күчмә театрына (хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) эшкә чакыралар. 1990 елдан 1997 елга кадәр ул — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты. Ике театрда да Гафур Каюмов төп рольләрдә уйный: Исмәгыйль (М.Фәйзи. Галиябану), Мирзахан (Т.Гыйззәт. Ташкыннар), Сәяр (Ш.Хөсәенов. Әни килде), Месье Таккарель (А.Лябиш. Тол ханымда тукталыш), Сәлимҗан (Г.Исхакый. Зөләйха), Алмаз (М.Гыйләҗев. Казан егетләре), Искәндәр (М.Фәйзи. Асылъяр) һ.б.

Сәхнә аны киңрәк мәйданга да алып чыга: ул «Болгарның җылы җилләре» нәфис фильмында Алмыш хан улы Бәйбарс, «Зөләйха» нәфис фильмында Сәлимҗан һәм «Галиябану» телефильмында Хәлил рольләрен башкара.

Гафур Каюмовны режиссерлык эше мавыктыра һәм ул 1994–1999 елларда Мәскәү институтының мәдәният, сәнгать хезмәткәрләрен режиссерлыкка әзерләү бүлегендә укый, Болгария Республикасының Милли академиясендә театр факультетында белемен күтәрә.

Театр һәм кино сәнгатендә шактый тәҗрибә һәм белем туплаган Гафур Каюмов 1980 еллардан башлап драма әсәрләре иҗат итә башлый. Шәхес буларак үзен раслау, дөньяга карашларын дәлилләү мәйданы дип ул театрны саный, сәхнәдән әйтелгән сүзләргә тирән фикерләр салынырга тиеш дигән таләптән чыгып иҗат итә. Бу өлкәдәге эшчәнлеге дә аңа иҗат куанычлары алып килә: пьесалары төрле театрларда куела, кызыклы спектакльләргә әверелә. «Упкын өстендә уен» 2 пәрдәлек трагифарс жанрында язылган әсәре, «Кабан күле серләре» пьесасы Г.Камал исемендәге, Тинчурин исемендәге, Чаллы, Минзәлә, Әлмәт, Түбән Кама театрларында, Башкортстанның «Нур», Уфа башкорт яшьләре театрларында, Туймазы, Сибай, Салават шәһәрләре театрларында һәм Оренбург татар драма театрында, Мари Эл драма театры сәхнәләрендә куела. Бу инде үзе үк Гафур Каюмовның драматургиягә килүе очраклы булмавы турында сөйли.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында аның «Мирас» (1990), «Һинд кызы» музыкаль комедиясе (1992), «Сарык арыслан» притча-әкияте (1997) куела.

Гафур Каюмов драматургиянең төрле жанрларына мөрәҗәгать итә, сәхнә законнарын белеп, шартлы алымнарны уңышлы файдаланып яза. Бүгенге көнгә кадәр язылган «Язмышлар ярында», «Юбилей», «Сагынырсың әле син дә бер...», «Ак баба иле», «Ахырызаман авазы», «Эх, Алла боерса», «Ач күзеңне — монда мин...», «Таныштыру-кавыштыру бюросы», «Соң инде», «Аномалик табигать күренеше», «Ыру», «Әрнү» пьесалары драматургның үсеш юлында әһәмиятле бер этапны хасил итәләр.

1997–2000 елларда ул Мәдәният министрлыгында, 2000–2004 елларда Татарстан телевидениесендә эшләп ала. 2004 елдан башлап Гафур Каюмов — Әлмәт дәүләт театрында баш режиссер.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Каюмов Г.** Упкын өстендә уен: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 383 б.

**Аның турында:**

**Аймәтов Р.** Мирас кемгә тиеш?: Театрда премьера // Татарстан яшьләре. — 1990. — 12 ноябрь.
**Миңнуллин Т.** Хәерле юл, егетләр! // Социалистик Татарстан. — 1991. — 15 март.
**Сәгъди Р.** «Ач күзеңне — монда мин...» // Шәһри Казан. — 1993. — 15 июль.
**Габәши А.** В Казани поселилась «Индианка». — Изв. Татарстана. — 1993. — 2 марта.
**Закирҗанов Ә.** Ышанычсыз ничек яшәргә?: Драматург Г.Каюмовның «Мирас» әсәре турында / Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 91–94 б.

## ГАФУР КОЛӘХМӘТОВ (1881–1918)

Гафур Коләхмәтов (Габделгафур Юныс улы Коләхмәтов) 1881 елның 5 маенда Пенза шәһәрендә сабын-шәм заводы хуҗасы гаиләсендә туа. 1888 елда, ягъни Гафурга җиде яшь тулганда, Коләхмәтовлар бөлә. Юныс ага гаиләсе белән Саратов губернасына күченеп, 1897 елга кадәр алпавыт утар-

ларында управляющий, бакчачы булып тора. Соңыннан, Казанга килеп, Үтәмишевләрнең сабын заводына баш мастер булып урнаша.

Гафур башта Пенза губернасының Түбән Ломов өязе Ятмис авылында мәдрәсәдә белем ала. Казанга күчкәч, 1898–1902 елларда Татар укытучылар мәктәбендә укый. Үзлегеннән рус һәм Европа әдәбияты, тарихы һәм иҗтимагый фикере белән таныша. Укытучылар мәктәбендә укыганда яшерен революцион түгәрәк эшчәнлегендә катнаша, беренче татар революционерлары Х.Ямашев, Г.Сәйфетдинов белән якыная.

Укытучылар мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казанның эшчеләр бистәсенә (хәзерге Коләхмәтов урамы, 17 нче йорт) урнашкан, дәүләт исәбенә ачылган өч класслы мәктәпкә укытучы булып килә. Анда ул 1911 елның җәенә кадәр эшли. 1911 елның сентябреннән Казандагы «Касыймия» (Апанай) мәдрәсәсе каршында оештырылган рус классларына укытучы һәм мөдир булып күчә һәм бу хезмәтен 1916 елның ноябренә кадәр дәвам итә.

Мәктәптә укыту белән бергә, Г.Коләхмәтов революцион эшчәнлек тә алып бара. Х.Ямашев белән бергә листовкалар тәрҗемә итә, «Искра» идеяләрен пропагандалый. Ул яшәгән йорт прокламацияләр саклау, яшерен җыелыш үткәрү, революционерларны полиция эзәрлекләвеннән яшеренеп тору һ.б. өчен хезмәт итә. Г.Коләхмәтов 1905 елгы революциянең үзәгендә кайный, корал тотып сугыша. Революционерлар белән бергә кулга алына һәм төрмәдә утырып чыга.

Г.Коләхмәтов революцион идеяләрне халыкка җиткерүдә публицистиканы — «Азат», «Азат халык» газеталарын трибуна итеп файдалана, большевикларның басма органы булган «Урал» газетасын чыгаруда зур көч куя, ягъни татар революцион публицистикасына нигез салучылардан санала.

Г.Коләхмәтов татар мәдәни дөньясындагы бик күп башлангычларның үзәгендә тора. Милли театр оештыру эшендә актив катнаша. Үзе дә сәхнәгә күтәрелә, 1903–1905 елларда һәвәскәрләр тарафыннан куела торган спектакльләрдә аерым рольләр башкара. «Яшьләр» труппасының артисты булып китә. Мәсәлән, Г.Камалның «Бәхетсез егет» драмасында Кәрим бай, «Мөсибәте Фәхретдин»дә Фәхретдин һ.б. бик күп рольләрне уйный. «Әль-ислах» газетасының рецензияләрендә артист Ширалиев (Г.Коләхмәтовның сәхнә псевдонимы) һәрчак югары бәяләнеп килә. Ул үзе генә түгел, туганнарын да сәхнәгә күтәрә. Сәхнәдән киткәч тә, Коләхмәтов театр белән тыгыз бәйләнештә яши. «Сәйяр» труппасы уйный торган «Шәрык клубы»нда Аксакаллар шурасының даими әгъзасы булып тора.

Г.Коләхмәтовның 4 пьеса язуы мәгълүм. Беренче әсәре булган «Ике фикер» драмасы (1906) белән үк ул татар драматургиясенә идея һәм форма яңалыгы алып килә. Аллегорик образлар Кызыл фикер һәм Кара фикер көрәше аша шул чор җәмгыятендә барган идеяләр бәрелеше һәм интеллигенциянең революциягә, пролетариатка килү юлы күрсәтелә. Әсәр беренче тапкыр Казанда 1918 елның 18 декабрендә «Кызыл һәм Кара» исеме белән сәхнәгә куела һәм шул елларда төрле сәхнәләрдә зур уңыш казана.

Икенче сәхнә әсәре «Яшь гомер» (1907) исемле биш пәрдәлек драмасы революция һәм интеллигенция, шәхес иреге кебек проблемаларны эзоп теле аша яктырта. Әсәр 1905 елгы азатлык хәрәкәтендә катнашкан яшьләр һәм татар эшчеләре тормышыннан алып язылган. Татар театры Октябрь революциясен «Яшь гомер» драмасын куеп каршылый.

«Ике фикер» һәм «Яшь гомер» драмаларында үз чорының бик күп иҗтимагый мәсьәләләре күтәрелә, фикер көрәше зур урын тота, шунлыктан бик еш публицистик алымнар кулланыла. Бу әсәрләр сәяси драмага якын тора.

Болардан тыш, Г.Коләхмәтов 1902–1912 еллар арасында «Уалган мол» исемле революцион эчтәлекле әсәр тәрҗемә итә, дүрт пәрдәлек «Әбүҗәһел» тарихи драмасын, «Кем гаепле?» исемле биш пәрдәлек драмасын яза. Вакытында матбугатта басылмау сәбәпле, аларның кайберләре сакланып калмаган.

Г.Коләхмәтов татар драматургиясе тарихында татар пролетариат әдәбиятына нигез ташлары салучы буларак урын ала.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Коләхмәтов Г.** Сайланма әсәрләр / М.Гайнуллин сүз башы белән. — Казан: Татгосиздат, 1950. — 120 б.

**Коләхмәтов Г.** Яшь гомер: Сайланма әсәрләр / Фән. ред. А.Әхмәдуллин. Төз. И.Абдуллин. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. — 384 б.

**Аның турында:**

**Гайнуллин М., Вәзиева Җ.** Татар әдәбияты. XX йөз. 1 нче кисәк. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1954. — 287–310 б.
**Хәйри Х.** Гафур гаиләсе / Х.Хәйри. Язучы һәм тормыш. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. — 209–214 б.
**Гыйззәт Б.** Гафур Коләхмәтов (1881–1918): Тормышы һәм иҗаты турында кыскача очерк. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. — 40 б.
**Гыйззәт Б.** Гафур Коләхмәтов / Татар әдәбияты тарихы 6 томда. — 3 т. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 402–421 б.
**Кашапова Г.** Г.Коләхмәтов драмаларында шәхес проблемасы // Фәнни язмалар. — 2002. — 235–238 б.

## РАФИС КОРБАН (1957)

Рафис Корбан (Рафис Харис улы Корбанов) 1957 елның 1 гыйнварында Татарстанның Биектау районы Кече Битаман авылында крестьян гаиләсендә туа. Туган авылындагы дүртьеллык башлангыч мәктәптә укыганда, тугыз яшьләрендә чакта ул шигырьләр яза башлый. Зур Битаман урта мәктәбендә 7 нче сыйныфта укыганда (1971 ел) «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында «Таң көтеп» дигән беренче шигыре басылып чыга. Шуннан соң «Яшь ленинчы»да, «Ялкын» журналында, Биектау районында чыга торган «Ильич юлы» газетасында бер-бер артлы шигырьләре, хәбәрләре, рәсемнәре басыла башлый. 1974 елда ул Зур Битаман урта мәктәбен тәмамлап, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. 1977 елда, университетның өченче курсын тәмамлагач, «Татарстан яшьләре» газетасында хезмәт юлын башлап җибәрә. 1978 елда Буага китеп, «Байрак» район газетасы редакциясенә эшкә урнаша. 1982–1989 елларда Татарстан радиокомитетында музыкаль тапшырулар редакторы, балалар өчен тапшырулар һәм әдәби тапшырулар редакцияләрендә эшли. 1989 елдан ул балалар өчен яңа чыга башлаячак «Салават күпере» журналын оештыручылардан берсе, аның җаваплы сәркатибе була. 1990 елдан «Идел» журналы сәркатибе, «Әдәби җомга» газетасын оештыручы мөхәррир, Татарстан Язучылар фонды (Литфонд) директоры, «ZAMAN» төрек-татар газетасы баш мөхәррире, «Шәһри Казан» газетасы корреспонденты, Казан дәүләт курчак театрының әдәби бүлек мөдире, «Мәгариф» нәшрияты мөхәррире булып эшли. Хәзерге вакытта Рафис Корбан — Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият һәм балалар әдәбияты редакцияләре мөдире.

Рафис Корбан, Казан дәүләт курчак театрының әдәби-драматик бүлек мөдире булып эшләгәндә, театр өчен пьесалар иҗат итә башлый. Алар бер-бер артлы Курчак театрының үзендә үк сәхнәләштерелә. 1994 елда — «Куркуын җиңгән Куян», 1995 елда — «Бардым күлгә, салдым кармак» һәм 1996 елда И.Зиннуров белән бергәлектә иҗат ителгән «Ак күлмәктә кара елан» спектакльләре уйнала.

1995 елда Татар яшьләр театры Р.Корбанның «Керпе малае дуслар эзли» әкиятен куя. 2001–2002 елларда аның «Патша кызы һәм җырчы» әкиятен Чаллы татар дәүләт драма театры, Уфаның «Нур» татар драма театры һәм Түбән Кама татар драма театры сәхнәләштерә.

Р.Корбан пьесалары урыс теленә тәрҗемә ителеп, алар Чаллы курчак театрында («Заяц, победивший страх») һәм Әстерхан дәүләт курчак театрында («Закинул я удочку») татар һәм урыс телләрендә параллель рәвештә уйналдылар. 2000 елда Татарстан китап нәшриятында Р.Корбанның сәхнә әсәрләре тупланган «Куркуын җиңгән куян» дигән китабы дөнья күрде һәм аның әкиятләре төрле мәктәп, балалар сәхнәләрендә куела башлады. Р.Корбан өлкәннәр өчен дә пьесалар иҗат итә.

Ул — унбишләп китап авторы.

2006 елда Р.Корбан татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерү буенча нәтиҗәле эшләгәне өчен «Татарстанның атказанган сәнгатькәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Ул — 1990 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

### Басылган драма әсәрләре:

**Корбан Р.** Куркуын җиңгән Куян: Пьесалар, шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. — 190 б.

### Аның турында:

**Солтан И.** Йөрәк тибеше // Казан утлары. — 2000. — № 9. — 160–162 б.
**Зарипова Р.** Балаларның күңел дөньясы // Казан утлары. — 2002. — № 12. — 156–159 б.
**Вәли-Барҗылы М.** Мәңгелек дип гүя пышылдый / Тормыш дулкынында. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.
**Зарипова Р.** Яраларга дәва бар // Мәдәни җомга. — 2005. — 4 ноябрь.
**Миңнуллин Р.** Дөрес яшисең, Рафис Корбан! // Казан утлары. — 2007. — № 1.
**Даутов Р.** Балачак әдипләре. Биобиблиографик белешмә. Беренче китап. — Казан: Мәгариф, 2002.

## ГАДЕЛ КУТУЙ (1903–1945)

Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев) 1903 елның 28 ноябрендә Саратов губернасындагы Кузнецк өязе Татар Кынадысы авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылы мәктәбендә ала. 1912 елда әтисе Нурмөхәммәт абзый, игенчелек эшен ташлап, гаиләсе белән Самара губернасындагы Алексеевск авылына күчә һәм Кутуевларның күн заводында эшли башлый. Гаделша шунда рус мәктәбендә укуын дәвам итә. 1917 елда бертуган Кутуевлар (дүрт гаилә) Самара шәһәренә күчеп килә. Булачак язучы өчен белем алу мөмкинлеге тагын да киңәя: ул атаклы рус язучысы А.Неверов җитәкчелегендәге түгәрәккә йөри башлый, табигый сәләте ачылып китә. Самара газеталарында 19 яшьлек Кутуйның беренче шигырьләре рус телендә басылып чыга.

Белем алуын дәвам иттерү һәм татар әдәби мохитенә якынрак булу максатыннан, Г.Кутуй Казанга килә, ата-анасы кушуы буенча ул политехник институтка керә. Әмма күңеле гуманитар фәннәргә тартыла, тиздән институтны ташлап, Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбенә әдәбият укытучысы булып урнаша. Шул чорда иҗат эшчәнлеге дә активлаша.

1925–1929 елларда Г.Кутуй Казан Көнчыгыш педагогика университетының рус теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Утызынчы еллар дәвамында Казан коммуналь төзелеш инженерлары институтында гыйльми сәркатип, мәктәпләрдә һәм Казан авиация техникумында әдәбият укытучысы булып эшли.

Г.Кутуй — ялкынлы публицист, зәвыклы тәнкыйтьче һәм тәрҗемәче дә. Ул газета-журнал битләрендә күпсанлы фельетоннары, очерк һәм мәкаләләре белән чыгышлар ясый, Татар академия театрының һәр яңа спектакленә диярлек рецензияләр язып бара, рус классикларының әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

Г.Кутуй, егерменче елларда театр өчен тәнкыйть мәкаләләре белән бергә, өч-дүрт ел эчендә берничә пьеса яза. Үз чорының төрле әхлакый проблемаларына багышланган «Балдызкай» (1926), «Директор Җәмилев» (1926), «Казан» (1927), «Күк күгәрчен» (1929), «Җавап» (1929) исемле пьесалары Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала. Бүгенгә Г.Кутуйның «Балдызкай» һәм «Күк күгәрчен» комедияләре генә сакланып калган. Кызганыч, иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләрне гәүдәләндергән «Казан», «Җавап», «Директор Җәмилев» пьесалары югалган.

Г.Кутуй татар поэзиясендә футурист шагыйрь буларак үзенчәлекле эз калдыра. 1927 елда аның «Кайнар көннәр» җыентыгы басыла. Ул проза өлкәсендә дә актив эшли. «Солтанның бер көне» (1935), «Вөҗдан газабы» (1939), «Илһам» (1941), «Рәссам» (1941) һ.б. хикәя, повестьларында чорының актуаль проблемаларын, яңа кеше формалашу, зыялыларның тормыштагы урыны мәсьәләләрен яктырта. 1935 елда Кутуй исемен бөтенсоюз һәм бөтендөнья әдәбиятына алып кергән әсәр — «Тапшырылмаган хатлар» повесте дөнья күрә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Г.Кутуй 1942 елның июнендә фронтка китә. Фронттагы батырлыклары өчен «Батырлык өчен», «Сталинград оборонасы өчен» медальләре һәм Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Сугыш шартларында, үзенең көрәш тәҗрибәсенә таянып, «Рәссам» (1941), «Яшен» (1941), «Хәнҗәр» (1945) хикәяләрен, «Без — сталинградчылар» (1944), «Сагыну», «Күпләрдән берәү» (1945), «Мәрфуга апа» (1945) һ.б. нәсер һәм очеркларын, «Рөстәм мәҗаралары» (1944) исемле повестен һәм күп кенә шигырьләрен иҗат итә.

Сәламәтлеге какшаган Г.Кутуй хәрби госпитальгә эләгә һәм, авыруыннан терелә алмыйча, 1945 елның 15 июнендә Польшадагы Згеш шәһәрендә вафат була.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Кутуй Г.** Әсәрләр: Шигырьләр һәм пьесалар. — 1 нче кисәк. — Казан: Яңалиф, 1929. — 107 б.

**Кутуй Г.** Балдызкай. Комедия 4 пәрдәдә. — Казан: Яңа китап, 1929. — 67 б.

**Кутуй Г.** Илһам. Сайланма әсәрләр / Төз. һәм кереш сүз авт. Р.Нуруллина. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. — 464 б.

**Кутуй Г.** Сайланма әсәрләр / Төз. һәм кереш сүз авт. Р.Нуруллина. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 415 б.

**Аның турында:**

**Усманова З.** Гадел Кутуйның «Җавап» пьесасы / Татар теле һәм әдәбияты. 2 нче китап. — Казан: Г.Ибраһимов ис. ТӘТИ., 1963. — 284–293 б.

**Нигъмәтуллин Ә.** Гадел Кутуй / Татар әдәбияты тарихы 6 томда. — 4 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 416–230 б.

**Нуруллина Р.** Ул ант итте җыры белән / Кутуй Г. Сайланма әсәрләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 6–18 б.

Якты шәхес: Гадел Кутуйның тууына 100 ел // Казан утлары. — 2003. — № 11. — 178 б.

**Усманова З.** Адель Кутуй: Жизнь и творчество. — Казань: Таткнигоиздат, 1966. — С. 96.

## ЛӘБИБ
## ЛЕРОН
## (1961)

Ләбиб Лерон (Лемон Лерон улы Леронов) 1961 елның 11 ноябрендә Татарстанның Мөслим районы Түреш авылында дөньяга килә. 1969 елда ул Олы Имән авылының башлангыч мәктәбендә укый. Сигезьеллык мәктәпне Югары Яхшый, ә урта мәктәпне Киров авылында тәмамлый.

1979 елда Л.Лерон Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Университетта укыган елларында «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы редакциясендә эшли башлый. 1984 елда университетның журналистика бүлеген тәмамлый.

1986–1988 елларда ул Татарстан Язучылар берлегендә СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры вазифасын башкара, шулай ук «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, Татарстан телевидениесенең балалар өчен тапшырулар редакциясендә мөхәррир булып та эшли. 1989 елдан башлап Ләбиб Лерон «Салават күпере» журналында әдәбият-сәнгать бүлеге мөхәррире вазифасын башкара.

Әдип төрле жанрларда иҗат итә. Аның «Яңгырның ял көне» (1988) шигырьләр җыентыгы; «Күрше тавыгы» (1990) эпиграммалар, пародияләр; «Тәгәрмәчле чана» (1993) әкиятләр, мәзәкләр; «Кояшны кочкан малай» (2004) шигырьләр, җырлар, әкиятләр, пьесалар һ.б. җыентыклары дөнья күрде.

Әдипнең «Чәпәләй белән Тәпәләй», «Аңгыра сарык җүләре» пьесалары Әлмәт татар дәүләт театры сәхнәсендә куелды. «Урмандагы тамаша», «Без барабыз бәйрәмгә» пьесалары Татарстан телевидениесеннән тапшырылды.

Ләбиб Лерон — Татарстан Язучылар берлегенең Шәйхи Маннур исемендәге (1994) һәм Абдулла Алиш исемендәге (2000) бүләкләре лауреаты. Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерү өлкәсендәге иҗади уңышлары өчен 2002 елда аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Ул — 1990 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Лерон Л.** Кояшны кочкан малай: Шигырьләр, җырлар, әкиятләр, пьесалар. — Казан: Мәгариф, 2004. — 303 б.

**Аның турында:**

**Даутов Р.** Балачак әдипләре. — Казан: Мәгариф, 2004. (Л.Лерон турында 163–168 б.)

## МӘДИНӘ

## МАЛИКОВА
## (1935)

Мәдинә Габделхак кызы Маликова 1935 елның 5 августында Татарстанның Сарман районы Мортыштамак авылында колхозчы гаиләсендә туа. Җидееллык мәктәпне үз авылында тәмамлаганнан соң, 1950–1959 елларда Татарстанның Минзәлә шәһәрендә педагогия училищесында, соңыннан Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетында укый. 1959–1964 елларда «Чаян» журналында корректор, 1964 елдан «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналында әдәби хезмәткәр, 1978–1987 елларда җаваплы сәркатибе булып эшли.

М.Маликова прозаик, публицист, драматург, җәмәгать эшлеклесе булып танылды.

Язучының «Казан каласы — таш кала», «Кояш күпере», «Янар таулар яктысында», «Алтын ятьмә», «Мендем биек тауларга», «Югалган якутлар» һ.б. повестьлары; «Шәфкать», «Басып сайрар талы бар», «Фидая», «Кызыл гөл» һ.б. романнары бар.

Әдибәнең драмаларында заман проблемалары, иҗтимагый мәсьәләләр геройлар язмышы аша күтәрелә. Аның «Йөрәк ничек түзсен», «Моңнар төште башыма», «Синең өчен үзем үләрмен» һ.б. пьесалары Минзәлә, Әлмәт һ.б. театр сәхнәләрендә зур уңыш казанды. 1990 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры аның «Оҗмах балалары» пьесасын сәхнәләштерде. Бу әсәр белән ул ятим балалар язмышы мәсьәләсен җәмәгатьчелек алдына күтәрә. М.Маликова дөрес тәрбия бирү, җаваплылык, әхлак һ.б. мәсьәләләр турында уйланырга мәҗбүр итә.

Матбугат һәм мәдәният өлкәсендәге хезмәтләре өчен М.Маликовага 1976 елда — Татарстанның, 1985 елда Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелде. Ул шулай ук 1980 елда Татарстан журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге республика бүләге лауреаты да.

Мәдинә Маликова — 1972 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Маликова М.** Алтын ятьмә: Повесть, хикәяләр, пьесалар. — Казан: Матбугат йорты, 2001. — 368 б.
**Маликова М.** Сөембикә: Яңа татар пьесасы 3 томда. — 1 т. — Казан: Идел-Пресс, 2004. — 114–175 б.

**Аның турында:**

**Хантимерова Г.** Төсләр балкышы: М.Маликованың иҗат портретына штрихлар // Казан утлары. — 1981. — № 8. — 133–138 б.
**Галимуллин Ф.** Халатың ак, күңелең пакь булса // Казан утлары. — 1983. — № 9. — 133–138 б.
**Даутов Р.** Балачак әдипләре. — Казан: Мәгариф, 2003. (М.Маликова турында 175–180 б.)
Татар драматургиясе (1980–2000): Сайланма пьесалар. «Мәктәп китапханәсе» сериясе. — 21 т. / Төз. һәм кереш мәкалә авт. А.Саттарова. — Казан: ТаРИХ, 2003. — 10 б.

## ИСЛАМИЯ
## МӘХМҮТОВА
## (1941)

Исламия Һидиятулла кызы Мәхмүтова (Мотыйгуллина) Әлки районы Югары Әлки авылында 1941 елның 1 декабрендә туа. Кече яшьтән үк артист булырга хыялланган Исламия, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казанга килә һәм Татар дәүләт күчмә театрына (хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) эшкә урнаша. Бер елдан соң сәхнәгә күтәрелә, төп рольләрдә уйный башлый.

1964 елдан башланган иҗат гомере тулысынча Тинчурин театры белән бәйле. Йөзгә якын рольләрнең иң характерлыларын гына санау да И.Мәхмүтованың күпкырлы талант икәнлеген күрсәтә: Фәйрүзә (Ю.Әминов. Умырзая чәчәкләре), Сәрия (Т.Миңнуллин. Нигез ташлары), Нурия (Т.Миңнуллин. Үзебез сайлаган язмыш), Ясминә (И.Юзеев. Кыр казлары артыннан), Хәтимә (И.Юзеев. Онытылмас бәет), Анна (А.Гыйләҗев. Сары чәчәк ата көнбагыш), Шәмсекамәр (М.Әблиев. Шәмсекамәр), Ана (Ш.Хөсәенов. Әни килде), Кураж ана (Брехт. Кураж ана һәм аның балалары).

Сәхнәдә алган тәҗрибә, беренче остазлары Кәшифә апа һәм Равил Тумашевларның онытылмас киңәшләре, дәресләре рухландыра — И.Мәхмүтова үзе дә режиссерлык эшенә алына. Д.Салиховның «Яшьлек хатам — йөрәк ярам», И.Юзеевның «Резидәкәй», Н.Гаетбаевның «Аты барның дәрте бар», Р.Сәгъдинең «Сынган беләзек» пьесаларын сәхнәгә куя, һәм алар зур уңыш белән баралар.

Җыр-музыкага, театр сәнгатенә гашыйк кешенең каләм көчен сынарга омтылышы табигый. Исламия Мәхмүтова да шигырьләр яза, кайберләренә көй язылып, җыр булып тарала: «Сынды беләзеккәем», «Тәүге яр», «Томаннар».

Пьесалар иҗат итүгә ул әнә шундый иҗат баскычлары үтеп килә. Халыкның яраткан актрисасы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы И.Мәхмүтова пьесалар язып сәхнәгә куя һәм шул спектакльләрдә үзе уйный да. Әсәрләр иҗат итәргә аны бүгенге тормышның үткен проблемалары, үзен борчыган һәм уйланып йөргән мәсьәләләр, тормыш һәм сәхнә тәҗрибәсе рухландыра. 1996 елда аның «Син бит минем бергенәм» пьесасы языла. 2004 елда ул «Мәхәббәт чишмәсе» пьесасын язып сәхнәгә куя. Спектакльләр театр репертуарында ныклы урын алалар, зур уңыш белән даими куелалар.

**Аның турында:**

**Гарәфетдинов А.** Исламия Мәхмүтова. — Казан: Татарстан газета-журналлар нәшр., 1993. — 16 б.
**Хәбибуллина Л.** Мәхәббәтнең сулмас гөлләре. — Казан: Матбугат йорты, — 2003. — 47 б.

## РӨСТӘМ МИНГАЛИМ (1937)

Рөстәм Мингалим (Рөстәм Гали улы Миңлегалимов) 1937 елның 15 августында Самара өлкәсенең Камышлы (хәзерге Келәүле) районындагы Йолдыз авылында игенче гаиләсендә дөньяга килә. Җидееллык мәктәпне Йолдыз һәм Дәүләткол авылларында тәмамлаганнан соң, Татарстанның Бөгелмә шәһәрендә авыл хуҗалыгы училищесында белем ала. 1955–1956 елларда ул Казакъстанның Күкчәтау өлкәсендә тракторчы һәм комбайнчы, 1956–1958 елларда Ташкент заводларында слесарь һәм станоклар көйләүче, соңыннан Бөгелмә шәһәрендә йөк ташучы булып эшли. 1962–1967 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Укуын тәмамлагач, сигез ел дәвамында «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр һәм җаваплы сәркатип вазифаларын башкара. 1975–1977 һәм 1989–1997 елларда Татарстан Язучылар берлеге аппаратында әдәби консультант булып эшли. 1977–1980 елларда Р.Мингалим Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларны һәм Дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС) каршындагы берьеллык театр курсларын тәмамлый.

1966 елда Р.Мингалимнең балаларга багышлап иҗат ителгән «Әйт, Кояшым!», 1967 елда өлкәннәр өчен язылган «Эзләр» исемле беренче шигырь җыентыклары басылып чыга. Алга таба әдипнең «Минем дәүләт» (1969), «Күз карасы» («Күк астында») (1979) һ.б. поэмалары языла.

Р.Мингалимнең шулай ук балалар өчен язган әсәрләре «Ә сәгать келт-келт итә» (1968), «Уйланырга кирәк» (1971), «Төнге әкият» (1973), «Бәхетле исем» (1977), «Галстуклы кәҗә» (1992), «Их, Самара яклары» (1998) һ.б. җыентыкларында чагылыш тапты.

Әдип драматургия өлкәсендә дә актив эшли. Заманның актуаль проблемаларына багышланган, идеянең сәнгатьчә бирелеше, психологизмы, кызыклы образлар системасы белән аерылып торган әсәрләрдән «Кунак кызы гел килмәс» (1984) лирик комедиясен, «Тау астында — бүре» (1979) сатирик комедиясен, «Кайда сез, ирләр?» (1975) моңсу комедиясен, «Кире уйларга соң инде» (1978) драмасын, «Өченче бүлмәдә эт яши» (1980) драмасын, «Әгәр булса борчуларың» (1986) драматик хикәясен, «Сабый туды» (1988) драмасын һ.б. санарга мөмкин. Р.Батулла белән берлектә иҗат ителгән «Сандугач сары түгел» (1989) драмасы да теманың актуальлеге белән укучыны җәлеп итә.

Курчак театры өчен язылган әсәрләрендә бала күңелен яхшы аңлау нәтиҗәсендә нәниләр өчен кызыклы образлар урын алды. Мәсәлән, «Урман улы Зурмөгез», «Сихерләнгән урман», «Шүрәлеләр үч алмый», «Сәер кешеләр, батыр малай һәм артист попугай» һ.б. пьеса-әкиятләре яшь укучының күңелен яулый.

Р.Мингалимнең «Кайда сез, ирләр?» комедиясе Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында, «Өченче бүлмәдә эт яши» драмасы Әлмәт театрында, «Сихерләнгән урман» әкият-пьесасы Мәскәүнең Үзәк курчак театры сәхнәләрендә уңыш казана.

Р.Мингалим киносценарийлар авторы буларак та билгеле. Ризван Хәмид белән берлектә әдип «Идегәй» исемле тарихи киносценариен иҗат итте. Яшь автор Эсфир Яһудин белән берлектә язылган «Ак метеор» киносценариесе матбугатта нәшер ителә.

Рөстәм Мингалимнең «Дүрт кешелек утыргыч» драмасы «Яңа татар пьесасы» бәйгесендә катнашып, жюри тарафыннан яхшы әсәр дип бәяләнде һәм «Яңа татар пьесасы» җыентыгында дөнья күрде.

Татар балалар әдәбиятын үстерү һәм баету юнәлешендәге эшчәнлеге өчен 1977 елда Р.Мингалим Татарстан Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге бүләгенә лаек була. 1987 елда аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Р.Мингалим «Дәрт чүлмәге» шигъри җыентыгы өчен 2005 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Ул — 1970 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Мингалим Р.** Тау астында илле бүре: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. — 312 б.
**Мингалим Р.** Шүрәлеләр үч алмый: Пьесалар, хикәяләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. — 128 б.
**Мингалим Р.** Дүрт кешелек утыргыч: Драма // Казан утлары. — 2002. — № 11. — 92–108 б.

**Аның турында:**

**Хәким С.** Әнвәр Давыдов эзе буйлап // Казан утлары. — 1971. — № 2. — 184–185 б.
**Миңнуллин Р.** Йолдыз җанлы малай турында әкият // Яшь ленинчы. — 1987. — 22 август.
**Хәлим А.** Кем анда?: Шагыйрь Рөстәм Мингалим иҗатына бер караш // Казан утлары. — 1998. — № 4. — 149–154 б.
**Даутов Р.** Балачак әдипләре. Беренче китап. — Казан: Мәгариф, 2002. (Р.Мингалим турында 110–114 б.)
«Сөю — минем өчен бик авыр чир: Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, А.Алиш исемендәге бүләк лауреаты, шагыйрь Р.Мингалим белән әңгәмә / Әңгәмәдәш Лерон Л. // Таһир-Зөһрә. — 2003. — 7 б.

## ГАБДРАХМАН МИНСКИЙ (1906–1983)

Габдрахман Мөхәммәт улы Минский 1906 елның 29 сентябрендә Әстерхан шәһәрендә эшче-һөнәрче гаиләсендә туа. Бер яше тулар-тулмас ул әтисез кала һәм үги әтисе Мөхәммәт Аллабирдиев гаиләсендә тәрбияләнә. Башлангыч белемне Әстерханның Тияк бистәсендәге җәдит мәдрәсәдә ала һәм Октябрь инкыйлабыннан соң татар совет мәктәбендә укый. (14 яшьлек Габдрахманның тәүге пьесасы — «Наданлык» әсәре — 1920 елда туган бистәсе клубында сәхнәләштерелә.)

1924 елда мәктәпне тәмамлагач, ике ел Әстерханның Нариман районында башта уку йортының, аннан соң «Кызыл Шәрык» исемле татар яшьләре клубының мөдире булып эшли. Шунда эшләгәндә үзешчән түгәрәкләрдә актив катнаша, балалар өчен беренче пьесаларын яза.

1926 елда Казанга килеп, Г.Минский театр техникумына укырга керә. Бу елларда ул «Кызыл яшьләр» газетасы һәм «Авыл яшьләре» журналы редакциясендә, утызынчы елларда Чиләбе трактор заводы төзелешендә чыккан «Төзү ударнигы» газетасында эшли. 1936–1938 елларда Мәскәүдәге Бөтенсоюз дәүләт кинематография институтының сценарий факультетын тәмамлый. Кырыгынчы елларда Бакуда яшәгән чоры да һәм Бөек Ватан сугышыннан соң да аның эшчәнлеге киностудия, радио һәм ТАСС (Советлар Союзы телеграф агентлыгы) белән бәйләнгән. 1952 елда Казанга кайткач, ул «Чаян» редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, 1957–1959 елларда Татарстан китап нәшриятында баш редактор урынбасары вазифасын башкара.

Г.Минский төрле жанрларда иҗат итә. Проза әсәрләре белән беррәттән ул күп кенә сәхнә әсәрләре дә яза. 1929 елда «Яңа яшьләр» исемле ике пәрдәлек комедиясе дөнья күрә. «Мансуровлар» исемле күләмле драмасы Татар дәүләт академия театрында сәхнәгә куела. Кызыл Армиядә хезмәт иткәндә, ул еллар өчен актуаль темага язылган «Шлем» дигән драма әсәре 1930 елда Татар академия теат-

рында сәхнәләштерелә һәм тамашачы тарафыннан җылы кабул ителә. Утызынчы еллар башында «ОДВА» һәм 1940 елда «Гөлчәчәк» исемле пьесалары куела.

Сугыштан соң Г.Минский клуб сәхнәләре өчен әхлак темасын яктырткан «Дуслык чишмәсе» (1956), «Бөдрә тал» (1957), «Җинаять» (1957), «Синең җырың» (1962), «Лачыннар» (1965), «Аналар» (1967) кебек драма һәм комедияләр яза. Аның «Бөдрә тал» әсәре Башкорт дәүләт театры сәхнәсендә, «Синең җырың», «Тапшырылмаган хатлар» (1960, Г.Кутуй повесте буенча) Татар дәүләт драма һәм комедия театры репертуарында урын ала.

Г.Минский — оста прозаик та. Ул — «Язның беренче көне» (1963), «Яшенле яңгыр» (1966) исемле повестьлар, «Миңсылу» (1928), «Юмористик хикәяләр», «Мәхәббәт хикәяләре», «Замандашларым» кебек җыентыклар авторы.

Г.Минский әдәби тәрҗемә эшенә дә лаеклы өлеш кертә. Азәрбайҗан язучылары Мәһди Хөсәеннең «Апшерон» романын, Җаббар Җаббарлының «Айдын» драмаларын татарчага тәрҗемә итә. «Айдын» Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелып, озак еллар зур уңыш белән бара.

Әдәбият өлкәсендәге уңышлары өчен Г.Минский «Почет Билгесе» (1976) ордены, «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» (1957) медале белән бүләкләнә.

Ул 1955 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Минский Г.** Яңа яшьләр: Комедия 2 пәрдәдә. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1928. — 20 б.
**Минский Г.** Хәерле кич: Комедия, эстрада. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1965. — 120 б.
**Минский Г.** Ике пьеса: Гөлчәчәк. Аналар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1967. — 120 б.
**Минский Г.** Синең җырың: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. — 178 б.

**Аның турында:**

**Сәләхетдинова А.** Заманасы шундый: Г.Минскийга — 70 яшь // Казан утлары. —1976. — № 9. — 187–188 б.
**Хәйри Х.** Язучы һәм журналист / Хәйри Х. Язучы һәм тормыш. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. — 262–266 б.
**Абдулла К.** Күңелдән чыкса, күңелгә барып җитә: Язучы Г.Минскийның тууына 90 ел // Ватаным Татарстан. — 1996. — 1 октябрь.
**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 303–305 б.

## ТУФАН МИҢНУЛЛИН (1935)

Туфан Габдулла улы Миңнуллин 1935 елның 25 августында Татарстанның Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында туа. 1952 елда урта мәктәпне тәмамлагач, Олы Кариле һәм Кама Тамагы авылларында хисапчы булып эшли. Казанда бухгалтерлар әзерләү курсларында укып чыккач, Казакъстанның Кустанай өлкәсендәге бер совхоз кооперациясендә баш бухгалтер булып эшли. 1956 елда Казан дәүләт университетына керә, ләкин озакламый Мәскәүгә Щепкин исемендәге театр училищесына укырга китә. 1961 елда аны тәмамлаганнан соң, башта Минзәлә дәүләт драма театрының, соңыннан Казанда 1964 елга кадәр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының артисты була. Шул ук елларда аның беренче әсәрләре дөнья күрә, әдип журналистика белән дә шөгыльләнә. 1964–1967 елларда Казан телестудиясендә өлкән мөхәррир булып эшли, «Чаян» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире вазифаларын башкара. 1968 елдан башлап Т.Миңнуллин профессиональ язучылык хезмәтенә күчә. 1975–1977 елларда драматург Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый.

Кабатланмас әсәрләр иҗат иткән, 1970 еллардан башлап бүгенге көнгә хәтле татар театр сәнгатенең үсешенә зур өлеш керткән, татар драматургиясен дөньякүләм таныткан шәхеснең эшчәнлеге тормышның иҗтимагый-сәяси яклары белән дә бәйле. Т.Миңнуллин — язучы, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе дә. Ул 1984–1989 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе булып эшли, 1985–1990 елларда — Татарстан Югары Советы, 1989–1991 елларда элеккеге СССР Югары Советы депутаты итеп сайлана. 1997 елдан Татар ПЕН-клубы рәисе вазифаларын башкара. 1995 елдан ул — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты.

Т.Миңнуллинның әсәрләре 1960 еллар башында дөнья күрә башлый. Бу чорда әдипнең юмористик хикәяләре, фельетоннары, бер пәрдәлек пьесалары, скетчлары языла. Аның «Бәхетле кияү», «Гарифулла карт», «Комиссия», «Айлы кичтә бакчада», «Мәхәббәт», «Шулай тиеш» һ.б. драма әсәрләре

«Бәхетле кияү» исеме астында басылып чыккан җыентыкта дөнья күрә. Тормышчан материалга нигезләнгән пьесалары тиз арада сәхнәләштерелә башлый. Аның «Безнең авыл кешеләре» комедиясе 1962 елда Минзәлә драма театрында, «Азат» әкият-пьесасы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, 1967–1969 елларда «Күрше кызы» пьесасы Әлмәт дәүләт драма театрында, 1968 елда «Миләүшәнең туган көне» драмасы, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелып, җәмәгатьчелек игътибарыннан читтә калмый. Шул ук елларда драматургның Республика күчмә театры (хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) репертуарында «Нигез ташлары» һәм «Йөрәк янар өчен бирелгән» пьесалары үз урынын ала. Тәнкыйть, бу әсәрләрне югары бәяләп, Т.Миңнуллинны талантлы, оста драматург итеп таный. Бу елларда әдипнең шулай ук «Чакыру билеты», «Аерылабыз — хуш инде», «Кем сызган?» һ.б. әсәрләре языла.

Т.Миңнуллин иҗатының яңа баскычка күтәрелүе, драматургия өлкәсендә остаруы, кабатланмас, сәнгать ягыннан югары дәрәҗәдә язылган әсәрләренең дөнья күрүе җитмешенче елларга туры килә. «Күрше кызы» (1967), «Миләүшәнең туган көне» (1968), «Диләфрүзгә дүрт кияү» (1968), «Ирегетләр» (1971), «Уйланыр чак» (1972), «Ат карагы» (1972), «Үзебез сайлаган язмыш» (1973), «Китәр юлың еракмы?» (1974), «Дуслар җыелган җирдә» (1975), «Әлдермештән Әлмәндәр» (1976), «Адәм баласына ял кирәк» (1977), «Монда тудык, монда үстек» (1982), «Әниләр һәм бәбиләр» (1984) һ.б. әсәрләрендә шәхес һәм җәмгыять, кешенең яшәү мәгънәсе, принциплары, дөньяга карашы, хатын-кызның вазифасы һ.б. тирән психологик анализ аша фәлсәфи яссылыкта бирелә.

Әдипнең иҗаты тематик төрлелеге белән дә аерылып тора. «Канкай углы Бәхтияр» (1974), «Без китәбез, сез каласыз» (1986), «Моңлы бер җыр» (1981), «Агыла да болыт агыла» (1999) пьесалары Б.Канкаев, Г.Тукай, М.Җәлил, Х.Туфан кебек тарихи шәхесләргә багышланган.

Т.Миңнуллин «Нигез ташлары» комедиясе һәм «Үзебез сайлаган язмыш» драматик хикәясе өчен 1974 елда Татарстанның М.Җәлил исемендәге Республика бүләгенә лаек була. «Ай булмаса, йолдыз бар» пьесасы буенча Әлмәт драма театрында куелган спектакль өчен драматургка 1979 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге тапшырыла. 1979 елда «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле өчен Т.Миңнуллинга, режиссер М.Сәлимҗановка, баш рольне башкаручы артист Ш.Биктимеровка Россиянең К.Станиславский исемендәге Дәүләт бүләге бирелә. Драматургның «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясе, 1976 елда сәхнәгә куелып, утыз ел дәвамында аншлаг тудырып, халыкның иң яраткан спектакльләренең берсенә әверелде.

Драматург 1990–2000 елларда «Хушыгыз!» (1990), «Илгизәр + Вера» (1991), «Баҗа мал түгел, кәҗә туган түгел» (1992), «Гөргөри кияүләре» (1995), «Айбикә» (1995–2001), «Сөяркә» (1996), «Йөрәк маем» (1996–1997), «Шәҗәрә» (1998), «Саташу» (2001), «Эзләдем, бәгърем, сине» (1999–2000), «Галиябану, сылуым-иркәм» (2001–2003), «Шулай булды шул» (2003), «Алты кызга бер кияү» (1985–2005) һ.б. пьесаларын иҗат итә. Бу пьесаларда кешенең дөньяга карашы, яшәү мәгънәсе, гаилә институтына, татар халкының гореф-гадәтләренә, татар теленә мөнәсәбәте, гомумән, адәмнең җәмгыятьтә яши белү осталыгы анализлана.

Әдип иҗатына жанр төрлелеге дә хас. Мәсәлән: моңсу комедия, сатирик комедия, комедия-детектив, этнографик музыкаль комедия, водевиль, комедия-дискуссия, лирик комедия, тарихи-героик драма, фәлсәфи-публицистик драма, тарихи-биографик драма, иҗтимагый-психологик драма, драматик хикәя, драматик повесть, драматик фрагмент һ.б.

Т.Миңнуллин балалар һәм яшүсмерләрнең күңел дөньясын аңлап, алар өчен сәхнә әсәрләре иҗат итүче драматург буларак та танылды. Аның балалар өчен язылган пьесаларында яшь укучыга һәм тамашачыга кызыклы образлар аша тәрбия мәсьәләләре күтәрелә, мәсәлән: «Азат», «Айга сәяхәт», «Иптәш командир», «Авыл эте Акбай», «Акбай нигә күңелсез?», «Акбай һәм Кыш бабай», «Акбай һәм Сарык малае», «Акбай SOS!», «О’кей, Акбай!», «Айбулат», «Җен алыштырган», «Кәрлә — мәктәп баласы», «Үзем белән үзем», «Гафият турында әкият», «Кайда хаклык, кайда дөреслек?», «Бик бүлтәймә, Бультерьер», «Internet Акбай» һ.б. Татарстанның төрле курчак һәм драма театрларында, Казанның Татар яшьләр театрында, Г.Камал исемендәге Татар академия театрында уңыш белән бара.

Гомумән алганда, драматургның пьесаларына куелган спектакльләр Казандагы К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры, Татарстанның Әлмәт, Минзәлә, Чаллы, шулай ук Башкортстан, Үзбәкстан, Удмуртия, Дагстан, Осетия, Ичкерия, Казакъстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Таллинн, Рига, Вильнюс милли театрлар сәхнәләрендә, Россиянең Әстерхан, Түбән Новгород, Воронеж, Мичурин, Мурманск, Новокузнецк шәһәрләрендәге рус театрларында һ.б. зур уңыш казанды. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә генә 1963–2006 елларда Т.Миңнуллинның 30 дан артык пьесасы сәхнәләштерелде. Әдипнең әсәрләре белән чит ил театр сөючеләре дә таныша алды.

Г.Камал театрының Германия, Финляндия, Төркиядәге гастрольләре вакытында драматургның «Әлдермештән Әлмәндәр» (Финляндия, 1996; Төркия, 1999), «Җанкисәккәем» (Германия, 1996; Финляндия, 2000), «Йөрәк маем» (Финляндия, 1997) спектакльләре тәкъдим ителеп, тәнкыйть һәм җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде. Т.Миңнуллин пьесалары инглиз, төрек һ.б. телләргә тәрҗемә ителде.

Язучының иҗаты классик иҗатка әверелде. Әдипнең драматургиясе хакында фәнни эшләр (А.Әхмәдуллин, Н.Ханзафаров, Ф.Ганиева, Г.Арсланов, М.Шәрипов, Г.Шакирова, А.Саттарова һ.б.), китаплар (Миңнуллин Т. Утырып уйлар уйладым, көндәлекләр), меңләгән рецензия һәм мәкаләләр (И.Илялова, Д.Гыйвмранова, Р.Игъламов, А.Габәши һ.б.) дөнья күрде.

Татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүдә лаеклы өлеш керткәне, дәүләт хакимияте органнарында күп еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен язучы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе урынбасары Туфан Габдулла улы Миңнуллин 2005 елда «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнде, 2006 елда аңа «Татарстанның халык язучысы» дигән мактаулы исем бирелде.

Т.Миңнуллин — 1969 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

### Басылган драма әсәрләре:

**Миңнуллин Т.** Азат: Әкият-пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1966. — 75 б.
**Миңнуллин Т.** Бәхетле кияү: Бер пәрдәлек пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1969. — 139 б.
**Миңнуллин Т.** Күрше кызы: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1970. — 132 б.
**Миңнуллин Т.** Йөрәк янар өчен бирелгән: Пьесалар җыентыгы. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1972. — 148 б.
**Миңнуллин Т.** Ир-егетләр: Пьесалар җыентыгы. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. — 250 б.
**Миңнуллин Т.** Иптәш командир: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. — 112 б.
**Миңнуллин Т.** Кырларым-тугайларым: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. — 366 б.
**Миңнуллин Т.** Монда тудык, монда үстек: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1985. — 462 б.
**Миңнуллин Т.** Без китәбез, сез каласыз: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 352 б.
**Миңнуллин Т.** Ай булмаса, йолдыз бар: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. — 408 б.
**Миңнуллин Т.** Авыл эте Акбай: Балалар театры өчен пьесалар. — Казан: Мәгариф, 1999. — 352 б.
**Миңнуллин Т.** Сайланма әсәрләр: 10 томда. — 1 т.: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 528 б.
**Миңнуллин Т.** Сайланма әсәрләр: 10 томда. — 2 т.: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 415 б.
**Миңнуллин Т.** Сайланма әсәрләр: 10 томда. — 3 т.: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 446 б.
**Миңнуллин Т.** Сайланма әсәрләр: 10 томда. — 4 т.: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 414 б.
**Миңнуллин Т.** Сайланма әсәрләр: 10 томда. — 5 т.: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 398 б.
**Миннуллин Т.** Белая ворона (Альмандар из Альдермыша): Комедия-притча в 2 д. / Пер. Ю.Мочалова. — М.: ВААП, 1976. — С. 58.
**Миннуллин Т.**Судьбы, избранные нами: Пьеса в 2 ч. / Пер. А.Жарова. — М.: ВААП, 1976. — С. 70.

### Аның турында:

**Әхмәдуллин А.** Драматург уйлана, эзләнә // Казан утлары. — 1969. — № 2. — 152–159 б.
**Арсланов Г.** Драматург белән театр дуслыгы [Татар дәүләт академия театры] // Татарстан яшьләре. — 1976. — 19 октябрь.
**Гаффар Ә.** Әлдермеш — дөнья уртасында [«Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә] // Социалистик Татарстан. — 1976. — 14 ноябрь.
**Гыйләҗев А.** Замандашыбыз Әлмәндәр // Социалистик Татарстан. — 1978. — 18 апрель.
**Харисов М.** «Моңлы бер җыр» — Мәскәү сәхнәсендә // Социалистик Татарстан. — 1981. — 21 апрель.
**Ахунов Г.** Ил гаме белән [«Монда тудык, монда үстек» пьесасы Г.Камал ис. Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә] // Социалистик Татарстан. — 1982. — 20 июнь.
**Шәймиев М.** Аны халык ярата // Казан утлары. — 1995. — № 8. — 130 б.
**Нуруллин И.** Кеше һәм драматург // Мирас. — 1995. — № 10. — 53–55 б.
**Шакирова Г.** Драматургия Туфана Миннуллина 1980–1990-х гг.: Автореф. дис... канд. филол. наук. — Казань, 1999. — С. 19.
**Әхмәдуллин А.** Туфан Миңнуллин // Татар әдәбияты тарихы. — 4 т. — Казан: Раннур, 2001. — 405–429 б.
**Саттарова А., Миңнуллина А.** Т.Миңнуллинның «Шәҗәрә» драмасында чор һәм герой мәсьәләсе // Гыйльми язмалар. — Казан: Татар дәүләт гуманитар институты, 2001. — № 9. — 68–69 б.
**Ханзафаров Н.** Драмаларда күңел дөньябыз: Т.Миңнуллинның хәзерге драматургиясенә бер караш // Мәдәни җомга. — 2002. — 15 март.

**Даутов Р.** Балачак әдипләре: Биобиблиографик белешмәлек. Беренче китап. — Казан: Мәгариф, 2002. — 223 б. (Т.Миңнуллин турында 125–133 б.)

**Саттарова А.** Современная татарская драматургия 1985–2000 гг. Концепция эпохи и героя [Анализ пьес «Бажа мал түгел, кәҗә туган түгел», «Шәҗәрә», «Сөяркә», «Саташу» Т.Миннуллина и др. авторов]. — Казань: Gumanitarya, 2003. — С. 150.

**Шамсутова А.** Язмыш шаярганны яратмый: Язучы Т.Миңнуллин иҗаты турында // Мәдәни җомга. — 2005. — 19 август.

**Галиев М.** Туфан булып кара син: Язучы Т.Миңнуллинга — 70 яшь // Мәдәни җомга. — 2005. — 19 август.

## ГАЗИЗ
## МОНАСЫЙПОВ
## (1888—?)

Габделгазиз Габдрахман Монасыйпов 1888 елның 3 декабрендә Татарстанның Арча районы Яңа Тазлар (Байкал) авылында мәзин гаиләсендә дөньяга килә. 1902–1908 елларда Кытай Төркестанында уйгурлар арасында яши, балалар укыта. Аннан соң берара Ташкентта яшәгән булса кирәк дип фаразлана. 1911 елда Казанга кайта. Биредә аның нәрсә белән шөгыльләнүе, даими эш урыны әлегә билгесез. Әдәби иҗатына килгәндә, 1911–1912 елларда «Шура» журналында һәм «Бәянелхак» газетасында унлап шигыре басыла.

1912–1914 елларда Г.Монасыйпов проза һәм драма төрләренә дә мөрәҗәгать итә. 1913 елда ике драмасы дөнья күрә. Чахотка белән авыручы Хәсән язмышын сурәтләгән «Имчеләр корбаны» (1913) исемле бер пәрдәлек пьесасы, әле басылып чыкканчы ук, 1912 елда Казанда «Сәйяр» труппасы тарафыннан, 1918–1919 елларда М.Фәйзи оештырган яшьләр түгәрәге көче белән Җүкәйдә һәм Юлыкта куела. Г.Монасыйповның икенче сәхнә әсәре — «Ышанычсыз юлга бер адым» (1913) исемле дүрт пәрдәлек драмасы — Әстерхан һәм Омск сәхнәләрендә уйнала.

1913 елда Казанның «Өмид» матбагасында «Өзелгән өмид» исемле озын хикәясе басыла. Тормышчан эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше белән уңышлы саналган әсәре — «Таранчы кызы, яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» романы — 1915 елда тәмамланып, 1918 елда дөнья күрә.

1914 елда башланган империалистик сугыш вакытында Г.Монасыйпов гаскәри хезмәткә алына, гаскәри мулла вазифасын үти. 1917 елгы Февраль революциясеннән соң сәяси вакыйгаларда актив катнаша. И.Алкин җитәкчелегендәге Бөтенроссия мөселманнар Хәрби Шурасының сәркатибе итеп сайлана. 1918 елны Хәрби Шураның матбугат органы булган «Безнең тавыш» газетасы идарәсендә эшли, күп сандагы мәкаләләр белән актив чыгыш ясый.

Милли мәнфәгатьләрне яклаучы Хәрби Шура совет хакимияте тарафыннан куып таратылгач, Г.Монасыйпов электә мөгаллимлек иткән якларына — Урта Азиягә китә, матбугатта исеме югала. Аннан соңгы язмышына кагылышлы төгәл мәгълүматлар әлегә юк. Туганнарының хәбәре буенча, аның гомер юлы фаҗигa белән тәмамлана.

Язучы, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Г.Монасыйповның әдәби мирасы таркау хәлдә кала бирә, аның иҗаты җентекле тикшерүне көтә.

**Аның турында:**

**Рәми З.** Тагын бер фаҗигале язмыш // Мирас. — 1996. — № 1–2. — 137–141 б.

**Рәми И., Даутов Р.** Әдәби сүзлек: Элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 178–179 б.

## ГАМИР
## НАСРЫЙ
## (1916–1959)

Гамир Насрый (Гамир Гариф улы Насретдинов) 1916 елның 3 гыйнварында Башкортстанның Кызыл Кама районы Иске Янҗегет авылында туа. Авыл мәктәбендә башлангыч белем ала, 1928–1931 елларда Казанда туганнары тәрбиясендә яши, җидееллык мәктәпне тәмамлый. Ике ел туган авылында эшләп алгач, 1934–1937 елларда Казан театр техникумында укый. 1937–1940 елларда ул

армия сафларында хезмәт итә, Бөек Ватан сугышында катнаша, хәрби корреспондент буларак фронт газеталары битләрендә йөзләрчә хәбәрләр, очерклар, шигырьләр бастыра.

Сугыштан кайткач, Татарстан радиокомитетында драматик һәм музыкаль тапшырулар редакторы булып эшли. 1949 елдан профессиональ язучылык хезмәтенә күчә, гомеренең соңгы көннәренә кадәр әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә.

Гамир Насрый 1932 елда, 16 яшьлек үсмер малай чагында ук, «Ялкау Бикмөхәммәт» исемендә дүрт пәрдәлек беренче пьесасын яза, һәм ул матбугатта басылып та чыга. Утызынчы елларда зур булмаган сәхнә әсәрләре яза; үз чоры геройларын тасвирлаган, проблемаларын чагылдырган «Культура фронтында», «Пушнина өчен көрәш», «Болын ударниклары», «Колхоз сәүдәсе», «Бәйрәм көннәрендә», «Чәчү алдыннан» инсценировкалары, «Бухгалтер Ашмасов», «Патриотлар семьясы», «Таныш кешеләр» дигән бер пәрдәлек пьесалары күмәк җыентыкларда басылып чыга. Шул ук вакытта аның «Делегат» (1936), «Путевка» (1938), «Ил чигендә» (1939) исемле күләмле пьесалары да иҗат ителә.

Сугыштан соңгы чорда Гамир Насрый үзен тормыш тәҗрибәсен туплаган, драматургия һәм сәхнә закончалыкларын махсус өйрәнгән үзенчәлекле драматург итеп таныта. Бу елларда ул комедия жанрында да уңышлы эшли, аның пьесалары татар театрларының репертуарын баетып тора: Минзәлә татар дәүләт театрында — «Туган авылым», «Кадерле минутлар», Республика күчмә театрында (хәзерге К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) — «Күңел дәфтәре», «Яшел эшләпә», Татар дәүләт опера һәм балет театрында «Идел буенда» («Алтын көз») пьесалары зур уңыш белән бара.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында аның «Кушнарат» комедиясе (1952), «Кадерле минутлар» драмасы (1953) куела.

Әдипнең җыр жанрындагы эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Күренекле композиторлар Заһид Хәбибуллин («Сайра син, тургай»), Җәүдәт Фәйзи («Хак булса әгәр»), Салих Сәйдәшев («Мәхәббәт җыры»), Рөстәм Яхин («Күңелемдә яз») белән бергә иҗат иткән җырлары әле дә татар классикасының җәүһәрләре булып санала һәм башкарыла. 1950 елларда Татар дәүләт опера һәм балет театрында барган «Идел буенда» («Алтын көз») музыкаль драмасы очраклы күренеш түгел иде.

Гамир Насрый — дүрт дистәгә якын сәхнә әсәрләре, күпсанлы сатирик шигырьләр, поэмалар иҗат иткән, татар драматургиясе һәм театры тарихында үзенчәлекле урын алган әдип.

Г.Насрый 1940 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Насрый Г.** Ялкау Бикмөхәммәт: Пьеса 4 пәрдәдә. — Казан: Татиздат, 1932. — 43 б.

**Насрый Г.** Колхоз театры: Кечкенә форма колхоз театрлары өчен. — Казан: Татгосиздат, 1934. — 54 б.

**Насрый Г.** Делегат: Пьеса 4 пәрдәдә, 6 күренештә. — Казан: Татгосиздат, 1936. — 72 б.

**Насрый Г.** Комедияләр. — Казан: Татгосиздат, 1950. — 120 б.

**Насрый Г.** Пьесалар. — Казан: Таткнигоиздат, 1953. — 230 б.

**Насрый Г.** Кадерле минутлар: Пьеса 4 пәрдәдә, 8 картинада. — Казан: Таткнигоиздат, 1955. — 123 б.

**Насрый Г.** Туган авылым: Драма 4 пәрдәдә, 7 картинада. — Казан: Таткнигоиздат, 1956. — 111 б.

**Насрый Г.** Яшел эшләпә: Комедияләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1958. — 106 б.

**Насри Г.** Дорогие минуты: Пьесы. — М.: Искусство, 1957. — С. 123.

**Насри Г.** Зеленая шляпа: Комедия — водевиль. — М.: ВУОАП, 1959.

**Аның турында:**

**Гыйззәт Б.** Танылган драматург // Социалистик Татарстан. — 1966. — 4 гыйнвар.

Күренекле драматург Гамир Насрыйның тууына 60 ел // Казан утлары. — 1976. — № 1. — 138–139 б.

**Гыйззәт Т.** Гамир Насрый иҗаты турында // Гыйззәт Т. Әсәрләр: 4 томда. — 4 т. — Казан: — Тат. кит. нәшр., 1978. — 305–315 б.

## КАВИ НӘҖМИ (1901–1957)

Кави Нәҗми (Габделкави Һибәтулла улы Нәҗметдинов) 1901 елның 15 декабрендә Сембер губернасының Курмыш өязе Петрякс волосте Красный Остров авылында (хәзерге Горький өлкәсе

Петрякс районы) крестьян гаиләсендә туа. 1906 елда әтисе Һибәтулла абзый гаиләсе белән Казанга килеп урнаша. Соңрак Кырымның Бакчасарай шәһәрендә мәдрәсәдә каравылчы булып, Әстерхан, Семипалат, Павлодар шәһәрләрендә төрле эшләргә йөргәч, 1910 елда Актүбә шәһәрендә төпләнә. 1912 елда унбер яшьлек Кави Актүбәдәге алты еллык рус-татар мәктәбендә укый башлый.

1917 ел башында, бер-бер артлы әтисе һәм әнисе үлеп киткәч, Кави ике энесе һәм сеңлесе белән туганнары янына Красный Островка кайта. 1918 елда Казанга килә. 1919 елда Сембердәге (хәзерге — Ульяновск) педагогия курсларында укый, үз авылларына кайтып, берничә ай башлангыч мәктәптә укыта. Шул ук елны Кызыл Армиягә языла һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнаша.

Гражданнар сугышы тәмамлангач, Киев шәһәрендә хәрби хуҗалык курсларында, соңыннан Мәскәүдәге Югары хәрби-педагогия институтында укый. 1922 елда, укуын тәмамлап, Казанга кайта һәм Татар-башкорт хәрби мәктәбендә укытучы, 1927 елдан башлап шул мәктәпнең комиссары булып эшли. Бер үк вакытта ул 1926–1933 елларда «Кызылармеец» газетасының җаваплы редактор вазифасын да башкара.

Егерменче елларда К.Нәҗми әдәби иҗат эшендә дә активлык күрсәтә. Шул заман өчен актуаль мәсьәләләрне яктырткан хикәяләр («Чыныгу», «Иң соңгысы», «Шобага», «Миңлебикә кодагыйның кайгысы» һ.б.) һәм повестьлар («Яр буенда учаклар», «Якты сукмак», «Кояшлы яңгыр») яза.

1933 елда Кави Нәҗми Татарстан Совет язучылары берлеген оештыру комитетында эшли башлый һәм бер үк вакытта «Совет әдәбияты» журналының редакторы да итеп билгеләнә. 1934 елда Мәскәүдә уздырылган Бөтенсоюз Совет язучыларының I съездында ул татар матур әдәбияты турында доклад ясый. Бу съездда К.Нәҗми СССР Язучылар берлеге идарәсенең әгъзасы һәм шул ук елда Татарстан Совет язучылары берлеге идарәсенең рәисе итеп билгеләнә.

Җаваплы эшләр белән бергә К.Нәҗми иҗади хезмәтен дә туктатмый. Каләмен драматургиядә дә сынап карый: 1933 елда ул К.Тинчурин белән берлектә «Булат бабай семьясы» исемле пьеса яза. Әсәр К.Тинчурин режиссерлыгында шул ук елда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала. Икенче драма әсәре — «Алма бакчасында» пьесасы — 1940 елда дөнья күрә.

Сталинның шәхес культы җилләре К.Нәҗмине дә аяп узмый. Ул нахакка «халык дошманы» дип игълан ителә һәм 1937 елның 2 июлендә төрмәгә озатыла (хатыны язучы С.Әдһәмова исә 1938 елның 4 гыйнварында кулга алына). К.Нәҗми 1939 елның декабрендә аклана һәм ireккә чыгарыла.

Бөек Ватан сугышы елларында К.Нәҗми Татарстан радиокомитетында эшли. Совет кешеләренең батырлыгын чагылдырган күп сандагы поэмаларын («Хәят апа», «Сагыну хаты», «Фәридә» һ.б.), шигырьләрен һәм публицистик мәкаләләрен яза.

1949 елда К.Нәҗминең зур тарихи вакыйгаларны үз эченә алган «Язгы җилләр» романы басыла һәм зур популярлык казана. 1951 елда бу әсәр СССР Дәүләт премиясенә лаек була, күп телләргә тәрҗемә ителә.

К.Нәҗми — балалар өчен язылган ике дистәгә якын шигъри китап авторы да («Күңелле көннәр», «Сабан туе», «Ун бәбкә», «Казанга кайту» һ.б.).

Иҗтимагый эшчәнлеге һәм татар әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен хөкүмәт тарафыннан ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «Хезмәттәге батырлыгы өчен» һәм «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында батыр хезмәте өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Ул 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Нәҗми К.** Әсәрләр: 4 томда. — 4 т.: Пьесалар. Публицистика. Хатлар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 364 б.

**Аның турында:**

**Гыйззәтуллин Н.** Кави Нәҗми: Тәнкыйди-биографик очерк. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1956. — 88 б.

**Гыйззәтуллин Н.** Кави Нәҗми // Татар совет әдәбияты тарихы: Очерклар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 673–704 б.

**Гыйззәтуллин Н.** Кави Нәҗми // Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. — 4 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 324–344 б.

**Фәттахов Р.** Кави Нәҗми. Чор һәм шәхес // Татарстан. — 2001. — № 10. — 38–47 б.

Кави Нәҗминең тууына 100 ел: Истәлекләр // Казан утлары. — 2001. — № 12. — 142–152 б.

## ӘХМӘТ РАХМАНКОЛЫЙ (1886–?)

Әхмәт Таҗетдин улы Рахманколый 1886 елның май аенда Чиләбе өлкәсенең Троицк шәһәрендә дөньяга килә. Әхмәт сигез яшенә кадәр әтисе Мөхәммәтҗанның «Рахманколый» мәдрәсәсендә белем ала. Аннары аны Бохарадагы «Заргаран» мәдрәсәсенә җибәрәләр. 1906 елда Троицкига кайтып, бер ел чамасы рус телен өйрәнә. 1907–1911 елларда Истанбулда белем ала. Россиягә кайтып, уңышлы гына сәүдә эше белән шөгыльләнә башлый. Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан Ә.Рахманколый кабат Төркиягә юл ала. Анда «Хөр милләт» исемле газета чыгара, «Чыңгыз» (1914) дигән беренче пьесасын яза. Аны сәхнәләштерү өчен Троицкидан Дәүләтша Мутин исемле режиссер чакыртыла. Драма Истанбулда уйнала.

Февраль революциясеннән соң Ә.Рахманколый, туган шәһәре Троицкига кайтып, газета чыгару эшен дәвам итеп карый, әмма «Хөр милләт»нең гомере озын булмый. Октябрь революциясеннән соң илдә башланган чуалышлар нәтиҗәсендә Ә.Рахманколый төрле шәһәрләрдә, төрле җирләрдә эшләргә мәҗбүр була, сәүдә эшен дәвам итәргә дә омтылып карый. Эшсез йөргән чаклары да шактый була.

1925 елда Ә.Рахманколый Казанга килә, һәм шул ук елны аның «Упкын» драмасы Татар академия театры сәхнәсенә күтәрелә. Бу драманы һәм Рахманколыйның соңрак куелган сәхнә әсәрләренең күпчелеген театрның баш режиссеры Гомәр Девишев сәхнәләштерә. Соңгы әсәре «Шомлы шәүләләр»не 1928 елда актер һәм режиссер Хәким Сәлимҗанов куя. Гомумән, Ә.Рахманколый өч сезонда 7 пьеса куйдырырга өлгерә, алар искиткеч зур уңыш белән бара («Упкын» (1925), «Боз астында дулкын» (1926), «Җиһан тетрәгәндә» (1926), «Тигәнәк» (1927), «Килмешәк» (1927), «Сафура» (1928), «Шомлы шәүләләр» (1928).

Ә.Рахманколый үз заманында күп серияле сәхнә әсәрләре авторы буларак та таныла. Җидешәр сериядән торган сериаллары да булганы мәгълүм.

Аның пьесалары рус сәхнәләрендә дә шаулап бара. Бу хакта «Кызыл Татарстан», «Красная Татария» газеталарында мәгълүматлар басыла.

Ә.Рахманколый шулай ук шәп киносценарист буларак та билгеле. Аның киносценарийлары буенча нәфис фильмнар куела.

Татар зыялылары, сәхнә һәм әдәбият әһелләре арасында ул танылган һәм үз кеше санала. Казанда яшәү чорында (1925–1932) С.Садыйкова, Ф.Ильская, Г.Болгарская, З.Солтанов, Х.Уразиков, К.Нәҗми һ.б. белән аралаша.

Сәмәркандка килеп урнашкач та Әхмәт Рахманколый кабат иҗат эшенә чума. 1931 елда «Кара күләгәләр» исемле сәхнә әсәре яза. «Последний удар» дигән киносценарий язу өстендә дә эшли.

Татар театры үсешенә зур өлеш керткән Әхмәт Таҗетдин улы Рахманколыйны да шәхес культы җилләре урап узмый. Ул 1938 елда Сәмәрканд шәһәрендә «контрмилләтчеләр шпион оешмасы җитәкчесе» буларак кулга алына. Озакка сузылган сорау алулардан соң, «халык дошманы» дип, сәламәтлеге шактый какшаган Ә.Рахманколый билгесез якка җәяүле эшкә җибәрелә. Аның үлгән елы да, күмелгән кабере дә әлегә билгесез.

1992 елда Ә.Рахманколыйның «Боз астында дулкын» драмасы режиссер Фәрит Бикчәнтәев тарафыннан кабат Татар дәүләт академия театры сәхнәсенә менде. Әдипнең тормыш һәм иҗат юлын барлауда драматург Юныс Сафиуллин зур эзләнүләр алып барды.

**Аның турында:**

**Сафиуллин Ю.** Атылган йолдыз // Идел. — 2000. — № 9. — 70–78 б.

## ШАМИЛ РӘКЫЙПОВ (1929—2005)

Шамил Җиһанша улы Рәкыйпов 1929 елның 22 сентябрендә Татарстанның Чүпрәле районы Яңа Чокалы авылында туа. Үсмер чагы сугыш елларына туры килә, яшьли ятим кала (әтисе 1941 елда фронтта һәлак була). Авыл мәктәбенең җиденче сыйныфын тәмамлагач, берөзлексез колхозда эшли. 1950 елда, колхозда амбарчы булып эшләгәндә, ачлыктан интегүче авылдашларына ярдәм рәвешендә колхоз амбарыннан ашлык бүлеп биргәне өчен, аны җавапка тарталар һәм Себер якларына ун еллык мәҗбүри хезмәт колониясенә җибәрәләр. Ул Красноярск шәһәре тирәсендәге хәрби төзелешләрдә ташчы, җир казучы, балта остасы, сварщик, бетонщик һ.б. булып эшли. Фәкать 1954 елда, Сталин культы фаш ителгәннән соң гына, бу бәладән котыла.

1955 елда Ш.Рәкыйпов Казанга килә һәм ике ел трамвай паркында электрик-моторист булып эшли. Аннары «Татарстан яшьләре» газетасында әдәби хезмәткәр, тәрҗемәче, соңрак газетаның бүлек мөдире вазифасын башкара. 1966–1993 елларда Татарстан китап нәшриятының балалар һәм яшьләр әдәбияты редакциясе мөдире, 1993 тән 2000 елга кадәр «Шәһри Казан» газетасында журналист булып эшли. 1999 елдан башлап гомеренең соңгы көннәренә кадәр фәкать иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

Ш.Рәкыйпов беренче очерклары, хикәяләре, нәсерләре һәм кече формадагы сәхнә әсәрләре белән матбугатта илленче еллар уртасында күренә башлый. Иҗатының башлангыч чорында ул аеруча сәнгать коллективлары өчен пьесалар язуга зур игътибар бирә. Драматургның дистәдән артык бер пәрдәлек комедияләре, драма һәм скетчларының («Чуен багана», «Зөһрә», «Сөю билгесе», «Арзан матурлык», «Ике туй», «Ике килен-килендәш», «Күршең кем синең?», «Бал вакыйгасы» һ.б.) күбесе «Күңелле сәхнә», «Үсү юлы» кебек җыентыкларда һәм авторның «Сөю билгесе», «Тынгысыз яшьлек», «Күршең кем синең?» исемле китапларында басыла. Әлеге пьесалар үз вакытында авыл, шәһәр клублары сәхнәләрендә еш куела. Берничәсе, рус теленә тәрҗемә ителеп, Мәскәү нәшриятларында да дөнья күрә.

Ш.Рәкыйпов прозаик буларак Бөек Ватан сугышы темасын яктырткан әсәрләре белән меңьеллык әдәбиятның алтын хәзинәсенә матур өлеш кертә («Чәчәкләр сөйли белә», «Таңнар һаман матурмы?», «Кызлар-йолдызлар», «Кипарислар җыры» һ.б.).

Татар әдәбиятын үстерүдәге зур хезмәтләре өчен Ш.Рәкыйповка 1980 елда «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

Ул 1966 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Рәкыйпов Ш.** Сөю билгесе: Бер пәрдәлек комедияләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. — 71 б.

**Рәкыйпов Ш.** Тынгысыз яшьлек: Бер пәрдәлек комедияләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1963. — 72 б.

**Рәкыйпов Ш.** Күршең кем синең?: Бер пәрдәлек комедияләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1966. — 102 б.

**Ракипов Ш.** Горят сердца: Пьеса в 1 д. — Москва: Отд. распростр. драм. произв. ВУОАП, 1960. — С. 24.

**Ракипов Ш.** Знак любви: Комедия в 1 д. / Пер. с тат. и сценич. ред. И.Луковского. — М.: Искусство, 1962. — С. 21.

**Ракипов Ш.** Спасите тетю: Комедия в 1 д. / Пер. с тат. и сценич. ред. И.Луковского. — М.: Искусство, 1962. — С. 22.

**Аның турында:**

**Вәли М.** Кешелекнең дәвамы — батырлык!: Ш.Рәкыйповка — 70 яшь // Казан утлары. — 1999. — № 9. — 188–190 б.

**Гыйззәтуллин Р.** Эзтабарлар патшасы // Шәһри Казан. — 1999. — 17 сентябрь.

**Дунай Ф.** Эзтабар каләм иясе: Язучы Ш.Рәкыйповка — 70 яшь // Ватаным Татарстан. — 1999. — 17 сентябрь.

**Маннапов Ш**. «Рәмел тактасы», яки Каләм тылсымы белән // Мәдәни җомга. — 2004. — 24 сентябрь.

**Мостафин Р.** Галиҗәнап эзтабар язучы: Язучы Ш.Рәкыйповка — 75 яшь // Шәһри Казан. — 2004. — 10 сентябрь.

**Юнысова А.** Миллионер: Эзтабар язучы Ш.Рәкыйповның тормыш һәм иҗат юлына бер караш // Ватаным Татарстан. — 2004. — 22 июнь.

Шамил Рәкыйповка — 75 яшь // Казан утлары. — 2004. — № 9. — 188 б.

Татарстан Язучылар берлеге. Татарстан китап нәшрияты. Шамил Рәкыйпов // Мәдәни җомга. — 2005. — 25 февраль.

## ИСМӘГЫЙЛЬ РӘМИЕВ (1895–1969)

Исмәгыйль Габдулла улы Рәмиев 1895 елның 1 гыйнварында Уфа губернасының Эстәрлетамак шәһәрендә урта кул сәүдәгәр гаиләсендә туа. Үз чорының җәдиди мәктәбендә урта белем алганнан соң, Казандагы «Амур» кунакханәсендә хисапчы булып эшли. 1912–1914 елларда «Сәйяр» драма труппасында суфлер була һәм труппа артистлары белән төрле шәһәрләрдә гастрольләрдә йөри. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, ике ел патша армиясендә писарь вазифасын башкара.

1917 елдан И.Рәмиевнең журналистлык эшчәнлеге башлана. Кызыл Армиядә хезмәт иткәндә «Кызыл яу», «Кызыл йолдыз», «Кызыл дөнья» исемле фронт газеталарында эшли. Бу газеталарда үзенең күп кенә публицистик мәкаләләрен һәм очеркларын бастыра. 1923–1925 елларда ул Уфа шәһәренең матбугат органнарында («Кызыл юл», «Урал», «Шәрык ярлылары»), 1925 елдан Казанда Татарстан китап нәшриятында, «Чаян», «Яңалиф» редакцияләрендә эшли. 1937—1942 елларда, нахакка гаепләнеп, репрессия корбаны була. 1942 елдан И.Рәмиев — Уралда, Түбән Тагил шәһәрендә хезмәт армиясендә, аннан Свердловскида хәрби курслар штабында писарь булып хезмәт итә. 1945 елда демобилизацияләнә һәм, Татарстанга кайтып, 1957 елга кадәр Кайбыч район газетасында сәркатип һәм шул ук районның мәдәният йортында инструктор булып эшли.

И.Рәмиев — күп кенә әдәби, тарихи-публицистик әсәрләр һәм биобиблиографик хезмәтләр авторы. Алар арасында 1926 елда Казанда басылган «Вакытлы татар матбугаты. 1905–1925» исемле кыйммәтле китап-альбомны санарга кирәк.

И.Рәмиев пьесалар да иҗат итә. Аның «Милләт Мәҗлесе» әсәре 1925 елда «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәләштерелә. Шулай ук «Тәфтиләү», «Кайда, кемнәр бу?» исемле пьесалары языла.

Әдип гомеренең соңгы елларында Октябрьгә кадәрге татар әдәбияты һәм мәдәнияте хакында кыскача сүзлек-белешмәлек төзү өстендә эшли. Әлеге кыйммәтле хезмәт, Р.Даутов тарафыннан тулыландырылып, «Әдәби сүзлек» исеме астында 2001 елда дөнья күрде.

**Аның турында:**

**Мәһдиев М.** Рәмиевләр нәселеннән берәү // Казан утлары. — 1989. — № 12. — 176–177 б.

**ДаутовР.** Исмәгыйль Рәмиев // Татарстан хәбәрләре. — 1995. — 22 март.

**Галиев Ш.** Язмышында гасыр таныла: И.Рәмиевнең тууына 100 ел // Шәһри Казан. — 1995. — 5 гыйнвар.

## СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВ (1880–1926)

Сәгыйть Лотфулла улы Рәмиев 1880 елның 12 (24) февралендә Оренбург губернасының Оренбург өязе Акман (Ибрай) авылында дөньяга килә. Әтисе Лотфулла яхшы гына белемле кешеләрдән санала, агач белән сату итә, урман эшкәртүче байларга ялланып сал да агыза. Шуңа да булачак шагыйрьнең балалык еллары төрле җирләрдә уза.

С.Рәмиев Урал суы буендагы Иләк шәһәрендә башлангыч мәктәптә, ә 1890–1902 елларда Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый. Гарәп-фарсы телләрен яхшылап өйрәнә, өч класслы рус мәктәбендә дә белем ала. 1902 елда мәдрәсәне мактау кәгазе белән тәмамлагач, шул уку йортында фарсы теле һәм математика укытучысы итеп билгеләнә. Беренче шигырьләрен дә мәдрәсәдә чагында яза башлый.

1905 елгы революция тәэсирендә көрәшкә, яңалыкка омтылган егет, мәдрәсәне ташлап, 1906 ел башында Казанга килә. Татар эсерлар партиясе лидеры Г.Исхакый белән якыная һәм «Таң йолдызы» (ул ябылгач, «Таң мәҗмугасы» журналы), «Тавыш» газетасында эшли, редакторлык вазифасын да

башкара. Рәмиевнең әдәби-публицистик эшчәнлеге әлеге матбугат органында башлана. Газетада яңалыкка, көрәшкә һәм бердәмлеккә чакырган шигырьләре һәм мәкаләләре басыла.

Революция елларында Г.Камал, Г.Коләхмәтов, Ф.Әмирхан һ.б. белән бергә С.Рәмиев тә татар театрын тудыру һәм юлга салу эшендә актив эшли. 1906 елның 22 декабрендә татар профессиональ театр тарихында беренче спектакльне ачып җибәргән речьне сөйләүче дә ул була. Шул көннәрнең тәэсире белән аның «Театр» шигыре языла.

С.Рәмиев театр репертуарын баету нисбәтеннән чорының актуаль проблемаларын гәүдәләндергән «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» (1907) һәм «Низамлы мәдрәсә» (1908) исемле пьесаларын иҗат итә. Мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган бу әсәрләрдә милләтне якты, мәдәни тормышка чыгару юллары эзләнә. Драматург үзенең идеалларын халыкка хезмәт итүгә, шәхес азатлыгы өчен көрәшкә багышлаган көчле рухлы, мәгърифәтле егет һәм кызларда чагылдыра («Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!»).

Пьесаның дөнья күрүе дин башлыклары арасында зур шау-шу куптара. Һәр әсәрнең тиражы кадимчеләрнең көчле басымы астында наширлар тарафыннан җыеп алына һәм утта яндырыла. Драма «Сәйяр» труппасы тарафыннан 1914 елда гына тамашачыга барып җитә.

Яшәештәге искелек кануннарын, мәдрәсәләрдәге кадими укыту системасын бердәмлек һәм яңалыкка омтылыш булганда гына җиңеп чыгу мөмкинлеген С.Рәмиев үзе укыган һәм мөгаллимлек иткән «Хөсәения» мәдрәсәсе тормышыннан алып язган «Низамлы мәдрәсә» драмасында ачып бирә. «Низамлы мәдрәсә» 1908 елның 22 февралендә басыла, алдынгы җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алына. Әсәр рус матбугатының да игътибарын җәлеп итә һәм шул ук елда «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куела.

1907 елның көзендә Тукай белән дуслашу, Ф.Әмирхан җитәкчелегендәге «Әльислах» газетасына якынаю Рәмиевнең поэтик иҗаты тагы да үсеп китүгә уңай йогынты ясый. Ислахчылар белән бергә әдәбият кичәләрен оештыруда актив катнашып, шагыйрь «Себектәгин» дигән исем астында чыгышлар ясый.

Татар җәмәгатьчелегенә Рәмиевне яңарыш, революцион күтәрелеш елларында татар халкы тормышында, аңында башланган каршылыклы көрәшне чагылдырган «Таң вакыты» (1908) шигыре таныта. Аның «Мин», «Син», «Ул», «Алданган», «Көлсеннәр», «Сызла, күңелем», «Дөньяга», «Минем төн» һ.б. романтик шигырьләрендә Көнчыгыш әдәбияты традицияләре белән бергә рус-Европа сүз сәнгатеннән килүче эстетик, фәлсәфи фикерләр урын ала.

Гомумән, С.Рәмиевнең күпкырлы бай иҗат мирасы татар әдәбияты, мәдәниятенең әһәмиятле бер өлешен тәшкил итә.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Рәмиев С.** Сайланма әсәрләр: Шигырьләр, хикәяләр, пьесалар / М.Гайнуллин кереш сүзе белән. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1962. — 163 б.

**Рәмиев С.** Таң вакыты: Шигырьләр, хикәяләр, сәхнә әсәрләре, публицистика / Ш.Садретдинов кереш сүзе белән. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — 270 б.

**Аның турында:**

**Садретдинов Ш.** Сәгыйть Рәмиев иҗаты. — Казан: Казан университеты нәшр., 1973. — 162 б.

**Садретдинов Ш.** Сәгыйть Рәмиев // Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. — 3 т. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 172–194 б.

**Рәмиев И.** Сәгыйть Рәмиев // Рәмиев И. Истәлекләр. Татарча басма сүз. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1965. — 43–50 б.

**Гайнуллин М.** Сәгыйть Рәмиев (1880–1926) // Гайнуллин М. Татар әдипләре: Иҗат портретлары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. — 143–155 б.

«Уйласам уй, сызлый күңлем, сызлый җан»: С.Рәмиевнең тормыш юлы һәм иҗатына карата яңа мәгълүматлар / Төз. Зарипова-Четин Ч. — Казан: Яңалиф, 2005. — 203 б.

## ГАЛИ
## РӘХИМ
## (1892–1943)

Гали Рәхим (Мөхәммәтгали Мөхәммәтшакир улы Габдерәхимов) 1892 елның 4 ноябрендә Казан шәһәрендә мул тормышлы сәүдәгәр гаиләсендә туа. Әтисе, чыгышы белән Лаеш өязе Олы Мәтәскә авылы крестьяны Мөхәммәтшакир, Казанга килеп, уңышлы сәүдә эшенә керешә һәм сәүдә фирмаларының берсенә хуҗа була. Әнисе Бибигайшә исә Казанның икенче гильдияле сәүдәгәр Исхак Айтуганов кызы.

Мөхәммәтгали башта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, аннан махсус укытучылар яллап, рус, гарәп, фарсы һәм төрек телләрен, дөнья әдәбиятын өйрәнә. Аннары әтисенең теләге белән 1905 елдан Казандагы коммерция училищесын тәмамлый, 1913 елда Мәскәү сәүдә институтының икътисад бүлегендә укый башлый.

Уку елларында ук әдәбият һәм фән белән кызыксына. 1909 елда «Җир йөзе» исемле фәнни-популяр жанрдагы беренче китабы басыла. «Ак юл», «Аң» журналларында актив язышa, аларда дистәләрчә әкият-хикәяләре басыла. Аларның күбесе 1919–1921 елларда аерым җыентык булып дөнья күрә.

Г.Рәхим драматургия өлкәсендә дә каләм тибрәтә. Балалар өчен йорт спектакльләре оештыра, һәм анда үзе язган пьесалары да куела. Кайвакыт балалар өчен Көнбатыш классиклары җәүһәрләрен дә тәрҗемә итә. Сеңлесе Рауза Габдерәхимова сөйләве буенча, шундый спектакльләрнең берсе — Гетеның «Урман патшасы» дигән әсәре — Г.Рәхим тәрҗемәсендә сәхнәләштерелә.

Октябрь революциясенә кадәр татар театрында Гали Рәхимнең «Дача кайгысы» исемле ике пәрдәлек комедиясе уйнала. Яшь драматург, бай тормышлы гаиләдә ир белән хатын арасындагы каршылыкларны көлкеле ситуациядә тасвирлап, җиңел телле, төзек сюжетлы пьеса тудыра. Комедия 1914 елда «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан «Шәрекъ клубы» сәхнәсендә куела һәм матбугатта уңай бәя ала.

Икенче драма әсәре — «Җанвар» исемле ике пәрдәлек пьесасын да 1918 елда «Сәйяр» труппасы сәхнәгә куя, һәм әсәр бер елдан аерым китап булып басыла. Автор реаль тормыштан аерылган, матурлыкка табынучы төп герое аша шәхес иреге проблемасын чишәргә омтыла.

Г.Рәхим шагыйрь һәм тәрҗемәче буларак та танылa. Ул лирик шигырьләр, сонетлар яза, Көнчыгыш һәм Көнбатыш поэзиясе үрнәкләрен тәрҗемә итә.

Г.Рәхим әдәби тәнкыйть һәм әдәбият теориясе өлкәсендә дә җитди эш башкара. Ул — әдәбиятка, тел белеменә, тарих, фольклористика, археология, педагогика мәсьәләләренә караган күп гыйльми хезмәтләр авторы. Г.Рәхим калдырган мирас арасында иң кыйммәтлесе — тарихчы-галим Г.Гобәйдуллин белән берлектә язылган «Татар әдәбияты тарихы» хезмәте.

Әдипнең 1922 елда романтик рухлы «Идел» повесте басылып чыга һәм көчле тәнкыйтькә очрый. Г.Рәхим рухы белән пролетариат идеологиясенә ят дип белдерелә (ә бу вакытта, ягъни 1922–1930 елларда, ул Көнчыгыш педагогия институтында укыта, доцент), шулай ук солтангалиевчелектә, милләтчелектә гаепләнеп, 1931 елның 6 маенда кулга алына. 5 елга ирегеннән мәхрүм ителеп, Ак диңгез-Балтыйк каналы төзелешенә хезмәт колониясенә җибәрелә. 1934 елның 22 август карары белән, яхшы эшләгәне өчен, срогыннан алда азат ителә. Элекке эшенә урнаша алмагач, 1936–1938 елларда Казан Дәүләт банкында хезмәт итә.

1938 елда яңадан кулга алына, мөстәкыйль төрки-татар дәүләте төзүдә яшерен көрәш алып барганы өчен гаепләнә. 1940 елның 27 февралендә суд Г.Рәхимне 8 елга концлагерьга җибәрергә хөкем чыгара. Ләкин сәламәтлеге нык какшаган әдип ирекка җибәрелә. 1943 елның 3 мартында сеңлесе Рауза Габдерәхимова фатирында дөнья куя.

Г.Рәхимнең исеме 1958 елның 2 февралендә реабилитацияләнә.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Рәхим Г.** Дача кайгысы: Комедия 2 пәрдәдә. — Казан: Хәсәни, 1914. — 14 б.
**Рәхим Г.** Җанвар: Ике пәрдәлек пьеса. — Казан: Алга, 1919. — 52 б.

**Аның турында:**

**Мәһдиев М.** Ерактан яңгыраган аваз // Мәһдиев М. Әдәбият һәм чынбарлык. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. — 118–144 б.
**Мәһдиев М.** Каһәрләнгән язмыш: Г.Рәхимнең тууына 100 ел // Татарстан хәбәрләре. — 1992. — 24 октябрь.
**Даутов Р.** Догасыз еллар корбаны // Мирас. — 2002. — № 11. — 53–56 б.
**Азизова Г.** Гали Рәхим: Тормышы һәм иҗаты // Фәнни Татарстан. — 2003. — № 2. — 52–59 б.

**Заһидуллина Д.** Кереш сүз // Рәхим Г. Сайланма әсәрләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 7–36 б.
**Азизова Г.** Вопросы истории татарской литературы в трудах Г.Рахима: Ди.... канд. филол. наук. — Казань, 2001. — С. 206.

## ГӘРӘЙ
## РӘХИМ
## (1941)

Гәрәй Рәхим (Родионов Григорий Васильевич) 1941 елның 15 июлендә Татарстанның Шөгер (хәзерге Лениногорск) районы Аланлык (Федотовка) авылында дөньяга килә. 1948–1959 елларда ул урта мәктәптә белем ала. Бу чорда әдип әдәбият белән кызыксына башлый. 1961 елда аның район газетасында «Язгы җыр» исемле беренче шигыре басылып чыга. 1962–1967 елларда Г.Рәхим Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Кулына диплом алган яшь әдип 1967 елда «Татарстан яшьләре» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. 1968–1972 елларда ул Татарстан китап нәшриятының балалар һәм яшьләр әдәбияты бүлегендә редактор; 1972–1977 елларда Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант, 1978–1979 елларда «Казан утлары» журналы редакциясендә проза бүлеге мөдире кебек вазифаларны башкара.

1979–1981 елларда әдип М.Горький исемендәге Мәскәү әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларда белемен арттыра. 1980–1987 елларда Г.Рәхим РСФСР Язучылар берлеге идарәсендә Татарстан, Башкортстан, Чуашстанның әдәби консультанты, Урал һәм Идел буе төрки әдәбиятлар комиссиясенең җаваплы сәркатибе һәм РСФСР милли әдәбиятлар эше буенча баш консультант була.

1987–1992 елларда Г.Рәхим Татарстан Язучылар берлеге идарәсендә рәис урынбасары, соңыннан «Шәһри Казан» газетасы редакциясендә бүлек мөдире, 1992 елдан ул Татарстан Дәүләт Советының мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясендә референт һәм баш референт булып эшли.

Г.Рәхимнең иҗат лабораториясенә килгәндә, ул поэзия, проза, драматургия жанрларында язучы әдип буларак танылды. Аның «Моңнарым» (1978), «Тимер торна» (1993), «Замандашларыма ачык хат» (1999) һ.б. шигырь җыентыклары, «Көннәр язга авышкач» (1974), «Туган йортта» (1983), «Татлы сагышларым» (1991), «Иске самавыр торбасы» (2000) һ.б. повестьлар, хикәяләр җыентыклары нәшер ителде. Мәктәп сәхнәләре өчен язылган пьесалары һәм скетчлары «Шатлык елы» (1972) китабында дөнья күрде.

Авторның пьесалары Минзәлә, Туймазы һ.б. татар театрларында сәхнәләштерелде. Әдип өч серияле «Исә Болгар җилләре» исемле киносценарий авторы буларак та танылды. М.Гафуриның «Кара йөзләр» повесте буенча иҗат ителгән опера өчен либреттосы Г.Рәхимгә зур уңыш китерде. «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсы иҗат иткән бер төркем сәнгать әһелләре белән бергә Г.Рәхимгә 1984 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге тапшырылды. 1985 елда ул «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Г.Рәхим — 1968 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

### Басылган драма әсәрләре:

**Рәхим Г.** Шатлык елы: Мәктәп сәхнәләре өчен пьесалар, скетчлар, парчалар, хикәяләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1972. — 104 б.

### Аның турында:

**Галиев М.** Чын исеме — Гөргөри // Казан утлары. — 2001. — № 7. — 75–88 б.
**Даутов Р.** Балачак әдипләре. Беренче китап. — Казан: Мәгариф, 2003. (Г.Рәхим турында 147–153 б.)

## ГАБДЕЛХӘЙ
## САБИТОВ
## (1931–1995)

Габделхәй Вәли улы Сабитов 1931 елның 28 июнендә Татарстанның Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, укытучы булып эшли. Минзәлә район газетасы редакциясендә эшләп алгач, М.Горький исемендәге Мәскәү әдәбият институтының драматургия бүлегендә укый.

1960–1965 елларда Г.Сабитов Казан телевидение студиясендә әдәби-драматик тапшырулар буенча өлкән редактор, аннан «Ялкын» журналында бүлек мөдире булып эшли, «Чаян» журналының җаваплы сәркатибе вазифасын башкара. 1970 елдан ул әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә.

Иҗатының башлангыч чорындагы шигырьләре, үзешчән сәнгать коллективлары өчен язган «Мәхәббәт һәм нәфрәт» комедиясе беренче иҗат тәҗрибәләре була. 1960 елларда республика көндәлек матбугатында аның өлкәннәр һәм балалар өчен дә «Туган җир туфрагы», «Агач аяклы кеше», «Өч күңел», «Корбан ашы», «Сәйлүн чәе», «Урман кызы», «Туй бүләге» кебек бердәй кызыклы, самими хикәяләре, әкиятләре басыла. «Кичерелмәс гөнаһ» драмасы белән профессиональ театр сәхнәсенә күтәрелә. Ул 1959 елда Минзәлә дәүләт театрында куела.

Җитмешенче еллар дәвамында Г.Сабитовның чын сәнгать кануннарына туры килгән, зәвык белән иҗат ителгән хикәяләре языла. Аларның иң матурлары мәктәп дәреслекләрендә, хикәяләр альманахында урын ала, ул татар әдәбиятында күренекле хикәя остасы буларак таныла. Шул ук вакытта әдип Курчак театры өчен «Гөлстан балалары» исемле әкият-драма (1973), «Үлемсез Акылгали» (1979) дигән пьеса, 1912 елгы Лена елгасы буендагы фаҗигагә багышланган «Гарасат» («Чулпан таңны уята») тарихи драмасын иҗат итә. Соңгысы СССРның 50 еллык юбилее уңае белән Татарстан Культура министрлыгы оештырган әдәбият-сәнгать әсәрләре конкурсында (1973) бүләккә лаек була һәм Минзәлә дәүләт театрында куела, зур уңыш казана.

Г.Сабитов балалар өчен дөнья классикасыннан күп кенә әсәрләр дә тәрҗемә итә.

Ул 1976 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Сабитов Г.** Чулпан таңны уята (Гарасат): Ике бүлекле драма. — Казан: Тат. кит, нәшр., 1979. — 86 б.

**Сабитов Г.** Ай сукмагы: Әкият-драма // Ялкын. — 1980. — № 9 —10. — 6–11 б.

**Сабитов Г.** Тармаклы яшен: Хикәяләр һәм пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. — 240 б.

**Сабитов Г.** Кичерелмәс гөнаһ: Драма // Мәйдан. — 2003. — № 6. — 127–156 б.

**Сабитов Г.** Чулпан таңны уята: Ике бүлекле драма // Мәйдан. — 2003. — № 6. — 92–126 б.

**Аның турында:**

**Әминов Ю.** Бүгенге драматургиябез турында кайбер фикерләр: Г.Сабитовның «Гарасат» драмасы турында // Казан утлары. — 1975. — № 10. — 152–159 б.

**Мәхмүтов Һ.** Гарасат // Социалистик Татарстан. — 1978. — 10 август.

**Гыйззәтуллин Р.** Аны укып үстек // Шәһри Казан. — 1991. — 2 июль.

**Вәлиев М.** Безнең Габделхәй абый // Шәһри Казан. — 1991. — 20 июнь.

**Шабаев М.** Ихлас җанлы авылдашым: Язучы Г.Сабитовның тууына 70 ел // Казан утлары. — 2001. — № 6. — 85–86 б.

**Ихсанова В.** Ул бит табигать баласы иде // Юлдаш. — 2001. — № 16.

**Гаффаров Ә.** Ай баткач: Язучы Г.Сабитовның тууына 70 ел // Шәһри Казан. — 2001. — 15 июнь.

## ФОАТ
## САДРИЕВ
## (1941)

Фоат Миңлеәхмәт улы Садриев 1941 елның 10 мартында Татарстанның Мөслим районы Олы Чакмак авылында дөньяга килә. Җидееллык мәктәпне үз авылында, урта мәктәпне күрше Шуган авылында тәмамлый. 1958–1960 елларда төрле эшләрдә эшли. 1965 елда ул Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлый. 1981–1982 елларда Мәскәүдә РСФСР Мәдәният министрлыгы каршындагы берьеллык Югары театр курсларында укый.

Ф.Садриев — оста прозаик. Аның «Шаһзаманов эше», «Зөбәйдәнең күңел дәфтәреннән», «Өченче кеше», «Рәхмәт, әтием!..», «Кыргый алма әчесе» кебек әсәрләре җитди проблематикалары, тирән психологизмы белән аерылып торалар. Әдипнең «Таң җиле», «Бәхетсезләр бәхете» кебек романнары дөнья күрә. «Таң җиле» романы өчен Ф.Садриев Әлмәт Язучылар берлегенең Рафаил Төхфәтуллин исемендәге әдәби бүләгенә лаек була.

Фоат Садриев драматург буларак та танылა. Аның «Оҗмах ишеге төбендә», «Их сез, егетләр!..», «Ач тәрәзәң», «Кондырлы кодачасы», «Тозлы бал», «Иртәгә нидер булачак», «Син сандугач, мин каен», «Безнең авыл кызлары», «Яшьли сөйгән ярлар», «Хөршидә, Мөршидә, Рәшидә», «Безнең гомер язлары», «Аяз көнне яшен» һ.б. пьесалары, Әлмәт татар дәүләт драма театры сәхнәсендә куелып, тамашачылар күңелен яулап алалар. Буыннар арасындагы мөнәсәбәт, рухи кыйммәтләр, көнкүреш проблемалар драматург тарафыннан оста яктыртыла.

1991 елда театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткәне өчен Ф.Садриевка «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә.

Ф.Садриев — 1981 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Садриев Ф.** Ач тәрәзәң: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 144 б.

**Садриев Ф.** Тозлы бал: Драмалар, комедияләр, скетчлар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 351 б.

**Аның турында:**

**Галимуллин Ф.** Гыйбрәтләр алсак иде... // Казан утлары. — 1993. — № 1. — 140–148 б.

Мәйдан. — 2004. — № 2. — 11–192 б. (Бу сан Ф.Садриевның иҗатына багышланган.)

**Даутов Р., Гамбәров Н.** Балачак әдипләре. Өченче китап. — Казан: Мәгариф, 2005. (Ф.Садриев турында 248–256 б.)

## Г.-ХАЛИКЪ
## САДРИ
## (1890–1955)

Г.-Халикъ Садри (Габделхаликъ Гариф улы Садриев) 1890 елның 4 августында хәзерге Самара өлкәсенең Камышлы районы Иске Ярмәк авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Кечкенәдән ятим калып, Октябрь революциясенә кадәрге чорда Оренбург, Уфа, Баку, Самара шәһәрләрендә завод һәм нефть промыселларында эшләп, «тормыш университетлары»н уза. Бик яшьли революцион көрәш юлына баса. 1919–1922 елларда партиянең Самара губерна комитетында татар-башкорт секциясе рәисе булып эшли. 1920 елда Мәскәүдә ТАССР оешу турындагы тарихи закон проектына кул куйган татар халкы вәкилләреннән берсе икәнлеге дә мәгълүм.

Х.Садри Казанда «Спартак» комбинатында директор һәм башка сәнәгать оешмаларында җитәкче булып эшли, актив җәмәгать эше алып бара. Бу чорда ул уйлап табу һәм хезмәтне рациональләштерү юнәлешендә фәнни-популяр хезмәтләр дә яза («Электромонтер», 1926; «Электрик серләре», 1928 һ.б.).

Бөек Ватан сугышында, батальон командиры буларак, фронтның алгы сызыгында сугыша. Фронттагы батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм медальләре белән бүләкләнә.

Х.Садри, әдәби иҗатка Октябрь революциясенә кадәр үк тартылып, шул чорда байтак кына хикәяләр яза. Революциядән соң ул прозада эшләү белән бергә үзен драматургиядә, поэзиядә һәм очеркларда сынап карый. Х.Садриның драматург Әнәс Камал белән берлектә «Юллар» (1950) исемле пьесасы бар. Шулай ук ул «Идел буенда сугышлар», «Партизаннар» һәм курчак театрлары өчен «Камал бабай әкияте» (1951) исемле сәхнә әсәрләре иҗат итә. Әлеге пьесалар үз вакытында республикабыз сәхнәләрендә зур уңыш белән бара.

Х.Садриның «Ил батырлары» (1934), «Тимерче малае» (1935), «Безнең таң» (1937) исемле повестьлары һәм «Йөзмә госпитальдә» (1950) дигән мемуар очеркы мәгълүм.

Аның барлыгы сигез китабы дөнья күрә.

Ул 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәре:**

**Садри Г.-Халикъ.** Ил батырлары: Сайланма әсәрләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1954. — 278 б.

**Аның турында:**

Халикъ Садриның тууына 90 ел // Казан утлары. —1980. — № 8. — 186 б.
**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 404–406 б.
Халикъ Садриның тууына 100 ел // Казан утлары. — 2000. — № 8. — 188 б.

## ДАНИЛ САЛИХОВ (1958)

Драматург һәм актер Данил Хәбибрахман улы Салихов 1958 елның 7 октябрендә Татарстанның Актаныш районы Киров исемендәге поселокта эшче гаиләсендә дөньяга килә. 1976 елда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан музыка училищесының вокал бүлегенә укырга керә. Белемен арттыру максаты белән 1979–1983 елларда Казан театр училищесының актерлар бүлегендә укый. 1983–1985 елларда Д.Салихов Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, ә 1985–1993 елларда К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында актер булып эшли. Әдип, сәхнәдә кабатланмас образлар тудырып, тиз арада танылa. Ул башкарган рольләр арасында Мәхмүт (М.Әмир. Миңлекамал), Наил (Х.Вахит. Туй алдыннан), Басарый (Т.Гыйззәт. Ташкыннар), Тимур (Р.Мингалимов. Кайда сез, ирләр?), Пруденсью (Л. де Вега. Белисаның хикмәтләре), аучы (К.Гоцци. Болан-патша) һ.б.

Театр тормышы Д.Салиховка зур йогынты ясый. 1980 елларда ул үз драма әсәрләрен иҗат итә башлый. «Яшьлек хатам — йөрәк ярам», «Чукрак» кебек пьесалары Д.Салиховны чын драматург итеп танытталар. Аның пьесалары, Татарстан һәм Россия театрларында куелып, тиз арада тәнкыйть һәм галимнәр тарафыннан игътибар үзәгенә алына. Алар арасында: Республика күчмә театрында (К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) — «Туй күлмәгем — соңгы бүләгем» (1987), «Яшьлек хатам — йөрәк ярам» (1989), «Бәйрәмгалинең сыер тошавы» (1991); Әлмәт татар драма театрында — «Хатын түгел — аждаһа» (1992), «Әти кызына өйләнәм» (1995), «Чукрак» (1998), «Алла каргаган йорт» (1996), «Көтмәгәндә-уйламаганда» (2001), «Узып барышлый» (2003); Минзәлә татар дәүләт театрында — «Өзелгән йөзем» (2005) һ.б.; Чаллы татар дәүләт яшьләр театрында — «Мөгезле Мәүлихан» (1994); Уфа «Нур» татар дәүләт театрында — «Пуля» (2003) һ.б. Шулай ук Сибай башкорт дәүләт театры, Туймазы татар дәүләт драма театры, Оренбург дәүләт драма театры сәхнәләрендә аның спектакльләре уңыш белән бара.

Драматургның иҗаты киң кырлы. Аның төрле жанрларда язылган «Ак күгәрчен», «Гыйләҗ тәрәзәләре», «Өзелгән йөзем», «Язмыш», «Узып барышлый», «Көттереп килгән яңгыр», «Кызлар капкыны», «Мөгез», «Бәхетеңне кәҗә сөзсә» һ.б. пьесалары тематик төрлелек, күтәрелгән җитди проблематика, психологизм, кулланылган сәнгать алымнары белән башкалардан аерылып тора. Драматургка зур уңыш алып килгән «Чукрак» пьесасы — татар халкының тарихын сәнгатьчә сурәтләгән уңышлы әсәрләрнең берсе. Татар авылы көнкүреше мисалында — 1917 елгы инкыйлаб, дингә каршы көрәш, мәчет манарасының киселүе, гражданнар сугышы, Сталин репрессияләре һәм 1990 елларда авылда яңа мәчет манарасының барлыкка килүе — татар халкының язмышы тасвирлана.

Д.Салихов җәмәгать эшлеклесе буларак та танылa. 1998 елда аңа Татарстан язучылары Әдәбият фондының мөдире вазифасы йөкләнелә. 2003 елда язучы Татарстанның милек агентлыгының мөдире итеп билгеләнә. Шулай ук Д.Салихов — Халыкара әдәби фонд әгъзасы, Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы, Татарстан Театр әһелләре берлеге әгъзасы.

2000 елда Д.Салиховка «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Ул — 1992 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Салихов Д.** Яшьлек хатам — йөрәк ярам: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. — 328 б.
**Салихов Д.** Узып барышлый: Пьесалар. — Казан: Мәгариф, 2002.
**Салихов Д.** Гыйләҗ тәрәзәләре: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 285 б.

**Аның турында:**

**Гыйләҗев А.** Ябык капкаң ачылыр чагы // Мәдәни җомга. — 1998. — № 34. — 21 август.
**Илялова И.** Мысли по поводу... // Идель. — 1998. — № 8. — С. 36–37.
**Саттарова А.** Человек в сложных обстоятельствах эпохи в драме Д.Салихова «Чукрак» («Глухой») // Проблемы истории, культуры и развития языков народов Татарстана и Волго-Уральского региона. Материалы VI региональной научно-практической конференции. — Казань: Gumanitarya, 2003. — С. 224–227.
**Саттарова А.** Современная татарская драматургия 1985–2000 гг. Концепция эпохи и героя. — Казань: Gumanitarya, 2003. — С. 150 .
**Җәлилова Э.** Данил Салихов серләрен ача: Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург белән әңгәмә // Ирек мәйданы. — 2005. — № 3. — 15 апрель.
**Гыйммранова Д.** Язмышыңа язылган булгач // Мәдәни җомга. — 2005. — № 39. — 30 сентябрь.
**Шәрәфетдинова Ф.** Әлмәт театры имтихан тотты // Ватаным Татарстан. — 2006. — 21 апрель. — № 76–77.
**Галиуллина А.** Өзелгән йөзем [Татар театрына 100 ел] // Ватаным Татарстан. — 2006. — № 79. — 25 апрель.
**Шәрәфетдинова Ф.** Башта — Уфа, аннан — Мәскәү // Ватаным Татарстан. — 2006. — № 80. — 26 апрель.

## ШӘРИФ САТТАРОВ (1887–1972)

Шәриф Саттаров 1887 елның 10 маенда Оренбург шәһәрендә туа. 1905–1909 елларда Казандагы Укытучылар мәктәбен тәмамлый һәм Иж-Буби мәдрәсәсендә рус теле укыта башлый. 1911 елда, донос буенча, Иж-Буби укытучылары белән бергә алдынгы карашлы Ш.Саттаров та кулга алына һәм Сарапул төрмәсенә ябыла. Ирекка чыгарылгач та ул 1911 елның маеннан 1913 елның сентябренә кадәр Казанда полиция күзәтүе астында яши.

1909–1911 еллар арасында Ш.Саттаров үзенең беренче сәхнә әсәрләре «Татар тәгассыб вә җәһаләтенең корбаны», «Татар милләтен тәрәккый иттермәүчеләр», «Бәхетсез татар кызы» исемле пьесаларын яза, һәм алар 1911 елда басылып чыга. Драматургның геройлары — татарны белемле, мәгърифәтле итү өчен көрәшүче яшьләр. «Бәхетсез татар кызы» драмасында яратмаган кешегә кияүгә бирелгән һәм кыерсытылып яшәүгә дучар ителгән Шакирәнең фаҗигасе тасвирлана. «Кабак алды» исемле комедиясе 1911 елда «Сәйяр» труппасы репертуарына кертелә.

1913 елдан Ш.Саттаров яңадан Иж-Буби мәдрәсәсендә, 1914–1915 елларда Ижбәйки авылында укыта.

Полиция күзәтүеннән котылыр өчен Ш.Саттаров Әстерхан якларына китә. Анда 1915–1917 елларда Сәетле авылында Русско-Каргашинское училищесында дәресләр бирә. Шунда Февраль революциясен каршылый. Бу елларда ул «Азатлык корбаннары», «Фабрикант кызы», «Степка Разин», «Мирзалар һәм чуралар» исемле пьесалар яза. «Азатлык корбаннары» дигән драмасының Октябрьгә кадәр Әстерхан сәхнәләрендә куелуы мәгълүм.

1917 елның сентябреннән Ш.Саттаров Әстерханда мәгариф өлкәсендә төрле җаваплы вазифалар башкара. Шул елларда «Аклар килгәч», «9 нчы Январь», «Завод хуҗасы һәм эшчеләр» исемле пьесаларын яза.

1923–1924 елларда Ш.Саттаров Бакуда укытучылар курсында һәм эшчеләр курсларында дәресләр бирә. Шундагы Үзәк эшчеләр клубы сәхнәләрендә аның «Азатлык корбаннары», «Аклар килгәч», «Фабрикант кызы» пьесалары уйнала.

1925–1950 елларда Ш.Саттаров Мәскәүдә эшли: дәреслекләр яза, газета-журнал битләрендә мәкаләләр бастыра, латин графикасына күчү эшендә актив катнаша һ.б.

1950–1955 елларда ул Ташкентта яши, туган тел дәреслекләрен һәм дәресләрнең сыйфатын күтәрүгә багышланган хезмәтен тәмамлый.

1955 елда Ш.Саттаров Татарстанның Яшел Үзән шәһәренә кайта һәм башлангыч класслар өчен татар теле дәреслекләре төзи. Соңгы елларда «Зөһрә кыз» исемле пьесасы дөнья күрә.

Әдип һәм педагог Шәриф Саттаров 1972 елда Яшел Үзән шәһәрендә вафат була.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Саттаров Ш.** Кабак алды: Көлке 1 пәрдәдә. — Казан, 1911. — 23 б.

**Саттаров Ш.** Бәхетсез татар кызы: Кайгылы 3 пәрдәдә. — Казан, 1911. — 45 б.

**Саттаров Ш.** Татар милләтен тәрәккый иттермәүчеләр: Драма 5 пәрдәдә. — Казан: Ә.Хәсәни вә шөрәкәсе нәшире, И.Н.Харитонов мәтб., 1911. — 70 б.

**Аның турында:**

Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. — 3 т. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 365–366 б.

**Рәми И., Даутов Р.** Әдәби сүзлек: Элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 201–209 б.

**Ханзафаров Н.** Шәриф Саттар. Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. — Казан: 2005. — 170–172 б.

## ЮНЫС САФИУЛЛИН (1947)

Юныс Габдулла улы Сафиуллин 1947 елның 18 октябрендә Татарстанның Яшел Үзән районы Бакырчы авылында туа. Әтисе хәрби кеше булу сәбәпле, Сафиуллиннар гаиләсенә төрле җирләргә күчеп йөрергә туры килә. Шулай да башлангыч белемне Юныс Сафиуллин үз авылларындагы мәктәптә ала, соңыннан күрше Акъегет авылындагы сигезьеллык мәктәпне тәмамлый. Бишенче сыйныфта ул шигырьләр яза башлый. Әдипнең беренче язу үрнәкләре районда чыгып килүче «Ярыш» һәм «Яшь ленинчы» газеталарында дөнья күрә.

1962 елда Юныс Сафиуллин Казан театр училищесына укырга керә. Беренче курстан ук Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакльләрендә актер булып катнаша башлый, җәй айларында театр белән Татарстанның төрле районнарына, Казакъстан, Урта Азия һ.б. төбәкләргә гастрольләр белән бара.

1966 елда театр училищесын уңышлы тәмамлаганнан соң, Ю.Сафиуллинны К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрына (элеккеге Республика күчмә театры) эшкә билгеліләр. Шул ук елда ул Совет Армиясенә хезмәткә алына. Армия юлларын үткәч, яңадан Татар дәүләт драма һәм комедия театрына кайта. 1976 елда А.В.Луначарский исемендәге Мәскәү дәүләт театр сәнгате институты (ГИТИС) каршындагы режиссерлар әзерләүче икееллык Югары курсларны тәмамлый һәм 1981 елга хәтле К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында актерлык эшен дәвам иттерә. 1981 елдан әдип Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында башта актер, соңыннан театрның әдәби бүлек мөдире булып эшли.

Ю.Сафиуллин татар драматургиясенә җитмешенче елларда килә. Әдипнең «Менә без дә үсеп җиттек» пьесасы 1979 елда Әлмәт театры, ә 1986 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәләрендә куелды. 1977 елда язылган «Әллә өйләнергә инде?..» пьесасы 1978 елда К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры репертуарында үз урынын ала. 1980 елда Ю.Сафиуллинның җитди иҗтимагый проблемаларны яктырткан «Ни булды бу ирләргә?» трагикомедиясе беренче тапкыр Әлмәт театрында уйнала. 1981–1987 елларда балалар өчен иҗат ителгән «Алмазбулат» әкият-пьесасы, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелып, тамашачылар тарафыннан җылы каршы алына. Моннан тыш әдипнең «Ләйсән ире Хәсән» (1972–1974, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куела), «Буйдак ир һәм танышлары» (1972), «Ур-тура, сатирик!» (1972), «Пар канат» (1988, Минзәлә театры), «Сукбай артистлар» (1998) һ.б. пьесалары языла.

1994 елда Ю.Сафиуллин, җәмгыятьтәге демократик үзгәрешләрдән файдаланып, тарихи чыганакларга, фәнни материалларга, «Идегәй» халык дастанына, Н.Исәнбәтнең «Идегәй» (1941) трагеди-

ясенә нигезләнеп, Алтын Урда дәүләтен тасвирлаган «Идегәй» трагедиясен иҗат итә. Ул 1994 елның 7 ноябрендә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела.

Ю.Сафиуллинның «Идегәй» трагедиясе һәм аның буенча куелган спектакль (режиссеры — Марсель Сәлимҗанов) мөһим вакыйга булып Мәскәүдә һәм илебезнең төрле сәхнәләрендә уңыш казана.

1996 елда әдипнең «Йөзек һәм хәнҗәр» исемле яңа трагедиясе дөнья күрә. Әсәр, Түбән Кама татар драма театры сәхнәсендә куелып, язучыга зур уңыш китерә. Тормышның иҗтимагый-сәяси проблемаларын тасвирлаган фаҗига тиз арада үз тамашачысын тапты.

Ю.Сафиуллин тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. Г.Камал театры өчен Р.Солнцевның «Красным по белому» («Йөрәк каным белән»), Г.Хугаевның «Черная бурка» («Кара чикмән»), Минзәлә театры өчен А.Галинның «Звезды на утреннем небе» («Таң йолдызлары») әсәрләрен тәрҗемә итә.

Г.Исхакыйның «Зөләйха» трагедиясе нигезендә Ю.Сафиуллин нәфис фильм өчен киносценарий әзерли.

1992 елдан башлап әдипнең Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, башка милли театрлар, актерлар, режиссерлар турында портрет-тапшырулары эфирдан яңгырый башлый.

Ю.Сафиуллин — 1982 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Сафиуллин Ю.** Менә без дә үсеп җиттек...: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1983. — 176 б.

**Сафиуллин Ю.** Пар канат: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. — 228 б.

**Сафиуллин Ю.** Чәчәкләр һәм күз яшьләре: Әсәр-хатирә. — Казан: Хәтер, 1999. — 176 б.

**Сафиуллин Ю.** Әллә өйләнергә инде?..: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 351 б., рәсем белән.

**Аның турында:**

**Ханзафаров Н.** Кешеләр матур булсын: «Әллә өйләнергә инде?..» комедиясе Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә // Социалистик Татарстан. — 1978. — 8 гыйнвар.

**Исхакова И.** Дебют драматурга. Пьеса «Жениться, что ли?..» на сцене Татарского театра драмы и комедии // Советская Татария. — 1978. — 5 февраля.

**Ханзафаров Н.** Кая барабыз, җәмәгать?: «Пар канат» драмасы Минзәлә татар дәүләт драма театры сәхнәсендә // Социалистик Татарстан. —1991. — 23 гыйнвар.

**Галимуллин Ф.** «Идегәй»нең кайтуы: «Идегәй» спектакле ТДАТ сәхнәсендә // Шәһри Казан. — 1994. — 18 ноябрь.

**Поюровский Б.** Бенефис бенефисов: Трагедия «Идегей» на сцене ТГАТ им. Г.Камала // Культура. — 1995. — 14 января.

**Гыйләҗев А.** Ак кеше, пакь кеше // Казан утлары. — 1997. — № 10. — 81–82 б.

**Миңнуллина Ф.** Юныс Сафиуллин драматургиясендә милләт язмышы // Фән һәм Тел. — 2003. — № 4.

**Игламов Р.** В пространстве трагедии: Трагедия «Перстень и кинжал» на сцене Нижнекамского драматического театра // Идель. — 1998. — № 2. — С. 77–79.

**Саттарова А.** Современная татарская драматургия 1985–2000 гг. Концепция эпохи и героя (Образ Идегея в трагедии Ю.Сафиуллина «Идегей»). — Казань: Gumanitarya, 2003. — С. 16, 45–63, 76–77, 128–131.

**Миннуллина Ф.** Драматургия Юнуса Сафиуллина (эволюция творчества): Автореф. канд. дис. — Казань: Мини-типограф. Института проблем информатики АН РТ, 2004. — С. 26.

## ӘБРАР СӘГЫЙДИ (1895–1939)

Әбрар Сәгыйди (Мөхәммәтәбрар Мөхәммәтзакир улы Сәгыйтов) 1895 елның 14 апрелендә Татарстанның Тау ягында — хәзерге Кайбыч районы Кече Кошман авылында туа. Атасы Закир хәзрәт (Ш.Мәрҗани шәкерте) беркадәр сабак таныткач, улын Казанга, үзе кебек имам хатип итү нияте белән, «Мәрҗания» мәдрәсәсенә урнаштыра. Мәдрәсәдә укыганда Әбрар Учительская семинариядә белем ала.

Ә.Сәгыйди шәкертлек елларында әдәбият мәйданына килә. 1913–1914 елларда «Ак юл» журналында һәм «Кояш» газетасында беренче шигырьләре басыла. Яшь шагыйрь иҗаты романтизм җир-

легендә формалаша һәм үсә бара. «Шура», «Сөембикә» журналларында һәм «Тормыш» газетасында басылган поэмаларында мифологик һәм символик образларга мөрәҗәгать итә, иҗаты дини мотивлар белән сугарыла.

Инкыйлаб һәм гражданнар сугышы елларында өч ел эчендә ике шигъри җыентыгы («Ирек азаны», «Сугыштан абыем хатлары»), биш поэмасы һәм алтмыштан артык шигыре басыла.

1918–1920 елларда Ә.Сәгыйди «Эшче» һәм «Татарстан хәбәрләре» газеталарында әдәби хезмәткәр, сәркатип урынбасары һәм бүлек мөдире булып эшли.

1921 елда совет матбугатында шагыйрь һәм журналист булып танылган Ә.Сәгыйди Буа районы Килдураз авылында мулла да булып тора. Ләкин илдә дингә, дин әһелләренә карата кысу, сәяси чаралар күрелә башлагач, ул мулла хокукларыннан азат ителә.

1925 елдан төрле урыннарда: Зөя кантоны башкарма комитетында консультант-тәрҗемәче, татар телен гамәлгә кую буенча инструктор, мәгариф бүлеге инспекторы, Мәлки, Кече Кошман, Зөя, Карауҗа, Кайбыч мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Мулла нәселеннән булганы өчен һәр җирдә берәр ел гына эшләргә туры килә.

1930 елларда Ә.Сәгыйди әдәбият мәйданыннан читләтелә, төрле сылтаулар белән әсәрләре матбугатта басылмый. «Кырлар тавышы» шигъри җыентыгы, «Кирпеч базларында» повесте чыкмый кала, иҗаты бары тискәре яктан гына бәяләнә.

Ә.Сәгыйди драма жанрында да уңышлы гына иҗат итә. Аның 27 исемдәге драматик әсәренең бары тик берсе генә сәхнәгә менә. «Сахра кызы» исемле 5 пәрдәлек драмасы 1928 елда Татар дәүләт академия театрында, соңрак Мәскәү үзәк татар эшчеләр театрында уйнала. Әдипнең «Ишан улы», «Кызыл таң», «Сак-Сок» кебек бүген дә кызыксынып укырлык драмалары бар.

Әдәби тәрҗемәче буларак, Ә.Сәгыйди егерменче елларда Имрү әл-Кайс, Рабиндранат Тагор, Уолт Уитмен һәм Демьян Бедный әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

Талантлы шагыйрь һәм журналист Ә.Сәгыйди тоталитар режим тарафыннан үкенечле язмышка дучар ителә. Ул каты авырудан соң 1939 елның 1 апрелендә туган авылы Кече Кошманда вафат була. 2005 елда Кошман урта мәктәбенә Ә.Сәгыйди исеме бирелде.

**Аның турында:**

**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 424 б.
«Эшләдем мин, җырладым читлектәге вакытымда да...» // Татарстан яшьләре. — 1995. — 18 апрель.
**Рәми З., Сәгыйтов М.** Катлаулы чор һәм шагыйрь язмышы // Ватаным Татарстан. — 1995. — 25 апрель.
**Сәгыйтов М.** Дәһшәтле еллар аша // Шәһри Казан. — 1995. — 21 апрель.

## РӘДИФ СӘГЪДИ (1957)

Рәдиф Сәгъди (Рәдиф Нәҗип улы Сәгъдиев) 1957 елның 17 июлендә Казан шәһәрендә туа. Балачак еллары әнисенең туган авылы — Кама Тамагы районының Балчыклы авылында үтә. 1964 елда шушы авылның башлангыч мәктәбенә укырга керә, бишенче сыйныфны күрше Иске Казиле авылы мәктәбендә тәмамлый. 1970 елда Рәдиф Сәгъди Казанның 113 нче татар мәктәбендә (хәзерге 4 нче татар гимназиясе) укуын дәвам итә. Бу чорда ул театр студиясенә йөри, баянда уйнарга өйрәнә, ныклап спорт белән шөгыльләнә. 1975 елда бокс буенча I разряд нормасын, кышкы күптөрлелек буенча спорт мастеры нормасын үти. 1974 елны Рәдиф Сәгъди Казан театр училищесына укырга керә. Бу елларда ул шаян шигырьләр, поэмалар иҗат итә. 1976–1978 елларда, укуыннан аерылып, армиядә хезмәт итә. 1978–1981 елларда, училищены тәмамлап, театр актеры дигән дипломны ала һәм Әлмәт драма театрына эшләргә китә. Ике елдан соң әдип, Казанга кайтып, төзелештә мастер-бригадир булып эшли. 1984 елда ул К.Тинчурин театрына актер булып әйләнеп кайта. 1986–1992 елларда Рәдиф Сәгъди Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетында белем ала.

Университетта уку дәверендә Рәдиф Сәгъди ныклап әдәби әсәрләр иҗат итү белән шөгыльләнә башлый. Аның «Әллә язмыш, әллә ялгыш» (1988) моңсу драмасы, «Финленди дә рәхәт ди» (1989) комедиясе, «Мөҗбирнең күккә ашуы» (1990) хыялый драмасы язылып, төрле театр сәхнәләрендә дөнья күрә башлый. Мәсәлән, «Финленди дә рәхәт ди» комедиясе Чаллы драма театрының реперту-

арында лаеклы урынын алды. Әдипне драматург буларак таныткан әсәрләрнең берсе — «Сынган беләзек» (1994) мелодрамасы — К.Тинчурин театрында куелды. Бөек Ватан сугышы темасына багышланган пьесада сәяси һәм иҗтимагый проблемалар туган җиренә әйләнеп кайта алмаган солдатның психологик кичерешләре яссылыгында тапшырыла. Р.Сәгъдинең образларга, хис-кичерешләргә бай булган әлеге мелодрамасы Бөек Ватан сугышын яңа ноктадан яктырткан әсәрләрнең берсе булды. 1998 елда язылган һәм К.Тинчурин театрында сәхнәләштерелгән «Яз галәмәте» комедиясе авторга яңадан уңыш китерде. Тарихи темага багышланган «Ирләр яуга киткәндә» (2002) тарихи драмасы «Мәйдан» журналы битләрендә басылып чыкты.

Р.Сәгъди балалар һәм яшүсмерләр өчен иҗат итүче драматург буларак та билгеле. Аның «Баһадирның бәхете» (1992) һәм «Баһадурның яңа дуслары» (1993) әкият-пьесалары К.Тинчурин театрында уңыш белән бардылар. Тамашачылар күңеленә хуш килгән «Гүзәл аппаксылу» (2001) һәм «Иске курчакларда Яңа ел» әкият-пьесалары Татар яшьләр театрында сәхнәләштерелде.

Р.Сәгъди повесть һәм роман жанрларында да иҗат итә. Аның «Канга буялган алтыннар» (1990), «Гаилә сурәте» (1992), «Кыйммәтле хезмәт» (1993), «Алло, хәлләр ничек?» (1999) детектив повестьлары, «Адашканнар» (1996) фантастик повесте, «Көтмәгәндә, ниһаять» (1994) детектив романы, «Ике кояшлы дөнья» (2001–2002) фантастик романы «Идел» журналы битләрендә дөнья күрде. 2003 елда әдипнең «Канга буялган алтыннар» исемле роман һәм повестьлар җыентыгы басылды.

Р.Сәгъдинең күпсанлы әкиятләре, публицистик мәкаләләре басылды. Әдип «Киләм, диден, килмәдең», «Сау бул, Казан», «Гүзәл Кама Тамагы», «Лаешым», «Кайттым, бәхетле ит әле» һ.б. җырлар авторы буларак та танылды.

2005 елда Р.Сәгъдигә «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде. 2005 елда Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы аңа «Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен» медален тапшырды.

Ул — 2000 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Сәгъди Р.** Яңа ел могҗизасы: Скетч // Идел. — 2004. — № 1. — 4–8 б.
**Сәгъди Р.** Ирләр яуга киткәндә: Тарихи драма // Мәйдан. — 2002. — № 3. — 35–37 б.
**Сәгъди Р.** Сынган беләзек: Мелодрама // Казан утлары. — 1999. — № 6. — 101–113 б.
**Сәгъди Р.** Ана күңеле балада: Әкиятләр, легендалар буенча пьеса // Мәйдан. — 2004. — № 3. — 75–86 б.

**Аның турында:**

**Яһудин Э.** Сәхнәдә «Сынган беләзек» // Шәһри Казан. — 1997. — 12 июнь.
**Маннапова Ф.** Казан артистлары Уфаны алкышлатты // Кызыл таң. — 1998. — 23 сентябрь.
**Гыйմранова Д.** Театрга гашыйк булыгыз! // Казан утлары. — 2003. — № 2. — 124–130 б.
**Айтуганов Б.** Милли байрак астында // Татарстан хәбәрләре. — 2003. — № 12.
**Шәрәфетдинова Ф.** Студентлар сабак ала // Ватаным Татарстан. — 2005. — 6 май.

## ФАТИХ
## СӘЙФИ-КАЗАНЛЫ
## (1888—1937)

Фатих Сәйфи-Казанлы (Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин) 1888 елның 22 мартында элекке Казан губернасының Спас өязе (хәзерге Әлки районы) Карамалы авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1891–1892 елгы ачлык вакытында бу гаилә Казанга күчә. Биредә Фатих «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый һәм 1905 елда хәзерге Сарман районы Яхшыбай авылындагы яңа методлы мәдрәсәдә мөгаллим булып эшли башлый.

1905 елгы рус революциясе дулкынында Фатих Сәйфи Казанга күчә һәм, кулына каләм алып, мәдрәсә шәкертләренең тормыш һәм укыту шартларын яхшырту өчен көрәшүчеләр сафына баса. Матбугатта басылган күпсанлы мәкалә очеркларыннан тыш, «Берек» исемле укучылар оешмасында катнаша. Мәгърифәтчелек проблемаларын яктырткан беренче әдәби әсәре — «Мөкатдәс хезмәт» дигән сәхнә әсәрен яза.

1909 елда Фатих Сәйфинең «Безнең заман» исемле бер пәрдәлек комедиясе дөнья күрә. «Безнең заман»ның икенче пәрдәсе рәвешендә язылган «Җәмәгать хадиме» (1916) комедиясе исә әдипнең драматургия өлкәсендә игътибарга лаеклы беренче тәҗрибәсе була. Әлеге әсәрендә автор аң-белемне күтәрү, мәктәп-мәдрәсәләрне үзгәртеп кору, хатын-кыз азатлыгы, әхлак мәсьәләләрен күтәрә.

1913–1914 елларда Ф.Сәйфи иң күләмле әсәре — «Ямьсез тормыш» исемле өч пәрдәлек драмасын яза. Автор аны татарның күренекле артисты Габдулла Кариевка багышлый. Пьеса 1915 елда «Сәйяр» артистлары тарафыннан сәхнәгә куела.

1906–1917 еллар эчендә Ф.С.-Казанлы «Йолдыз», «Аң», «Тормыш», «Ялт-Йолт», «Мәктәп», «Ак юл» кебек газета-журналларда иҗтимагый тормышның төрле якларын яктырткан публицистик мәкаләләре белән катнаша. Шушы чорда ул «Сәйфи-Казанлы» дип имза куя башлый. Матбугат битләрендә Ф.Камалов, Исәнбай, Гарб, Бакыр күз, Батыр күз, Чәпи Камалый малае кебек псевдонимнар белән дә чыгыш ясый.

Империалистик сугыш елларында Ф.Сәйфи Казаннан Уфага күченә һәм 1915–1917 елларда «Галия» мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә. Февраль һәм Октябрь инкыйлабларын биредә каршылый һәм «Ирек» газетасын (нашире — Г.Ибраһимов) оештыру эшендә активлык күрсәтә. Революция һәм гражданнар сугышы елларында педагог буларак та зур эш башкара. Татар мәктәпләре өчен тарих, тел буенча иң беренче дәреслекләр төзи.

1918 елның гыйнварында Сәйфи-Казанлы янә Казанга күчә. Вакытлы матбугатта («Эшче», «Эш» газеталарында) актив языша. 1920 елда РКП(б)га әгъза итеп алына. Татарстан Республикасы төзелгәч, Мәгариф халык комиссариатында, Җир эшләре халык комиссариатында җаваплы урыннарда эшли. 1923–1925 елларда «Кызыл Татарстан» һәм «Крәстиян» газетасының җаваплы редакторы була. 1923–1932 еллар арасында Ф.Сәйфи Татарстан Республикасы Советлары съездына делегат һәм Татарстан Үзәк башкарма комитетына вәкил була.

1925–1926 еллардан башлап Ф.Сәйфи татар язуын гарәп хәрефләреннән яңалифкә күчерү өлкәсендә иң актив пропагандист буларак таныла. Татарстан «Яңалиф» җәмгыятенең рәисе, «Яңалиф» журналының җаваплы редакторы булып эшли.

Бу елларда ул татар классик әдәбиятын популярлаштыру, җыю һәм бастырып чыгару юлында да күп кенә эшли. Ул Г.Тукайның өч, Г.Камалның ике, Дәрдемәнднең бер томлык җыентыкларын төзеп чыгара, Г.Камал һәм Ф.Әмирхан иҗатларына багышланган «Ике татар классигы» исемле әсәрен бастыра.

Язучы Ф.С.-Казанлы гражданнар сугышы күренешләрен, колхозлашу хәрәкәтен, эшчеләр тормышын чагылдырган проза һәм драма әсәрләре дә яза. Дүрт пәрдәлек «Дошманнар» драмасына (1920) сюжет итеп ил тарихында кискен борылыш ясаган давыллы 1917 елның көзендә булган хәлләр алына. Заман таләп иткәнчә, драматург шәхес концепциясен революциягә мөнәсәбәттә ачыклый һәм дошманнар ягына басым ясавы белән үз чор әдәбиятына яңалык алып килә. Драма 1921 елда режиссер Ш.Шамильский тарафыннан сәхнәләштерелә. Иң соңгы әсәрләреннән булган биш пәрдәлек «Зөбәрҗәт» драмасында исә хезмәт иясен үсеш-үзгәрештә күрсәтү тенденциясе үзәк урынны алып тора. «Зөбәрҗәт» пьесасы Татар дәүләт академия театрында 1935–1936 елгы сезонда берничә тапкыр уйнала.

Утыз ел буена әдәбиятка тугры хезмәт иткән Ф.Сәйфи-Казанлы шәхес культы корбаны була. 1936 елның 16 сентябрендә ул кулга алына. 1937 елның 3 августында иң югары җәзага — атарга хөкем ителә.

Ул 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Сәйфи-Казанлы Ф.** Дошманнар: Драма 4 пәрдәдә. — Яңалиф, 1929. — 60 б.
**Сәйфи-Казанлы Ф.** Әсәрләр / Төз. Х.Хисмәтуллин. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 416 б.

**Аның турында:**

Татар совет әдәбияты тарихы: Очерклар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 824 б.
**Рәмиев И.** Хәтердә шулай калган // Совет әдәбияты. — 1964. — № 2. — 143—145 б.
**Мөхәммәдиев Р.** Әгәр без янмасак: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — 144 б.

**Гарифуллин Д.** Ул халык күңелендә // Социалистик Татарстан. — 1988. — 22 март.
**Мусин Ф.** Фатих Сәйфи-Казанлы // Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. — 4 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 213–334 б.
**Гыйззәтуллин Н.** Үз заманының улы // Казан утлары. — 1998. — № 3. — 185–186 б.

##ҺАДИ ТАКТАШ (1901—1931)

Һади Такташ (Мөхәммәтһади Хәйрулла улы Такташев) 1901 елның 1 гыйнварында элекке Тамбов губернасы Спас өязе (хәзерге Мордва республикасының Торбеевка районы) Сыркыды авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Башта авыл мәктәбендә, соңрак заманы өчен җәдиди уку йортларыннан саналган Сыркыдыдан 30 чакрым ераклыкта булган Пешлә мәдрәсәсендә өч ел укый.

Зур гаиләнең матди хәле авыр булу сәбәпле, Хәйрулла абзый улларын читкә эшкә җибәрергә мәҗбүр була. Унөч яшьлек Һади да, үзләренә туган тиешле сәүдәгәргә ияреп, Бохара якларына юл ала. Башта әлеге сәүдәгәрнең өендә хезмәтче малай хәлендә яши, аннары шәһәр байларының берсендә приказчик өйрәнчеге булып эшли. Хезмәттән буш вакытларында шәһәр яшьләренең төрле мәдәни эшләрендә, һәвәскәрләр оештырган спектакль, концертларда актив катнаша. «Олугъ Төркестан» газетасында мәдәни яңалыкларны яктырткан мәкаләләре һәм «Төркестан сахраларында» (1918) исемле шигыре басыла.

1918 елның көзендә Һ.Такташ туган авылы Сыркыдыга кайта. Авылда китапханә мөдире һәм башлангыч мәктәп укытучысы булып эшләгәннән соң, 1919 елның көзендә Оренбургка килә. «Юксыллар сүзе» газетасында әдәби хезмәткәр, аннары җаваплы сәркатип, вакытлыча редактор вазифаларын да башкара. Шунда ул Ш.Камал, А.Таһиров кебек күренекле әдипләр белән таныша, шәһәрнең мәдәни тормышында актив катнаша. «Юксыллар сүзе»ндә аның мәкаләләре һәм шигырьләре («Караңгы төннәрдә», «Ачлык патша», «Антым» һ.б.) басыла.

1921 елның язында (февраль-март) Ташкентка күчеп, анда Төркестан эшче-диһкан университетында әдәбият укыта, «Белем йорты» журналында җаваплы сәркатип булып эшли. Иҗат эшчәнлеге тагын да активлаша. Шунда ул «Таң кызы», «Урман кызы» кебек шигырьләрен, беренче сәхнә әсәре булган «Җир уллары трагедиясе»н (1921) яза.

Тынгысыз Такташ 1922 елда берничә ай Мәскәү әдәби атмосферасында кайный, әдәби кичәләргә йөри. Шул елның көзендә Казанга килә һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шунда төпләнеп кала. Берникадәр вакыт татар театрында суфлер, 1923–1924 елларда «Чаян» журналында, 1925–1926 елларда «Октябрь яшьләре», «Авыл яшьләре» журналларында җаваплы сәркатип вазифаларын башкара. Журналистлык эшчәнлеген ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам итә. 1926–1929 елларда «Азат хатын»да, ә 1929–1931 елларда кабат «Чаян»да эшли.

Һ.Такташ татар сәхнәсенә 4 драма әсәре язып калдыра. Алар идея-проблематикасы һәм сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан егерменче еллар татар драматургиясендә мактаулы урын тоталар. Дини-мифологик сюжетка нигезләнеп язылган «Җир уллары трагедиясе» 1923 елда басыла һәм шул ук елны зур сәхнәгә дә менә. Спектакльнең премьерасында Идея ролен Такташ үзе башкара.

Егерменче елларның икенче яртысында ул драматургиянең күләмлерәк жанрларына мөрәҗәгать итә. 1927 елда Татар дәүләт академия театры, Октябрь революциясенең унъеллык юбилеен каршылап, Такташның «Күмелгән кораллар» драмасын сәхнәгә куя. Әсәр 1928 елда аерым китап булып басыла. Шул ук сәхнәдә 1929 елда «Югалган матурлык» (1927) пьесасы, 1930–1931 елларда «Камил» (1929) драмасы уйнала. «Камил» драмасы нигезендә шагыйрь 1930 елда «Востоккино» өчен «Камил» исемле киносценарий яза. 1931 елда «Янгын» пьесасы өстендә эшли башлый. Үз заманында хаксыз тәнкыйтькә дучар ителгән «Югалган матурлык» драмасы Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында кабат 1956 елда сәхнәләштерелә.

Такташ — барыннан да элек шагыйрь булып танылган әдип. Ташкент чорында — 1921–1922 елларда язылган романтик әсәрләрендә («Онытылган ант», «Күләгәләр», «Нәләт», «Таң кызы», «Урман кызы») ул мифологик һәм символик образлар, сурәтләү чаралары аша кеше шәхесенең рухи хөрлеген данлый. Казанда 1922–1923 елларда иҗат ителгән «Бакчачылар», «Мәңгелек әкият», «Урамда», «Гыйсъян», «Янар таулар» кебек шигырьләрендә поэтик фикерләүдәге романтик гыйсъянчылык мотивлары яңгырый. «Мәхәббәт тәүбәсе» (1927), «Алсу» (1929), «Мокамай» (1929) кебек лирик поэ-

малары, «Киләчәккә хатлар» (1931) исемле шигъри әсәре белән ул егерменче еллар лиро-эпик жанрын үстерүгә зур өлеш кертә.

Һ.Такташ — заманының актуаль проблемаларын яктырткан дистәләрчә публицистик мәкалә, очерк һәм фельетон авторы да. Хикәя жанрында, әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә каләм тибрәтеп карый.

Ул — үзенең шигъри мәктәбен тудырып, бик күп шагыйрьләрнең үсүенә, формалашуына зур уңай йогынты ясаган шәхес.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Такташ Һ.** Җир уллары трагедиясе: 6 күренештә. Адәм, Хаувалар тормышыннан. — Казан: Корылтай, 1923. — 102 б.

**Такташ Һ.** Күмелгән кораллар: Драма 5 пәрдәдә. — Казан: Татиздат, 1928. — 66 б.

**Такташ Һ.** Әсәрләр: 3 томда. — 2 т: Драматургия һәм проза. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1981. — 480 б.

**Такташ Һ.** Сайланма әсәрләр / Кереш мәкалә авторы Р.Яруллина. — Казан: Хәтер, 2006. — 382 б.

**Аның турында:**

Һ.Такташ турында истәлекләр / Төз. һәм искәрмәләрне язучылар: Н.Юзиев, Н.Садыйкова. Н.Юзиев кереш сүзе белән. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — 287 б.

Һади Такташ. Яңа тормыш җырчысы: Фәнни конференция материаллары / Ред.: Г.Халитов һ.б. — Казан, 1982. — 160 б.

**Хәйри Х.** Һади Такташ (1901–1931): Атаклы кешеләр тормышы. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. — 176 б.

**Әхмәдуллин А.** Һ.Такташ пьесаларында гомумкешелек мәсьәләләренең чагылышы // Әхмәдуллин А. Дөреслеккә ирешү юлында: Мәкаләләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. — 215–222 б.

**Әхмәдуллин А.** Яңалык алып килгән драмалар // Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 54–59 б.

Такташ: Истәлекләр, шигырьләр / Төз.: Р.Батулла, Р.Корбан. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 207 б.

**Бәйрәмова Ф.** Мишәрнең бөек улы: Фәнни-публицистик язмалар. Драматургия. — Казан, 2001.

Һади Такташ: Библ. күрс. / Татарстан Респ. Милли китапханәсе. Төз.: Н.С.Митрофанова, Д.Р.Фәхретдинова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. — 286 б.

**Хабутдинова М.** Проблема личности в творчестве Хади Такташа. Дис. ... канд. филол. наук 10.01.02. — Казань, 1998 — С. 198.

## КӘРИМ ТИНЧУРИН (1887–1938)

Кәрим Гали улы Тинчурин 1887 елның 15 сентябрендә Пенза өлкәсе Беднодемьянск районы Аккүл авылында ишле гаиләдә дөньяга килә. К.Тинчуринның әтисе Гали — тырыш, урта хәлле крестьян, әнисе Мәхмүдә шактый укымышлы мулла кызы була.

Туган авылыннан ике чакрым ераклыктагы Татар Шалдавычы дигән авыл мәдрәсәсендә укыгач, К.Тинчурин 13 яшендә, бәхет эзләп, Казанга килә һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Мәдрәсә еллары (1900–1906) яшь егетнең әдәбиятка, сәнгатькә тартылуында һәм дөньяга карашы киңәюендә әһәмиятле роль уйный.

1905 елгы рус революциясе дулкыннары тәэсирендә укудан канәгать булмаган 82 шәкерт белән берлектә К.Тинчурин да 1906 елның февралендә мәдрәсә стеналарын ташлап чыгып китә. Әлеге шау-шулы вакыйга күп татар газеталарында яктыртыла. Шуннан соң Россия төбәкләре буйлап бәхет эзләү башлана: урман каравылчысы булып тору, балалар укыту һәм язу эшендә көч сынап карау. 1906 елда аның тәүге әсәре булган «Моназарә» (сүз көрәштерү, бәхәсләшү) комедиясе языла.

1910 елда ул «Сәйяр» труппасында эшли башлый. Г.Кариев кебек тәҗрибәле остаз җитәкчелегендә аның актерлык таланты тагын да камилләшә. Ул бу чорның иң популяр әдипләре — Г.Камал, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Коләхмәтов пьесаларындагы һәм тәрҗемә әсәрләрдәге төп рольләрне башкара. Шуның белән бергә К.Тинчурин труппа репертуарын баетуга да зур көч куя: үзен драматург-

новатор итеп таныта, татар драматургиясенә яңа темалар һәм геройлар алып килә. Бу елларда ул «Хәләл кәсеп» (1910), «Шомлы адым» (1910–1912), «Беренче чәчәкләр» (1913), «Назлы кияү» (1915), «Ач гашыйк» (1915), «Җилкуарлар» (1916), «Соңгы сәлам» (1917), «Йосыф-Зөләйха» һ.б. пьесаларын яза. Шулардан «Беренче чәчәкләр», «Назлы кияү» һәм «Соңгы сәлам» әсәрләре 1917–1922 елларда «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәләштерелә.

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң К.Тинчурин яңа татар совет театрын оештыру эшендә актив катнаша, М.Горький, Г.Исхакый, Г.Коләхмәтов пьесаларын сәхнәләштерә. Күренекле сәхнә осталары М.Мутин, С.Айдаров, Г.Кариевны Казанга кайтаруга зур көч куя.

Гражданнар сугышы тәмамланып, тыныч тормыш урнаша башлагач, Татарстан хөкүмәте Кәрим Тинчуринга Дәүләт театр труппасын оештыру бурычын йөкли. 1922 елның 8 ноябрендә Казанда Кызыл Октябрь исемендәге Татар дәүләт театры ачыла, һәм аның баш режиссеры итеп К.Тинчурин билгеләнә. Әлеге театрда К.Тинчурин белән бергә Б.Тарханов, М.Мутин, З.Солтанов, К.Шамил, Ш.Шамильский, Г.Болгарская, Камал I, Р.Кушловская кебек сәхнә йолдызлары үз эшчәнлекләрен башлый.

К.Тинчурин чакыруы буенча Оренбургтан татар профессиональ музыкасына нигез салучы Салих Сәйдәшев кайта, һәм ике зур талантның иҗади дуслыгы башлана.

К.Тинчурин татар профессиональ театрын оештыруда һәм яңа үрләргә күтәрүдә бөтен җанын һәм энергиясен биреп эшли. Авыр һәм җаваплы эштә үзен артист, режиссер, драматург, теоретик һәм оста җитәкче итеп таныта.

К.Тинчурин әсәрләре жанр ягыннан төрле. Ул калдырган әдәби мираска күз салсак, шулардан 12 се комедия, 5 есе драма, 4 есе музыкаль драма, 1 се трагедия. 4 әсәре башка авторлар белән берлектә эшләнә. Күренгәнчә, К.Тинчурин үзен беренче чиратта комедия жанрында оста комедиограф итеп таныта.

Аеруча Октябрь революциясеннән соңгы елларда драматург иҗатында комедия жанрына күчешне күзәтергә мөмкин. Аның «Йосыф-Зөләйха» (1918), «Сакла, шартламасын!» (1918), «Казан сөлгесе» (1922), «Американ» (1923), «Җилкәнсезләр» (1926), «Хикмәтле доклад» (1928) комедияләре халык көлүе рухында иҗат ителә. Аларга бәйрәмчә җиңеллек, хәрәкәтчәнлек, фарс һәм водевиль алымнары, анекдотик сюжет һәм ситуацияләр хас. Әлеге комедияләр һәм тагын «Җилкуарлар», «Нәни абый» комедияләре шул елларда К.Тинчурин режиссерлыгында «Сәйяр» труппасы (1926 елдан Татар дәүләт академия театры) артистлары тарафыннан сәхнәгә куела.

К.Тинчурин, М.Фәйзи традицияләрен дәвам итеп, яңа милли театрга халык сәнгатен алып керә. «Зәңгәр шәл» (1926), «Казан сөлгесе (1922), «Сүнгән йолдызлар» (1923), «Ил» (1927), «Кандыр буе» (1930) исемле пьесаларын язып, популяр музыкаль драма жанрының үсешенә зур өлеш кертә. «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе» кебек атаклы әсәрләрдәге җырлар К.Тинчурин белән С.Сәйдәшевнең бердәм иҗат җимеше булып тора.

Утызынчы елларда драматург совет чынбарлыгын чагылдырган «Корыч орчык» (1930) (Ф.С.-Казанлы белән берлектә), «Ударниклар бәйрәме» (1933), «Алар өчәү иде» (1935) кебек пьесалар яза. Бу пьесаларның барысы да диярлек үз вакытында профессиональ артистлар тарафыннан сәхнәгә куела. Аларның күпчелегенә Кәрим Тинчурин режиссерлык итә.

К.Тинчурин — талантлы драматург кына түгел, үзенә генә хас стиль белән иҗат ителгән хикәя остасы да. Ул бу жанрда аеруча 1914–1918 елларда, ягъни илдәге гаять катлаулы, каршылыклы чорда иҗат итә. Тирән драматизм белән сугарылган «Хәкимҗан агай» (1916), «Искәндәр» (1917), сатирик эчтәлекле «Юбилей», «Ак чирбик» хикәяләрендә, мөһим тарихи вакыйгаларны үз эченә алган автобиографик характердагы «Мәрҗәннәр» (1935–1937) әсәрендә дә К.Тинчурин үзен сюжет кору, калку образлар тудыру остасы итеп таныта.

Театр өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен К.Тинчуринга 1926 елда «Татарстанның атказанган артисты» исеме бирелә.

Утызынчы еллар уртасында көчәеп киткән шәхес культы җилләре, кызганыч, К.Тинчурин кебек олуг шәхесне дә аяп узмый. Иҗатының һәм театр эшчәнлегенең нәкъ чәчәк аткан чорында — 50 яше тулган көннәрдә — ул кулга алына. Хаксызга «халык дошманы», «милләтче» дип гаепләнеп, 1938 елның 15 ноябрендә судсыз-нисез атыла. Сталинның шәхес культы фаш ителгәннән соң, 1955 елда К.Тинчурин шәхесе дә аклана, иҗаты халыкка кайтарыла. Татар дәүләт драма һәм комедия театрына К.Тинчурин исеме бирелә. Театр сәхнәләренә аның әсәрләре кабаттан менә һәм зур популярлык казана.

К.Тинчурин 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Тинчурин К.** Сайланма әсәрләр / Төз. З.Тинчурина, Р.Ишморатов, Б.Гыйззәт. — Казан: Таткнигоиздат, 1956. —567 б.

**Тинчурин К.** Сайланма драмалар һәм комедияләр: 2 томда. — 1 т. / Төз., сүз башы һәм иск. авт. Б.Гыйззәт. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1969. — 542 б.

**Тинчурин К.** Сайланма драмалар һәм комедияләр: 2 томда. — 2 т. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1971. — 577 б.

**Тинчурин К.** Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. — 222 б.

**Тинчурин К.** Әсәрләр: 3 томда / Томны төзүче, сүз башы язучы һәм искәрмәләр әзерләүче Б.Гыйззәт. — 1 т.: Драмалар һәм комедияләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 511 б.

**Тинчурин К.** Әсәрләр: 3 томда. — 2 т.: Драмалар һәм комедияләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 544 б.

**Тинчурин К.** Сайланма әсәрләр / Төз., кереш сүз авт. Р.Яруллина. — Казан: ТаРИХ, 2003. — 495 б.

**Аның турында:**

**Әхмәдуллин А.** Визит карточкасы булып калсын иде // Әхмәдуллин А. Дөреслеккә ирешү юлында. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. — 124–128 б.

**Батулла Р.** Аның белән янәшә: К.Тинчуринның тууына 100 ел // Казан утлары. — 1997. — № 9. — 148–153 б.

**Баһаветдинов Р.** Кәрим Тинчуринның соңгы көннәре // Казан утлары. — 1990. — № 2. — 149–151 б.

**Җәләлиева М.** Тарих әһеле: К.Тинчурин турында уйланулар // Җәләлиева М. Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. — 42–47 б.

**Әхмәдуллин А.** «Соңгы сәлам»: Г.Камал театрында К.Тинчурин драмасының куелышы // Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 91–95 б.

**Арсланов Г.** Кайгыда юата, шатлыкта уйната: К.Тинчуринның тууына 115 ел тулу уңаеннан // Ватаным Татарстан. — 2002. — 20 сентябрь.

**Закирҗанов Ә.** Беренче адымнар (К.Тинчуринның башлангыч чор иҗаты) // Закирҗанов Ә. Заман белән бергә. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 139–145 б.

**Солтанова Р.** Кәрим Тинчурин әсәрләрендә сәхнә бизәлеше // Фәнни Татарстан. — 2004. — № 1–2. — 135–141 б.

**Игламов Р.** Выдающийся драматург. — Казань: Татиздат, 1987. — С. 122.

**Ханзафаров Н.** Татарская комедия. — Казань: Фэн. — 1996. — С. 266.

## ГОМӘР ТОЛЫМБАЙ (1900–1938)

Гомәр Толымбай (Габделхак Җәләлетдин улы Шаһиәхмәтов) 1900 елның 14 апрелендә Буа районы Адав-Толымбай авылында туа. Уналты яшенә кадәр туган авылы һәм Буа мәдрәсәләрендә белем ала. 1916 елда, укуын ташлап, Петроградка барып чыга һәм 1917 елгы Февраль революциясен шунда йөк ташучы буларак каршылый. Шул елның җәендә туган авылына кайта. Октябрь инкыйлабыннан соң крестьяннарга җир даулау эшләрендә катнаша. 1918 елда күрше Бикмураз авылы мәктәбендә укыта. Сембер (Ульяновск) шәһәрендә большевистик «Таң» газетасында беренче шигырьләрен бастыра. 1919 елда, шул вакыттагы тормыштан алып, ике пәрдәлек пьеса яза, һәм ул Буада куела.

Гражданнар сугышы чорында Г.Толымбай үз теләге белән Кызыл Армиягә китә. Фронттан кайткач, бөтен көч-сәләтен яңа татар совет әдәбиятын булдыруга, татар матбугатын үстерүгә багышлый. 1922–1923 елларда ул «Октябрь» һәм «Сулф» әдәби оешмаларын төзүдә катнаша. 1923–1927 еллар арасында Татар коммунистлар университетында укый. Аны тәмамлагач, «Гажур» нәшриятында редактор урынбасары, «Крәстиян» газетасында редактор булып эшли. 1929–1931 елларда Казан педагогия институтында гыйльми эш алып бара. 1931–1934 елларда Мәскәүдә Әдәбият институтында укый, диссертация яклап, «кызыл профессор» дигән гыйльми дәрәҗә ала. Аннан соң Казан педагогия институтында укыта. Татар дәүләт нәшриятының матур әдәбият секторында мөдир булып эшли.

Шәхес культы котырынган елларда Г.Толымбай җаны-тәне белән бирелгән, үзе инанган һәм бөтен барлыгы белән хезмәт иткән совет җәмгыятендә үзе үк шул җәмгыятькә каршы көрәшүче, Киров, Горький кебек шәхесләрне юк иткән контрреволюцион оешма төзешүдә, совет властен бетереп,

пантюркистик буржуаз дәүләт оештыруда гаепләнә. Г.Толымбай 1938 елның 9 маенда атып үтерелә. Кабере билгесез, шулай да ул Казанның Архангель зиратына күмелгән дип фаразлана.

Унтугыз елдан соң, ягъни 1957 елның 8 октябрендә, Г.Толымбай тулысынча реабилитацияләнә.

Г.Толымбайның әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме өлкәсендә заман идеологиясе белән сугарылган «Матур әдәбият фронты» (1926), «Татар буржуа теле безнең тел түгел» (1931), «Фатих Әмирхан» (1936) исемле китаплары языла. Шулай ук Г.Толымбай татар фольклорының үзенчәлекле жанрлары саналган җырларны һәм бәетләрне өйрәнүгә зур игътибар бирә. Бик күп бәетләрне җыеп, 1935 елда аерым китап итеп чыгара. 1936 елда ул әкият җыю эшенә керешә. Экспедицияләрдә йөреп, 51 әкият язып ала. Шуларның утыздан артыгы бүгенге көндә дә китапларда кат-кат басылып килә. Әдипнең «Түбән елгада» (1932), «Куян солдат» (1933) дигән повестьлары да бар.

Г.Толымбай татар театры тарихына «Баҗайлар» исемле пьесасы белән кереп калган. Әсәр «Сәйяр» труппасы тарафыннан 1925 елда сәхнәләштерелә. Әмма пьеса матбугатта басылмый кала.

**Аның турында:**

**Мостафин Р.** Олы әдипме, «Кызыл кыңгырау»мы? // Шәһри Казан. — 1998. — 29 апрель.

**Рахмани Р.** Җитмеш елдан соң очрашу // Толымбай Г. Сайланма әсәрләр / Томны төзүче, кереш сүз авторы һәм мөхәррире Рахмани Р. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. — 5–23 б.

## ФАЗЫЛ ТУЙКИН (1887–1938)

Фазыл Кәрим улы Туйкин 1887 елның 22 июнендә Татарстанның хәзерге Лениногорск районы Зәй-Каратай авылында мәзин гаиләсендә дөньяга килә. Җиде яшеннән ятим калып, башта авыл мәдрәсәсендә, соңрак чоры өчен шактый дәрәҗәле саналган «Хәкимия», «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә укый.

1904 елда, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең урта сыйныфын тәмамлаганнан соң, туган авылына кайта һәм 1909 елга кадәр балалар укыта. 1909–1911 елларда Ф.Туйкин Бөгелмә өязенең Ташлы Яр авылында, 1911–1912 елларда Уфада «Хәкимия» мәдрәсәсендә, аннан Бөгелмә өязенең Кәкре Елга авылында мөгаллимлек итә.

1917 елгы Февраль һәм Октябрь инкыйлабларыннан соң да Бөгелмә өязендә укытучылык эшен дәвам иттерә. Ул берничә ел Бөгелмә татар-башкорт укытучылар семинариясендә укыта.

Төрле жанрларда уңышлы иҗат иткән Ф.Туйкинның 4 драма әсәре — «Ватан каһарманы» (1912), «Тормыш корбаннары» һәм балалар өчен язылган «Салих бабай» исемле пьесалары бар. Сәнәкчеләр вәхшәтенә нигезләнеп язылган «Мәгариф корбаннары» исемле сәхнә әсәре авыл сәхнәсендә уйналса да, аның кулъязмасы да, матбугатта басылган варианты да юк. Ә «Ватан каһарманнары» драмасы 1912 елда «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куела.

Ф.Туйкинның Казанда «Сугышчы Сатыш әфәнде» (1912) хикәясе, 1915 елда Уфада «Нардуган» исемле шигырьләр җыентыгы, 1919 елда Оренбургта абыйсы Кәбир Туйкин белән берлектә язган «Төрек тарихы» дигән дәреслеге дөнья күрә. Шулай ук ул халык авыз иҗатын туплауга һәм өйрәнүгә зур өлеш кертә. Мең бер йөз җыр туплаган «Җырлар әхтәрисе» (Казан, 1912), «Җырлар мәҗмугасы» (Уфа, 1914) һәм «Шура», «Безнең юл», «Мәгариф» кебек журналларда күп сандагы мәкаләләре басыла. Ф.Туйкинның кайбер хезмәтләре дөньяга чыкмый кала һәм аларның кайдалыгы да билгесез.

Ф.Туйкинның гомере аянычлы тәмамлана. 1937 елның 1 гыйнвар көнне, Габдрахман авылы мәктәбендә укытканда, милләтчелектә гаепләнеп кулга алына, һәм күп хезмәтләре конфискацияләнә. 1938 елның 15 февраль төнне атып үтерелә. Исеме һәм иҗаты 1958 елның 27 маенда аклана, һәм күпкырлы мирасы мәдәниятебез тарихына кайтарыла.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Туйкин Ф.** Ватан каһарманнары: Тарихи пьеса. — Казан: Сабах, 1912. — 88 б.

**Туйкин Ф.** Тормыш корбаннары: Драма 4 пәрдәдә. — Уфа: Кәримов, 1912. — 50 б.
**Туйкин Ф.** Салих бабай: Балалар сәхнәсе өчен бер пәрдәлек пьеса. — Казан: Татиздат, 1925. — 12 б.
**Туйкин Ф.** Ватан каһарманнары: Тарихи пьеса // Әдәби мирас: Альманах. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 105–147 б.

**Аның турында:**

**Шәрифуллина Э.** Фазыл Туйкин. Әдәби мирас: Альманах. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 102–105 б.
**Галимҗанова Э.** Туйкиннар турында Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты материаллары // Инсани фәннәр: эзләнү һәм табышлар. — Казан, 2004. — 478–482 б.
**Ханнанова-Галимҗанова Э.** «Тарих күреп, эзләп алыр әле...» // Гасырлар авазы. — 2004. — № 1. — 85–92 б.
**Әхмәтҗанов М.** Фольклорчы, әдип һәм педагог Фазыл Туйкин / Әхмәтҗанов М. Дастаннар ватаны. — Казан: Мәгариф. — 1999. —158 б.

## МИРГАЗИЗ УКМАСИ (1884–1946)

Миргазиз Каюм улы Укмаси (Зәбиров) 1884 елның 14 июнендә Татарстанның Балык Бистәсе районы Кече Укмас авылында мулла гаиләсендә туа. Башта үз авылларында башлангыч мәктәптә, аннан Мамадыш өязендәге Иләбәр, Сатыш авыллары мәдрәсәләрендә укый. Соңыннан, Казанга килеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә урнаша. К.Насыйрины күрү бәхетенә ирешә, мәдрәсәдә Ф.Әмирхан, З.Бәшириләр белән аралаша. 1908 елга кадәр шунда укып, бер үк вакытта һөнәр мәктәбенә дә йөреп, столярлык эшенә өйрәнә. Аннары төрле урыннарда мөгаллимлек итә, халык арасында эшли, сугышка алына. Революциядән соң кабат балалар укыта башлый, туган авылында мулла булып тора. 1931 елда М.Укмаси, советка каршы эшчәнлектә гаепләнеп, гаепсезгә кулга алына һәм сигез елга сөргенгә хөкем ителә.

М.Укмасиның яза башлавы 1903 елга туры килә. 1904 елда аның беренче шигырьләр җыентыгы басыла. 1906 елда «Хатирә, яки Дусларыма сүзләрем» китабы, бер елдан «Алданма кызыл алмага» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Поэзиядә ул Тукай шигъри мәктәбе традицияләрен дәвам иттерүче буларак танылa.

Педагогик тәҗрибәсенә таянып, балалар өчен «Алтын таҗ» (1912, 1915) дигән китап бастыра.

Матбугатта әдәбият-тәнкыйть мәкаләләре белән дә чыгышлар ясый.

М.Укмасиның «Наместник урыны өчен көрәш» исемле пьеса язуы мәгълүм. Әлеге әсәр 1917 елда «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәләштерелә.

Төрмәдән азат ителгәч, әдәбият дөньясында ул кабат 1945 елда яңа шигырьләре белән күренеп ала. 1946 елның көзендә Казанда вафат була.

Ул 1945 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Аның турында:**

**Гайнуллин М.** Миргазиз Укмаси (1884–1946) // Гайнуллин М. Татар әдипләре: Иҗат портретлары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. — 172–176 б.
**Мәһдиев М.** Кара тарихтан бер ләүхә: М.Укмасиның тууына 110 ел // Казан утлары. — 1994. — № 12. — 167–170 б.
**Рәми З.** Авыр язмышлы шагыйрь // Татарстан. — 1994. — № 5–6. — 105–110 б.
**Рәмиев З.** Миргазиз Укмаси.Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. — Казан, 2005. — 203–205 б.

## УРАЛЬСКИЙ I (1903–1942)

Уральский I (Насыйбуллин Габдулла Насыйбулла улы) 1903 елда Әстерхан шәһәрендә туа. Сәхнә эшчәнлеген 1917 елда Әстерхан татар театрында башлый. 1920 еллар башыннан 1941 елга кадәр Казанда Татар академия театрында, Әстерхан татар театрларында эшли. Шул ук вакытта режиссер буларак спектакльләр куя, берничә пьеса яза. «Утлы боҗра» исемле драмасы 1929 елда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела.

Сәхнәдә кабатланмас образлар тудырган артист 1940 елда «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исемгә лаек була.

**Аның турында:**

**Илялова И.** Г.Камал театры артистлары: Биографик белешмәлек. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 82–83 б.

## ШАМИЛ
## УСМАНОВ
## (1898–1937)

Шамил Хәйрулла улы Усманов 1898 елның 16 декабрендә Саратов губернасының Кузнецк өязе Пәндәлгә авылында мөгаллим гаиләсендә дөньяга килә. 1906 елда Усмановлар гаиләсе Әстерханга, берничә елдан Оренбургка күченә. Биредә әтиләре Хәйрулла «Хөсәения» мәдрәсәсенә укытучы булып урнаша, ә өлкән уллары Али, Шамил һәм Габдрахман мәдрәсәгә укырга керә. «Хөсәения» урта сыйныфын һәм 1914 елда һөнәр училищесын тәмамлап, Шамил Февраль революциясенә кадәр Акчуриннарның Сембер губернасындагы Гурьевка туку фабрикасында слесарь булып эшли. Февраль революциясен большевистик рухлы егет булып каршылый. Беренче булып фабрикада Кызыл Гвардия отрядын оештыра. Бераздан партия ячейкасы карары белән Ш.Усманов Сызрань тимер юл депосына эшкә җибәрелә. Шул елның җәендә гаскәри хезмәткә алына һәм Октябрь революциясенең беренче көннәреннән үк Идел буенда совет власте урнаштыру эшендә актив катнаша.

1917 елның ноябрендә Ш.Усманов фронтовик солдатлардан һәм Сызрань төбәге эшчеләреннән кызыл отряд төзи һәм Оренбург далаларын Дутов гаскәрләреннән азат итәргә юнәлә. Сызрань партизаннарының беренче пулеметчылар отряды дип аталган бу гаскәр башта Оренбургтагы татар-башкорт батальоны белән, аннары Актүбә шәһәрендәге венгр, поляк һәм немец әсирләреннән оешкан батальон белән берләшә. Шулай «Өченче Интернационал легион» туа. Аның комиссары итеп Ш.Усманов билгеләнә. Әлеге легион Актүбәдән Оренбургка кадәр сугышчан юл уза, Оренбург шәһәрен аклардан азат итә. Усманов үзен батыр көрәшче һәм талантлы командир итеп таныта.

1919 елның мартында Ш.Усманов Казанга кайта һәм яңа төзелә торган Беренче Идел буе татар бригадасының комиссары итеп билгеләнә. Бригада төзүне уңышлы башкарып чыккач, шул ук елның октябрендә ул Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге начальнигы итеп раслана һәм бу хезмәтен коллегия яшәүдән туктаганчы дәвам итә.

Сәләтле оештыручы һәм җитәкче Ш.Усмановка партия яңадан-яңа эшләр йөкли. 1920 елда ТАССР төзелә башлагач, ул республиканың революцион комитеты секретаре итеп билгеләнә. Ә бер елдан Казандагы 16 нчы мөселман пехота командирлары хәзерләү курсларының политбүлек начальнигы, бераздан берләшкән татар-башкорт хәрби мәктәбе комиссары кебек җаваплы эшләр башкара. 1925 елда Усмановка дивизия комиссары дигән хәрби исем бирелә һәм аңа Кызыл Армиянең милли хәрби уку йортлары инспекторы вазифасы йөкләнә.

1925 елның көзеннән 1926 елның августына кадәр Ш.Усманов Мәскәүдә Хәрби академия каршындагы курсларда укый, аннары Ташкентка җибәрелеп, анда Көнчыгышны өйрәнү институтының хәрби курсларында политбүлек начальнигы булып эшли.

1927 елда демобилизацияләнеп кире Казанга кайта һәм, өч елга якын Татарстан тамаша предприятиеләре идарәсе рәисе һәм радиостанция төзү буенча Республика Халык Комиссарлары Советының махсус вәкиле булып эшләгәннән соң, 1930 елдан башлап тулысынча әдәби иҗат эшенә чума.

Ш.Усманов әдәбият мәйданына турыдан-туры гражданнар сугышы кырыннан килеп керә. Аның тәүге әсәре — «Канлы көннәрдә» драмасы — 1919 елның салкын кышында Оренбург далаларында барган көрәш эчендә языла. Әлеге пьеса революция һәм гражданнар сугышы турында татар драматургиясендә беренче әсәр булып санала. Бу драманы кызылармеецлар кулдан-кулга күчереп яза, һәм ул хәрби сәхнәләрдә уйнала. Беренче уңыштан канатланып, Ш.Усманов шул ук елда рус һәм та-

тар эшчеләренең дуслыгын яктырткан «Беренче адым» драмасын иҗат итә. Әлеге пьеса да театрларда, клубларда йөзләрчә мәртәбә куела һәм зур уңыш белән бара.

Егерменче елларда Ш.Усмановның көрәш һәм мәхәббәт темасын яктырткан «Бай кызы» (1922) драмасы дөнья күрә һәм шул ук елда татар театры сәхнәсендә уйнала. Иҗат эшчәнлеге «Кичеккән фәрман» (1932) пьесасы белән төгәлләнә. Автор аны русчага тәрҗемә итә һәм Мәскәүгә иң яхшы пьесаларга үткәрелгән конкурска җибәрә. Бөтенсоюз конкурсында махсус билгеләнеп, «Страна родная» исеме астында 1000 данәдә бастырыла һәм төрле театрларга таратыла. 1934–1935 елларда ул Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уңыш белән бара.

«Кичеккән фәрман» пьесасын Татар дәүләт академия театры сәхнәсенә режиссер Гали Ильясов куя. Пьесаның иң җаваплы ролен Татарстанның һәм РСФСРның халык артисты Хөсәен Уразиков башкара. Спектакль тамашачы тарафыннан яратып кабул ителә һәм үз иҗатына таләпчән автор да канәгать кала.

Ш.Усманов проза жанрында да актив иҗат итә. Драма әсәрләрендәге кебек, хикәя һәм повестьларында да революция һәм гражданнар сугышы темасы яктыртыла («Ил кызы» (1923), «Краском мәхәббәте» (1923), «Өч снаряд» (1927), «Гает корбаны» һ.б.). Бер төркем хикәяләрендә («Эшче кызы Нина» (1922), «Фабрика анасы» (1926), «Ачылган йозак» һ.б.) революциягә кадәрге эшчеләр тормышы сурәтләнә, геройны психологик яктан ачуга омтылыш ясала.

Ш.Усманов татар әдәбияты тарихына татар-мадьяр легионерларының батырлыгын тасвирлаган «Легион юлы» (1935) исемле дилогиясен һәм заманында күп телләргә тәрҗемә ителгән «Памирдан радио» (1925) дигән фантастик повестен язып калдыра.

Ш.Усмановның гомере, шәхес культы корбаны буларак, 1937 елның 3 декабрендә Казан Кремле төрмәсендә өзелә.

Ул 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Усманов Ш.** Канлы көннәрдә: 3 пәрдәлек инкыйлабый пьеса. — Казан: Мәркәз мөселман хәрби һәйәт нәшере, 1919. — 32 б.

**Усманов Ш.** Беренче адым: Пьеса 3 пәрдәдә. — Казан: Мәркәз мөселман һәйәте хозурындагы сәяси шөгъбәнең нәшере, 1920. — 88 б.

**Усманов Ш.** Бай кызы: Пьеса 4 пәрдәдә. — Казан: Татпечать, 1923. — 63 б.

**Усманов Ш.** Сайланма әсәрләр: Повестьлар, хикәяләр, пьесалар / А.Гумеров кереш сүзе белән. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1958. — 662 б.

**Усманов Ш.** Сайланма әсәрләр: Повестьлар, хикәяләр, пьеса. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1964. — 504 б.

**Усманов Ш.** Кичеккән фәрман: Повесть һәм пьеса. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 272 б.

**Усманов Ш.** Страна родная: Пьеса в 6 картинах / Пер. с татар. автора. Пьеса рекомендована к постановке жюри первого Всесоюзного конкурса на лучшие пьесы. — М.: ЦБРДП, 1935. — С. 47.

**Усманов Ш**. Запоздалый приказ (Страна родная): Пьеса в 7 эпизодах. — М.: Художник лит., 1936. — С. 115.

**Аның турында:**

**Яхин А.** Шамил Усманов драматургиясе. — Казан: Таткнигоиздат, 1959. — 30 б.

**Яхин А.** Ш.Усманов (1898–1938): Ш.Усмановның тормышы һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге турында документ. очерк. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1963. — 40 б.

**Мусин Ф.** Шамил Усманов // Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. — 4 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 225–238 б.

**Гыйззәтуллин Н.** Язучы-каһарман: Шамил Усмановның тууына 100 ел // Казан утлары. — 1998. — № 12. — 158–163 б.

**Әхмәдуллин А.** Ш.Усманов драматургиясендә герой проблемасы / Әхмәдуллин А. Дөреслеккә ирешү юлында. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1993. — 234–242 б.

## ӘХМӘТ ФӘЙЗИ (1903–1958)

Әхмәт Фәйзи (Әхмәт Әхмәтсафа улы Фәйзуллин) 1903 елның 11 мартында Уфа шәһәрендә туа. Башта мәдрәсәдә, аннары рус-татар мәктәбендә һәм революциядән соң татар гимназиясендә белем

ала. Укыган елларында ук үзенең өйрәнчек шигырьләрен һәм пьесаларын яза. Шундыйлардан берсе — «Матурлык дөньясында» (1902) исемле бер пәрдәлек комедиясе — Уфа, Оренбург сәхнәләрендә куела, соңыннан әдипнең томнарына да кертелә.

Мәктәпне тәмамлагач, Ә.Фәйзине Оренбургтагы Шәрекъ институтына укырга җибәрәләр. Шунда ул яшь татар язучылары түгәрәге эшендә актив катнаша, Муса Җәлил белән очраша һәм дуслаша. Ләкин 1921–1922 еллардагы ачлык Әхмәт Фәйзигә институтны тәмамларга мөмкинлек бирми, укуын ташлап, ул Урта Азиягә китәргә мәҗбүр була; 1924 елга кадәр Төркмәнстан кышлакларында һәм шәһәрләрендә укытучы, һәвәскәр артист булып йөри. 1924 елдан Уфада, берничә ел Донбасста татарлар арасында укыту һәм культура-агарту эшләре алып бара. Мәскәү, Казан шәһәрләрендә, Татарстанның Арча төбәгендә матбугат һәм мәгариф системаларында эшли. 1931 елда ул Мәскәүгә күчә һәм гомерен профессиональ язучылык хезмәтенә багышлый.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Әхмәт Фәйзи Мәскәүдәге Әдәбият институтының өченче курсыннан үзе теләп фронтка китә һәм хәрби корреспондент булып хезмәт итә.

Әхмәт Фәйзинең иҗат уңышлары беренче чиратта шигърият белән бәйле. Аның лирик шигырьләре шул чор кешеләренең рух-омтылышларын чагылдыра. Ил һәм халык тормышын гәүдәләндергән «Флейталар» (1933), «Дала һәм кеше» (1933), «Кара таш ник дәшми» (1940), «Туу сулышы» (1943) поэма һәм балладалары татар поэзиясенең үсеш тарихында урын алдылар.

Язучының ике китап итеп уйланылган «Тукай» роман-эпопеясы аның иҗатында гына түгел, гомумән татар әдәбиятында аеруча күренекле урын алып тора. Бу романы өчен Әхмәт Фәйзи 1958 елда, язучылардан беренче буларак, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнә.

1973 елны басылып чыккан «Әдипнең эрудициясе» җыентыгы аның әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть, публицистика өлкәсендә калдырган, әһәмиятен югалтмаган мирасы булды.

Әдипнең тормышы үсмер елларыннан ук мәгариф һәм мәдәният белән бәйле сукмаклардан башлана, иҗатында да ул иҗтимагый тормышта кайнап яшәгән күпкырлы талант булып формалаша. Иҗат юлы аны табигый рәвештә драматургия белән бәйли, драматургиянең мәркәзе булган театр дөньясына алып килә. Ул «Каеннар яфрак ярганда», «Беренче елмаю», «Шәмгун Тавысов», «Гөлшаян», «Төтен», «Түрәкәй» комедияләрен, «Тукай», «Пугачев Казанда» драмаларын иҗат итә.

Әхмәт Фәйзи үзен чынлап та киң эрудицияле әдип итеп таныта: театр сәнгатенең опера, балет, музыкаль комедия төрләрендә танылган композиторлар белән берлектә үлемсез әсәрләр иҗат итә. 1939 елда Татар дәүләт опера һәм балет театры үзенең беренче сезонын Нәҗип Җиһановның Әхмәт Фәйзи либреттосына язган «Качкын» операсы белән ачып җибәрә. Опера Казан, Мәскәү, Ленинград театрларында зур уңыш белән бара, Франция, Канада кебек чит ил сәхнәләрендә дә куела. «Җәлил» (композиторы — Н.Җиһанов) операсына язылган либретто да язучының исемен күп илләргә, халыкларга танытты. Композитор Рәшит Гобәйдуллин белән берлектә иҗат ителгән «Кисекбаш» балеты Әхмәт Фәйзине Тукай иҗаты белән бәйләп торган салават күпере булды.

Сугыш чорында иҗат ителгән «Акчарлаклар» музыкаль комедиясен (композиторы — Җәүдәт Фәйзи) ул берничә вариантта эшли, әсәрдән музыкаль өзекләр әле дә башкарыла. Сугыштан соңгы елларда язылган «Отышлы кияү» (1947), «Күршеләр» (1951), «Сәйдә апа» (1955) комедияләре актерлар тарафыннан яратып уйнала.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Ә.Фәйзинең «Тукай» (1939, 1942, 1961), «Пугачев Казанда» (1948), «Рәүфә» (1958) драмалары һәм «Гөлшаян» (1958) комедиясе куела.

Ә.Фәйзи 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Фәйзи Ә.** Качкын: 3 актта. Опера либреттосының әдәби варианты. — Казан: Татгосиздат, 1939. — 31 б.
**Фәйзи Ә.** Тукай: Тарихи драма. — Казан: Татгосиздат, 1943. — 136 б.
**Фәйзи Ә.** Пугачев Казанда: Тарихи драма. — Казан: Татгосиздат, 1951. — 63 б.
**Фәйзи Ә.** Әсәрләр: 3 томда. — 3 т.: Либреттолар һәм пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1966. — 463 б.
**Файзи А.** Шурале (Батыр): Балет в 3 д., 4 карт. — Л.: Театр оперы и балета им.Кирова, 1955. — С. 15.
**Файзи А.** «Джалиль» Н.Г.Жиганова (опера-поэма в 7 карт. Либретто А.Файзи). — М.: Музгиз, 1960. — С. 77.

**Аның турында:**

**Хөсни Ф.** Әхмәт Фәйзи — драматург // Хөсни Ф. Ни әйтергә? Ничек әйтергә? — Казан, 1974. — 171–179 б.
**Хәйруллина З.** Музыкадан аерылгысыз шагыйрь // Социалистик Татарстан. — 1978. — 16 март.
**Усманов З.** Ахмед Файзи // Театральный календарь. — 1978. — Л., 1977. — С. 33–34.

## МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ (1891–1928)

Татар драматургиясен яңа үрләргә алып менгән Мирхәйдәр Фәйзи (Мирхәйдәр Мостафа улы Фәйзуллин) 1891 елның 1 ноябрендә Оренбург губернасының Орск өязе Күкшел авылында мул тормышлы ишле гаиләдә туа. Сигез-тугыз яшеннән абыстайга йөреп һәм өйдәге апа-абыйлары ярдәмендә укырга-язарга өйрәнә. 1902–1904 елларда Орск мәдрәсәсендә белем ала, аннары Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә кереп укый. Биредә ул К.Насыйри әсәрләре, Г.Тукай, М.Гафури поэзиясе белән таныша, төрки һәм фарсы телендә язылган китаплар укый. Матур әдәбиятка мәхәббәте уянып, үзе дә шигырьләр, бәетләр һәм «Татар туе» (1905) исемле беренче пьесасын яза. Болардан тыш шушы ук елларда Оренбургтагы «Чүкеч» журналында һәм Казандагы «Әльислах» газетасында мәдрәсә тәртипләрен тәнкыйтьләгән берничә мәкаләсе басыла.

Авыру сәбәпле, М.Фәйзигә «Хөсәения» мәдрәсәсен ташларга туры килә. Шуннан соң ул кышларын Орскида — атасы йортында, җәйләрен Күкшел һәм Юнәй авылларында яши. Бер үк вакытта үзлегеннән укуын дәвам итә һәм Орск шәһәре татар яшьләренең мәдәни хәрәкәтендә актив катнаша, андагы һәвәскәр драма түгәрәген оештыручылардан берсе була. Бу түгәрәк өчен, русчадан файдаланып, «Ике Хәсән» (1909), «Чәчәкләр арасында» (1912) исемле пьесаларын һәм «Бизәнү» (1911), «Яшьләр алдатмыйлар» (1911) дигән оригиналь комедияләрен яза.

1910 елдан соң М.Фәйзинең матбугатта бер-бер артлы шигырьләре басыла башлый. Мәхәббәтне һәм табигатьне данлаган лирик шигырьләре, бергә тупланып, «Минем шигырьләрем» (1912) һәм «Яшь күңел» (1913) исемендә дөнья күрә.

1912–1916 елларда М.Фәйзи башта Орск шәһәрендә мануфактура кибетендә кассир, соңыннан шул төбәктәге авылларда китапханәче булып эшли. Аның бу чорда «Кызганыч» (1913), «Тәкъдирнең шаяруы» (1913) исемле романтик драмалары языла. Заманның яңа фикерле мөгаллимнәрен, милләтпәрвәр сәүдәгәрләрен беренче планга куеп, М.Фәйзи бәхетсезлекнең сәбәбен язмыш, тәкъдир фәлсәфәсенә бәйләп аңлата. Бу пьесалар үткен тел, әдәби осталык белән язылган. Аларда авторның драматургия өчен кирәкле кискен конфликт, мавыктыргыч сюжет һәм үзәк вакыйга кора алу таланты ачык күренә. М.Фәйзинең «Кызганыч» драмасын «Нур» труппасы 1918 елда сәхнәгә куя.

1913–1915 елларда драматург иҗатында фольклор эстетикасына борылыш ясала. Ул авыл халкының көнкүрешен тирәнтен өйрәнә, этнографик күзәтүләр ясый, халык иҗаты материалларын җыя, җырлар анализлый һәм аларны әсәрләренә алып керә. Шуның матур үрнәге буларак, халык иҗаты җәүһәрләренә нигезләнгән «Авыл бәйрәме» (1914) музыкаль комедиясе туа.

1916 елда М.Фәйзи үзенең иҗатында гына түгел, гомумән бөтен татар драматургиясендә иң камил, иң халыкчан әсәрләрнең берсе булган мәшһүр «Галиябану» («Сәгадәтбану») драмасын иҗат итә. Әсәр беренче тапкыр 1917 елның 19 мартында Оренбургтагы «Нур» труппасы тарафыннан сәхнәдә уйнала һәм зур уңыш казана. Шуннан аның бүгенгә кадәр дәвам иткән озын гомерле сәхнә тормышы башлана.

«Галиябану» драмасына төп тема итеп дөнья әдәбиятында мәңгелек дип исәпләнгән тема — ике яшь йөрәкнең саф мәхәббәте һәм бу мәхәббәтнең тормыш шартларында фаҗигале язмышын күрсәтү алынган. Драматург тормышчан сюжет һәм драматик коллизия төзү остасы икәнен раслый. Романтизм эстетикасына хас романтик сызык, традицион романтик-символик образлар, җыр, музыка, сәнгать культы, романтик шартлылык драманың тамашачыга тәэсир итү көчен тагы да көчәйтә.

«Галиябану» драмасы беренче буларак сәхнәгә җыр-музыка алып менә һәм татар сәнгатендә яңа бер жанрга — музыкаль драма жанрына нигез сала. Гомумән, бу әсәр дөнья классикасының җәүһәрләре янәшәсендә мәхәббәтнең көчен, кешелек яшәгәндә, аның мәңге яшәячәген раслаучы драма булып тора.

Октябрь революциясеннән соң, сәламәтлеге начар булуга карамастан, М.Фәйзи башта туган якларында, ә 1919–1921 елларда Башкортстанның Бөрҗән-Тангаур кантоны Юлык исемле татар авылында культура-агарту эшләре алып бара, ахырда кантон үзәге Тимәстә драмтүгәрәк режиссеры

һәм «Кызыл Урал» газетасы хезмәткәре вазифаларын башкара. 1923 елда М.Фәйзи бераз вакыт Казанда Үзәк шәрекъ китапханәсенең балалар бүлегенә җитәкчелек итә, аннары, докторлар кушуы буенча, яңадан Башкортстанга кайтып, Тубинск руднигы эшчеләре клубы китапханәсендә, аннары Баймак китапханәсендә мөдир булып эшли.

Октябрь революциясеннән соң да драматург «Урал суы буенда» (1918), «Ак калфак» (1922), «Асылъяр» (1920), «Адашкан күңел» (1923) кебек дистәгә якын романтик эчтәлекле сәхнә әсәрләре язып калдыра. Шулардан «Ак калфак», «Асылъяр» 1924–1925 елларда «Сәйяр» театры артистлары тарафыннан тамашачыга җиткерелә. Гомумән, кыска гына иҗат гомерендә М.Фәйзи уналты оригиналь пьеса, берничә хикәя, ике йөзгә якын шигырь язып өлгерә, рус теленнән җиде сәхнә әсәре тәрҗемә итә, күп кенә фольклор материаллары җыеп бастыра. 1912–1927 еллар аралыгында ул 68 дәфтәрдән торган көндәлекләр яза.

### Басылган драма әсәрләре:

**Фәйзи М.** Сайланма әсәрләр: 2 томда. — 1 т. / Төз. Ф.Фәйзуллина. — Казан: Таткнигоиздат, 1956. — 403 б.

**Фәйзи М.** Сайланма әсәрләр: 2 томда. — 2 т. / Төз. Ф.Фәйзуллина. — Казан: Таткнигоиздат, 1957. — 464 б.

**Фәйзи М.** Сайланма әсәрләр / Төз. һәм кереш сүз авт. Ф.Фәйзуллина. — Казан: Хәтер, 2005. — 205 б.

Татар классик драматургиясе: Галиәсгар Камал. Мирхәйдәр Фәйзи / Төз. һәм кереш сүз авт. Ф.Ә.Ганиева. — Казан: ТаРИХ, 2004. — 5–28 б.

### Аның турында:

**Гайнуллин М., Вәзиева Җ.** Мирхәйдәр Фәйзи. Тормышы һәм иҗаты / Гайнуллин М., Вәзиева Җ. Татар әдәбияты. XX йөз. — Казан: Таткнигоиздат, 1954. — 1 нче кисәк. — 339–357 б.

**Әхмәдуллин А.** Аның сәнгатьчә ачышлары // Әхмәдуллин А. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — 141–146 б.

**Ханзафаров Н.** Мирхәйдәр Фәйзи / Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. — 3 т. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 421–435 б.

**Ханзафаров Н.** Мирхәйдәр Фәйзи / Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. — 4 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 259–270 б.

**Нуриев Р.** «Галиябану» драмасының поэтикасы // Нуриев Р. Татар классик драматургиясенең поэтикасы. — Казан, 1999. — 161–174 б.

**Хәмидуллин Л.** Әсәрләре гасырлар кичә / Хәмидуллин Л. Ак төннәр хәтере. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 107–117 б.

## НУРИХАН
## ФӘТТАХ
## (1928–2004)

Нурихан Садрилмән улы Фәттахов 1928 елның 25 октябрендә Башкортстанның Яңавыл районы Күчтавыл дигән татар авылында туа. Яңавыл урта мәктәбен тәмамлагач, 1946–1951 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Аннан соң Татарстан китап нәшриятында редактор, Чистай шәһәрендә өлкә газетасы редакциясендә тәрҗемәче булып эшли. 1953 елда Казанга кайта һәм тулысынча әдәби иҗатка — профессиональ язучылык эшенә күчә.

Мәктәптә укыган елларында ук шигырьләр, хикәяләр яза башлаган Нурихан Фәттах язучы буларак «Сезнеңчә ничек?» (1955) романы белән танылa. Алтмышынчы елларда «Бала күңеле далада» романы, «Мөдир Саҗидә» повесте языла. Аның татар әдәбиятындагы төп урынын һәм дәрәҗәсен, әлбәттә, гаять үзенчәлекле, чын тарихи материалларга нигезләнеп, югары сәнгать дәрәҗәсендә иҗат ителгән «Ител суы ака торур» (1970), «Сызгыра торган уклар» (1977) исемле тарихи романнары билгели.

Драматургия өлкәсендә дә ул, ерак тарихка мөрәҗәгать итеп, татар халкы өчен аеруча кадерле булган шәхес һәм вакыйгаларны тергезгән талантлы әсәрләре белән урын алды. Аның «Кол Гали» пьесасы (1972) Болгар дәүләте, болгар шагыйре язмышын тасвирлый, 1220–1230 елларны гәүдәләндерә. Әдәби әсәр буларак та яратылып укыла, трагедия жанрының да камил бер үрнәге булып тора. «Кол Гали» трагедиясе Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында иң танылган актерлар башкаруында куелды.

Нурихан Фәттахның тагын бер әсәре — «Сармат кызы Сәринә» (1986) тарихи драмасы — 2200 ел элек Кара диңгез буе далаларында яшәгән борынгы күчмә кабиләләр тормышын чагылдыра һәм кискен конфликтларга корылган чын сәнгать әсәре булып тора.

Нурихан Фәттах балалар әдәбияты өлкәсендә дә яратып иҗат итә: балалар өчен язылган хикәяләр җыентыкларын («Тегермәндә», «Өч туган», «Ирек, Алмас һәм Җәлил») бастырып чыгара. Аның «Энҗеле үрдәк», «Кызлар тавының сере» исемле әкият-пьесалары, Казан курчак театры сәхнәсендә 1973–1975 елларда куелып, нәни тамашачыларның мәхәббәтен казанды.

Татар әдәбиятын үстерүгә куйган хезмәтләре өчен Нурихан Фәттах «РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек булды (1979). 1991 елда аңа Президент указы белән «Татарстанның халык язучысы» дигән дәрәҗәле исем бирелде. 1994 елда ул Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты булды.

Н.Фәттах 1965 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Фәттах Н.** Кол Гали: Трагедия 3 пәрдәдә // Сайланма әсәрләр: 5 томда. — 3 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 386–418 б.

**Фәттах Н.** Сармат кызы Сәринә: Тарихи драма // Сайланма әсәрләр: 5 томда. — 3 т. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 418–463 б.

**Фәттах Н.** Энҗеле үрдәк: Әкият-пьеса. Серле алан. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 176 б.

**Аның турында:**

**Мәхмүтов Һ.** «Кол Гали» трагедиясе Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә // Социалистик Татарстан. — 1974. — 18 апрель.

**Әминов Ю.** Бүгенге драматургиябез турында кайбер фикерләр // Казан утлары. — 1975. — № 10. — 162–170 б. («Кол Гали» трагедиясе турында 158–159 б.)

**Рәхмәтҗан Р.** Бу спектакль безгә тәс түгелмени? [К.Тинчурин ис. драма һәм комедия театрында премьера: «Итил суы ака торур» романы сәхнәләштерелгән] // Шәһри Казан. — 1994. — 5 февраль.

**Сафиуллин Ә.** Хан иттеләр!: Язучы Н.Фәттахның 75 еллыгы уңаеннан узган кичә турында // Ватаным Татарстан. — 2003. — 19 ноябрь.

## ШАМИЛ ФӘХРЕТДИНОВ (1971)

Шамил Тимергали улы Фәхретдинов 1971 елның 18 февралендә Татарстанның Аксубай районы Яңа Ибрай авылында туа. Гаиләдә алты бала арасында әтисенең, туганнарының кайгыртуын, хезмәт сөючәнлекләрен күреп үсә. Үзе дә, мәктәптә укыганда ук, балта остасы булган әтисенә йортлар салганда булышып йөри. Әтисе, һөнәрле булу өстенә, әдәби әсәрләр, газета-журналлар укырга, җыярга ярата. Улына М.Мәһдиев әсәрләрен биреп, аның күңелендә дә әдәбиятка, сәнгатькә мәхәббәт уята. Мәктәптәге драма түгәрәгенә актив катнашу, «рольләренең» уңышлы чыгуы аның күңелен күтәрә, сәләтен үстерә.

Мәктәпне тәмамлагач, Шамил Фәхретдинов, бер дә икеләнмичә, Казанга килә һәм 1989–1993 елларда Казан театр училищесында укый, остазы талантлы актер һәм педагог Шамил Бариев була. Училищены кызыл диплом белән тәмамлап, яшь актер К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында эшли башлый. Ул башкарган рольләр — Э.Яһудинның «Мәхәббәткә мәдхия» әсәрендә — Эдгар, Х.Вахитның «Кияүләр» әсәрендә — Барлас, «Туй алдыннан»да — Марат, Г.Зәйнашеваның «Җаным җәл түгел сиңа» әсәрендә — Равил, төрки халыклар фестивалендә «Иң яхшы ирләр роле» өчен беренче урынны алган Надир мәхдүм (К.Тинчурин. Сүнгән йолдызлар) — Шамил Фәхретдиновның гаять эш сөючән, тынгысыз һәм эзләнүчән шәхес икәнлеген раслыйлар.

Училищеда укыган вакытта ук ул юмористик хикәяләр яза һәм матбугат битләрендә күренә башлый. Үз алдына язучы булу максатын куймаса да, театрдагы эшчәнлеге (ул актерлык хезмәтеннән тыш әдәби бүлек мөдире вазифаларын да башкара) һәм табигый сәләте аны драматургия өлкәсенә алып килә. К.Тинчурин исемендәге театрның 60 еллык юбилее уңаеннан балалар өчен пьесалар язу максаты куела. Утыздан артык роль уйнап, сәхнә тәҗрибәсен туплаган Шамил Фәхретдинов драма-

тургия законнарын да махсус рәвештә өйрәнә һәм әсәрдән әсәргә аның каләме дә чарлана, иҗат темпы да җитезләнә бара. Ул дистәдән артык драма әсәре яза, берничә пьеса тәрҗемә итә, һәм алар барысы да Татар дәүләт драма һәм комедия театрында, Түбән Кама театрында, Татарстан дәүләт телевидениесендә куелдылар. «Әкият турында әкият», «Алтын алма», «Йолдызлы яңгыр», «Мыгырдык», «Али баба һәм өч карак», «Ала карга хәйләсе», «Шифалы су», «Саламторхан яки бәхетле гаилә», «Әптери солдат маҗаралары», «Тылсымлы чыршы» әкиятләре халык иҗаты стилен дә саклаганнар, балалар хыялын канатландырырлык серле дә, мәрхәмәтлеләр дә. Тәрҗемә иткән әсәрләре дә, таныш әсәрләр булсалар да, бүгенге тамашачы күзаллавына якынайтылганнар: «Могҗизадан соң» (У.Гибсон. После чуда), «Кояш төшмәгән җирдә» (М.Горький. На дне), «Кыю Вәсилә һәм убырлы карчык» (Е.Шварц. Два клена).

2003 елда Шамил Фәхретдиновка «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Фәхретдинов Ш.** Әкият турында әкият: Әкият-пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 240 б.

**Аның турында:**

**Мөхәммәтов Р.** Исмәгыйль белән Мәхдүм // Ватаным Татарстан. — 2000. — 28 гыйнвар.
«Угасшие звезды» принесли победу: приза за лучшую мужскую роль на международном фестивале тюркоязычных театров удостоен Ш.Фахретдинов // Вечерняя Казань. — 2000. — 9 июня.
**Гыйматдинова Н.** Кемгә уен, кемгә яшәү // Идел. — 2000. — № 10.
**Хәйруллина Л.** «Мин реалист хыялый…» // Татарстан яшьләре. — 2003. — 27 сентябрь.
**Хәмидуллина Р.** Балачактан сәхнәгә сихерләнгән: К.Тинчурин ис. театр артисты Ш.Фәхретдинов // Шәһри Казан. — 2001. — 26 октябрь.
**Иванечева О.** Цветок счастья растет в душе каждого // Казанские ведомости. — 2001. — 18 ноябрь.
**Зиганшина А.** Огонь бичующей сатиры // Вечерняя Казань. — 2003. — 1 октябрь.
Творчество Ш.Фахретдинова // Гордость города Казани. — М.: Авангард, 2005. — С. 208–209.

## ФАТИХ ХАЛИДИ (1850–1923)

Фатих Халиди 1850 елда Казан губернасы Тәтеш өязе (хәзерге Татарстанның Кама Тамагы районы) Яңа Сала авылында мулла гаиләсендә туа. Атасы Хаммат мулла Фатихка бер яшь вакытта Казанга күчеп килә һәм шәһәрнең бер мәхәлләсендә мулла, мөдәррис булып тора. Фатих башта атасы карамагындагы, соңрак Кышкар мәдрәсәсендә укый. Үзлегеннән рус телен өйрәнә. Берничә ел сату эше белән шөгыльләнгәннән соң, гомеренең иң күп өлешен язучылык эшенә багышлый.

Ф.Халиди, сәхнә әсәрләре язудан тыш, 1893 елда татар телендә беренче стена календаре чыгара. Календарьларда халыкны әдәбиятка кызыксындырырлык фантастик әкиятләр, кечкенә хикәяләр туплана. 1899 елда «25 еллык адресный календарь» исемле өстәл календаре да бастыра. 130 битле журнал форматындагы календарьда Казан һәм Болгар, тел һәм әдәбият, мәдәният һәм мәгариф учаклары тарихына кагылышлы бай мәгълүмат урнаштырыла.

1888 елдан 1910 елга кадәрге чорда Ф.Халиди 11 исемдә 18 китап яза һәм тәрҗемә итә. Матур әдәбият өлкәсендә драма һәм хикәят жанрларында көчен сыный. Татар әдәбияты тарихында икенче драма әсәре булган «Рәдде бичара кыз» (1888) төп проблемасы ягыннан Г.Ильясиның «Бичара кыз» (1887) пьесасына якын. Ф.Халиди дә, Г.Ильяси кебек, байлыкка караганда укыган кешене югары күтәрә, хатын-кыз хокукын яклый. Әсәрдә Ф.Халиди икенче мәсьәләне — матурлыкның байлыктан өстенлеген дә яктырта. Беренче тәҗрибәләр булганлыктан, «Рәдде бичара кыз», драма әсәре буларак, йомшак эшләнгән: вакыйгалар тиешле тирәнлектә бармый, образларның күбесе схематик. Драма теленең халыкчанлыгы, диалогларның җыйнаклыгы пьеса эшләнешендәге уңай сыйфатлар булып торалар.

1904–1906 елларда Ф.Халиди тагын дүрт драма әсәре яза. Болардан «Морат Сәлимов» (1905) һәм «Мәхрүсә ханым» (1906) исемле әсәрләрендә наданлык тәнкыйтьләнә, гыйлемнең байлыктан өс-

тенлеге пропагандалана, мәдәни тормышка чакырыла. Ф.Халиди соңгы драмаларын француз әдәбияты йогынтысында яшәгән төрек әдәбияты тәэсирендә яза. Ике әсәр дә сәхнәгә куела.

«Морат Сәлимов» драмасы 1907 елның 3 апрелендә Оренбург сәхнәсендә яңа оешып килгән «Сәйяр» труппасының беренче спектакле булып уйнала.

Фатих Халиди — XIX йөзнең соңгы чирегендә әдәбият мәйданына килеп, К.Насыйри, З.Бигиевләр белән бергә татарлар арасында аң-белем таратуда, яңа әдәбият булдыру юлында актив эшләүчеләрдән. Ул, Көнчыгыш әдәбияты традицияләрен һәм рус мәдәниятеннән файдаланып, киң массага аңлаешлы әдәби әсәрләр язуда, татар әдәби телен халыклаштыруда зур хезмәт куя.

**Басылган драма әсәрләре:**


**Халиди Ф.** Рәдде бичара кыз: Драма. — Казан: Вячеслав, 1888. — 21 б.

**Халиди Ф.** Мәхрүсә ханым: Драма. — Казан, 1906. — 48 б.

**Халиди Ф.** Морат Сәлимов: Драма. — Казан, 1905. — 40 б.

**Халиди Ф**. Рәдде бичара кыз. Морат Сәлимов // Гайнуллин М. Татар әдәбияты. XIX йөз. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1968. — 556–585 б.


**Аның турында:**


**Гайнуллин М.** Фатих Халиди // Гайнуллин М. Татар әдәбияты. XIX йөз. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1968. — 548–556 б.

**Халидов Ә.** Мәгърифәтче әдипләребездән берсе // Мирас. — 1993. — № 4. — 48–50 б.

**Мөхәммәтшин З.** Фатих Халидинең иҗат мирасы. — Казан: Таң — Заря, 2001. — 160 б.

**Әхмәдуллин А.** Фатих Халиди турында берничә сүз // Әхмәдуллин А. Офыклар киңәйгәндә. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 26–27 б.


## ЗӨЛФӘТ ХӘКИМ (1960)

Зөлфәт Хәким (Хәкимханов Зөлфәт Зөфәр улы) 1960 елның 11 августында Татарстанның Түбән Кама районы Шәңгәлче авылында туа. Үз авылындагы мәктәпне тәмамлагач, армиядә хезмәт итә, соңыннан Казан химия-технология институтында читтән торып укый.

З.Хәким, сәнгатькә һәм әдәбиятка 1980 елларда килеп, үзен талантлы, кыю фикерле, кабатланмас әсәрләр иҗат итүче көчле шәхес итеп танытты. Мәдәният өлкәсендә ул шагыйрь, композитор, драматург, проза остасы буларак мәгълүм. Әдипнең «Апрельдә кар ява», «Газап», «Татар иле», «Ни булды сиңа бүген?», «Җырларым-хыялларым», «Газиз халкым», «Казан — кала», «Сине югалтсам...» һ.б. җырлары халыкның яраткан җырларына әйләнде.

З.Хәкимнең «Агымсуда ни булмас», «Курку» һ.б. повестьлары, «Мәгънәсез низаг» (1991), «Чын ярату» (1991), «Котлы булсын туегыз!» (1991), «Гонорар» (1994) һ.б. күпсанлы хикәяләре һәм монологлары да дөнья күрде.

Авторның 1995–1996 елларда иҗат ителгән «Гөнаһ» исемле романы тирән фәлсәфилеккә, психологизмга корылган булуы белән башка әсәрләрдән аерылып торды. Әлеге роман татар прозасының казанышы булды. Ул, автор тарафыннан рус теленә тәрҗемә ителеп, «Трясина» исемендә нәшер ителде.

З.Хәкимнең әсәрләре тәнкыйть, укучы, тамашачы тарафыннан югары бәяләнде. Аның Идел буе Болгар дәүләте тарихына багышланган «Мәңгелеккә изге сәфәр» (1995–1996) пьеса-кыйссасы, тормышыбызның иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга багышланган, тоталитар системаның асылын ачкан «Җүләрләр йорты» (1995) трагикомедиясе, халыкның тормыш-көнкүрешен тасвирлаган «Карак» (1994), «Зәхмәт» (1994), «Үтермә» (1996), «Килә ява, килә ява» (1997), «Мин төш күрдем» (2001), «Чапты атым Казанга» (2002) һ.б. пьесалары яңа форма, стиль, образлар системасы белән аерылалар.

Драматургның дөньяны яңача кабул итүе, аның субъектив карашлары «Җен бутады» (1991), «Шайтан куентыгы» (1999) трагедиясендә, «Мин сине яратам!» (1998) мелодрамасында, «Арабызда сәер сызыклар» (1998) музыкаль драмасында һ.б. чагыла. Әдипнең яшәеш, рухи кыйммәтләр, чын

сөю кебек төшенчәләр турындагы фәлсәфи уйланулары пьесаларда фантастик уйдырма, символик һәм метафорик образлар, абсурд театр элементлары, тормыштан читләшкән герой һ.б. алымнар аша җиткерелә.

Көчле сатира, үткен юмор, ирония, сарказм аша драматург «Кишер басуы» (1991–1993), «Күрәзәче» (1996–1997) трагикомедияләрендә җитди иҗтимагый проблемаларны күтәрә.

З.Хәким пьесалары, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелып, зур уңыш белән бара. 1990–2006 еллар арасында драматургның «Су төбендә сөйгәнем», «Кишер басуы», «Карак», «Җуләрләр йорты», «Күрәзәче», «Килә ява, килә ява», «Мин төш күрдем», «Ява карлар, ява карлар», «Чапты атым Казанга», «Телсез Күке», «Бит» пьесалары сәхнәләштерелде. Әдипнең драма әсәрләре, шулай ук Минзәлә, Чаллы, Оренбург, Әлмәт, Башкортстан һ.б. театрларда уйналып, халык күңелен яулап алдылар.

З.Хәким — тирән фәлсәфи эчтәлекле мәкаләләр һәм афоризмнар авторы да.

2003 елда татар драматургиясен һәм театр сәнгатен үстерү максаты белән Татарстан күләмендә үткәрелгән «Яңа татар пьесасы» бәйгесендә З.Хәкимнең «Телсез Күке» драмасы беренче урынны яулап алды. Шулай ук драматургның «Бит» пьесасы да махсус бүләккә лаек булды.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Хәким З.** Сайланма әсәрләр: 3 томда. — 3 т.: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. — 335 б.

**Хәким З.** Мин төш күрдем...: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. — 366 б.

**Хәким З.** Телсез Күке // Яңа татар пьесасы: 3 томда. — 1 т. — Казан: Идел-Пресс, 2004. — 176–337 б.

**Хәким З.** Бит // Яңа татар пьесасы: 3 томда. — 2 т. — Казан: Идел-Пресс, 2004. — 285–345 б.

**Аның турында:**

**Зәйнуллин З.** Кыю кыен ашый: Зөлфәт Хәким драматургиясе турында уйланулар // Ватаным Татарстан. — 1996. — 2 апрель.

**Әхмәдуллин А.** «Күрәзәче»нең ялгышы: З.Хәкимнең «Күрәзәче» спектакле турында // Ватаным Татарстан. — 1998. — 15 май.

**Хәсәнова А.** Барысына бер Зөлфәт: Җырчы, композитор, драматург, прозаик З.Хәким иҗаты турында // Ватаным Татарстан. — 2001. — 26 октябрь.

**Саттарова А.** Современная татарская драматургия 1985–2000 гг. Концепция эпохи и героя. [О пьесах З.Хакима и др.] — Казань: Gumanitarya, 2003. — С. 13–23, 78–85, 117–122.

## РИЗВАН ХӘМИД (1941)

Ризван Хәмид (Ризван Мирхәбибулла улы Хәмидуллин) 1941 елның 24 октябрендә Башкортстанның Ярмәкәй районы Усман-Ташлы авылында туа. 1963–1971 елларда Казан педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. 1971 елда «Чаян» журналы редакциясендә фельетончы, соңрак хатлар бүлеге мөдире булып эшли. 1978–1979 елларда А.В.Луначарский исемендәге Мәскәү дәүләт театр сәнгате институтында берьеллык Югары курсларда укый. 1981–1983 елларда Чаллы язучылар оешмасын җитәкли, 1985–1987 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары вазифасын башкара.

Җитмешенче еллар ахырында әдәбият мәйданына килгән Р.Хәмиднең беренче җитди әсәре — «Синең урыныңа кайттым...» драмасы — 1978 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куела. Әдәби җәмәгатьчелекнең һәм тамашачыларның югары бәясенә лаек булган әлеге әсәр соңрак Әлмәт дәүләт драма театрында, шулай ук илебезнең күп кенә театрларында уйналды. Театр сәнгатенә беркемне дә кабатламый торган үзенчәлекле характерлар алып килгән драматург үзенең пьесаларында көнүзәк проблемаларны кыю рәвештә күтәрергә, күренеш-вакыйгаларның асылына төшенергә омтылуы белән аерылып тора. Әдипнең 30 дан артык драма әсәрләре арасында актуаль мәсьәләләрне яктырткан «Иске йорт кешеләре» (1979), «Кайтыр идем» (1979), «Каен җиле» (1981), «Китәм инде...» (1981–1982), «Майның унбишләрендә» (1984), «Ике сәгать — бер гомер» (1985) «О-лы юлның тузаны» (1986), «Җиде бажа» (1988) һ.б. бар. Әдипнең пьесалары Г.Камал исемендәге Та-

тар дәүләт академия театры, Лак драма театры (Махачкала), Әлмәт татар драма театры, Минзәлә дәүләт драма театры, Чаллы татар дәүләт драма театры һ.б. театрлар сәхнәләрендә уңыш казанды.

Драматургның балалар өчен язылган «Айдарның авыр көне» (1980), «Тәбе» (1982), шулай ук Рөстәм Мингалим белән берлектә иҗат ителгән «Тукай» (1992–1993) исемле күп серияле телевизион спектакль-фильм өчен драма, «Идегәй» (1994–1995) нәфис фильм өчен кинодраманы да санарга кирәк.

XX гасыр ахыры — XXI гасыр башында да актив иҗат итүче каләм остасы буларак, Р.Хәмид «Ак тамырлар иле» (1989–1990), «Хушлашырга безгә иртә әле» (1991), «Хан кызы» (1993–1994), «Исәнлеккә-саулыкка» (1994), «Көзнең соңгы яфраклары» (1996), «Җанкай улы Җанкыяр» (1998), «Тигезәкләр» (2000), «Адашкан морза» һ.б. пьесаларын язды.

Р.Хәмид драма, комедия, трагедия жанрларында иҗат итә. Аның пьесалары, рус, украин, грузин, кыргыз, эстон, латыш, башкорт, чуаш, кабардин һ.б. телләргә тәрҗемә ителеп, төрле театрларда уңыш казанды.

Р.Хәмидкә «Синең урыныңа кайттым...» һәм «Китәм инде...» драмалары өчен 1984 елда Муса Җәлил исемендәге Республика бүләге бирелде, ә 1991 елда ул «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Р.Хәмид — 1981 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Хәмид Р.** Кайтыр идем: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1982. — 168 б.
**Хәмид Р.** Каен җиле: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. — 160 б.
**Хәмид Р.** Олы юлның тузаны: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 192 б.
**Хәмид Р.** Китәм инде...: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 384 б.
**Хамид Р.** Охота на волка / Пер. с яз. драмы «Синең урыныңа кайттым...» Ю.Эдлиса. — М.: ВААП, 1978. — С. 73.
**Хамид Р.** Над обрывом / Пер. с тат. драмы «Кайтыр идем» Ю.Эдлиса. — М.: ВААП, 1979. — С. 56.
**Хамид Р.** Домик с колоннами / Пер. с тат. драмы «Иске йорт кешеләре» Л.Виноградова. — М.: ВААП, 1982. — С. 62.
**Хамид Р.** Под знаком Марса / Пер. с тат. драмы «Китәм инде...» В.Розова. — М.: ВААП, 1983. — С. 67.

**Аның турында:**

**Шәфигуллин Ф.** Хәбировлар характеры // Социалистик Татарстан. — 1978. — 24–26 май.
**Гыйләҗев А.** Үз урынына килде // Социалистик Татарстан. — 1982. — 26 сентябрь.
**Каюмова Г.** Тынгысыз йөрәк, яки Күңелләр чыңын кагучы // Мәдәни җомга. — 2002. — 13 август.
**Саттарова А.** Ризван Хәмиднең «Ак тамырлар иле» трагедиясендә чор һәм герой концепциясе // Milli Mədəniət. — 2002. — № 2. — 83–84 б.
Татар драматургиясе (1960–1980): Сайланма пьесалар. «Мәктәп китапханәсе» сериясе. — 21 т. / Төз. һәм кереш мәкалә авт. А.Саттарова. — Казан: ТаРИХ, 2003. — 329–364 б.
**Золотарев Е.** О драматургии Р. Хамида // Поднимаясь над бытом с мыслями о бытии. Золотое двадцатилетие. Очерки. — Казань, 1989. — С. 70–80.

## МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ (1927–1990)

Мәхмүт Максуд улы Хәсәнов 1927 елның 21 декабрендә Татарстанның Саба районы Югары Кибәхуҗа авылында туа. Гаиләләре 1937 елда Яшел Үзән шәһәренә күченеп килә, шунда Мәхмүт татар урта мәктәбен тәмамлый. Әдәбиятка, театр сәнгатенә бала чактан ук килгән мәхәббәте 1944 елда аны — уналты яшьлек егетне — Мәскәүгә А.В.Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтына (ГИТИСка) алып килә. Актерлык факультетын тәмамлап Казанга кайткач, Мәхмүт Хәсәнов Яшь тамашачылар театрында (ТЮЗда) актер булып эшли башлый. Бер елдан аны Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына чакыралар. Шул елларда (1949–1951) ул очерк, хикәяләр яза

башлый. Соңрак журналистика өлкәсендә эшли, газета редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, Татарстан радиосында хәбәрче вазифаларын башкара.

Илленче еллардан башлап Мәхмүт Хәсәнов хикәя-повестьларын яза, бер-бер артлы нефтьче-разведчиклар турындагы повестьлары басылып чыга. Язучы буларак ул проза өлкәсендә танылa, әдәбият тарихында зур күләмле «Саф җилләр», «Юллар-юллар», «Кама таңнары», «Шөгеровлар», «Язгы аҗаган» романнары белән танылып калды.

Илленче-алтмышынчы елларда Мәхмүт Хәсәнов шактый гына драма әсәрләре дә иҗат итә. Китап булып басылып чыкмасалар да, аның «Нурихан» дигән комедиясе, «Рамай» драмасы Әлмәт - татар драма театры сәхнәсендә (1955–1958), «Көя күбәләге» комедиясе Азнакай халык театрында (1962), «Хикмәтле Хикмәтулла» дигән әкият-пьесасы Казан курчак театрында (1965–1967) куела.

1977 елда аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

М.Хәсәнов 1965 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Аның турында:**

**Төхфәтуллин Р.** Дулкыннар ярга кага: М.Хәсәновка — 50 яшь. — Казан утлары. — 1977. — № 12. — 169–171 б.

**Галимуллин Ф.** Юл кешесе. — Казан утлары. — 1982. — № 3. — 147–155 б.

## ШӘРИФ ХӨСӘЕНОВ (1929–1999)

Шәриф Нургали улы Хөсәенов 1929 елның 26 ноябрендә Татарстанның Буа районы Өчмунча авылында туа. Башлангыч белемне туган авылында ала, соңыннан күрше Килдураз авылында укый, ә 1947 елда, Буа шәһәренең Мулланур Вахитов исемендәге урта мәктәбен тәмамлагач, Казандагы медицина институтына укырга керә. 1953 елда шифаханәдә эшли башлый, ә 1960–1962 елларда ул Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда белемен арттыра. Казанга кайткач, табиб булып эшли, бер үк вакытта әдәби эшчәнлек белән дә шөгыльләнә.

Язучы-драматург буларак, Ш.Хөсәенов «Профессор кияве» (1952) комедиясе белән танылa. 1952 елда бу әсәр пьесалар буенча уздырылган конкурста икенче премиягә лаек була һәм шул елдан башлап Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куела башлый (ике йөзгә якын спектакль). Әлеге комедия Башкорт дәүләт драма театры, Башкортстандагы Баймак һәм Аургазы театрлары, Татарстандагы Минзәлә, Дагстандагы Кумык, Себердә Хакас милли театрлары сәхнәләрендә уйнала.

Әдипнең «Бирнәле кыз» (1954), «Чулпан» (1955), «Зөбәйдә — адәм баласы» (1961), «Егерме ел үткәч» (1962), «Туган көнең котлы булсын» (1965), «Әниемнең ак күлмәге» («Әни килде», 1968), «Безнең подъезд төбендә» (1989–1993), «Көфер почмагы» (1993) һ.б. пьесалары дөнья күрә, күбесе, спектакль буларак, илебезнең төрле сәхнәләрендә озын гомерле була.

Драматургның «Әниемнең ак күлмәге» («Әни килде») драмасы — яшьләр һәм өлкәннәр арасындагы туган каршылыкларны, балаларның ана кешегә булган әхлаксызлыгын, игътибарсызлыгын, битарафлыгын, ана фаҗигасен әдәби мәйданда яктырткан уңышлы әсәрләрнең берсе. Автор, яшьләр тормышына, аларны борчыган проблемаларга басым ясап, буыннар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне дә яктыртуга ирешә. 1970 елдан башлап әлеге драма Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында гына да дүрт йөзгә якын тапкыр куела (режиссеры — М.Сәлимҗанов), рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителеп, кырыкка якын театрлар сәхнәсендә уңыш белән бара. Татар театрының йөзьеллык юбилеен каршылаганда да Ш.Хөсәеновның бу әсәре республикабызның әйдәп баручы театры репертуарында үз урынын били.

Ш.Хөсәенов «Мәхәббәт сагышы» (1964) исемле повесть һәм юмористик-сатирик хикәяләр авторы буларак та билгеле.

Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен 1979 елда Ш.Хөсәенов «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә һәм «Татарстанның атказанган табибы» дигән мактаулы исемгә лаек була.

Ш.Хөсәенов 1959 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Хөсәенов Ш.** Профессор кияве: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1958. — 187 б.
**Хөсәенов Ш.** Мәхәббәт сагышы: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1965. — 234 б.
**Хөсәенов Ш.** Зөбәйдә — адәм баласы: 3 пәрдәлек трагикомедия. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1968. — 82 б.
**Хөсәенов Ш.** Пьесалар (Т.Миңнуллин сүз башы). — Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. — 288 б.
**Хусаинов Ш.** Белое платье матери: Драма в 3 д. / Авториз. пер. П.Демина. — М.: ВУОАП, 1972. — С. 60.

**Аның турында:**

**Камалов Б.** Гаять үзенчәлекле талант: Ш.Хөсәеновка — 50 яшь // Татарстан яшьләре. — 1979. — 27 ноябрь.
**Миңнуллин Т.** Драматург // Казан утлары. — 1979. — № 11. — 125–127 б.
Татар драматургиясе (1960–1980): Сайланма пьесалар. «Мәктәп китапханәсе» сериясе. — 21 т. / Төз. һәм кереш мәкалә авт. А.Саттарова. — Казан: ТаРИХ, 2003. — 143–211 б.
Шәриф Хөсәенов: Повесть, очерклар, хатирә-истәлекләр, әңгәмәләр, хатлар / Төз. һәм кереш сүз авт. Р.Юсупова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 407 б.
**Илялова И.** Зоркий взгляд драматурга: Драматургу Ш.Хусаинову 50 лет // Советская Татария. — 1979. — 2 декабря.
**Миннуллин Т.** Пьесы, которые всегда современны // Вечерняя Казань. — 1979. — 4 декабря.

## ФАТИХ ХӨСНИ (1908–1996)

Фатих Хөсни (Фатих Хөснетдин улы Хөснетдинов) 1908 елның 3 февралендә Татарстанның хәзерге Саба районы Олы Мәтәскә авылында туа. Авылда башлангыч белем алганнан соң, 1924 елда Казанга килә, Мулланур Вахитов исемендәге күргәзмә-тәҗрибә мәктәбенә укырга керә. Шунда укыганда шигырьләр яза башлый, ул шигырьләре «Безнең юл», «Авыл яшьләре», «Яңалиф», «Атака» журналларында басылып чыга. 1927–1930 еллар арасында иҗаты активлаша — ул күп кенә очерклар һәм «Көрәш кызы», «Усаллар» дигән драма әсәрләре дә яза.

1929 елда Ф.Хөсни Казан дәүләт университетының экономика факультетына укырга керә. Аны тәмамлагач, армиягә алына — 1933–1935 елларда Казандагы Беренче укчы дивизиядә элемтәче, соңрак хәрби корреспондент булып хезмәт итә. Армиядән кайткач, газета редакцияләрендә эшли, журналист буларак авылларда күп йөри, завод-фабрикалардагы эшчеләр белән таныша, тормышны, кешеләрне өйрәнә.

«Йөзек кашы», «Җәй башы», «Авыл өстендә йолдызлар», «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел», «Мәйдан», «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» исемле роман, повестьлары, күпсанлы хикәяләре белән ул татар әдәбиятының классигы булып танылды.

Ф.Хөсни иҗатында драматургия, публицистика, әдәби тәнкыйть жанрлары да күренекле урын алып тора.

Әдипнең «Урманда» (1938) комедиясе, «Әбли авылы» (1949), «Еллар-юллар» (1956), «Бертуган Таһировлар» (1965) драмалары, үз вакытында Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелып, уңай бәя алды.

Ф.Хөснигә 1972 елда «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» повесте һәм хикәяләре өчен Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде. Ул шулай ук Хезмәт Кызыл Байрагы, Октябрь Революциясе, «Почет Билгесе» орденнары белән бүләкләнә.

Ф.Хөсни 1936 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Хөсни Ф.** Усаллар: Бүгенге тормыш драмасы. 4 пәрдәдә. — Казан: Татиздат, 1929. — 36 б.
**Хөсни Ф.** Урманда (Кунак кызның мәхәббәте): Комедия 4 пәрдәдә. — Казан: Татгосиздат, 1940. — 67 б.

**Аның турында:**

**Илялова И.** Бертуган Таһировлар // Социалистик Татарстан. — 1965. — 31 гыйнвар.
**Мостафин Р.** Бертуган Таһировлар // Казан утлары. — 1965. — № 10. — 138–140 б.
**Илялова И.** Возвращение Загита // Театральная жизнь. — 1965. — № 8. — С. 23.

## ГАБДУЛЛА ШАМУКОВ (1909–1981)

Габдулла Рухулла улы Шамуков 1909 елның 11 декабрендә хәзерге Ульяновск өлкәсе Әсән авылында туа. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Уфада Башкорт сәнгать техникумының театр бүлегендә укый һәм унбиш елга якын Башкорт дәүләт академия театрында актер булып эшли. 1946 елдан башлап гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә онытылмаслык образлар иҗат итә.

Театрдагы актерлык хезмәтен Габдулла Шамуков әдәби иҗат эше белән аерылгысыз бәйләп яши, күренекле сәхнә остасы, үткен каләмле язучы булып таныла. Драматургия өлкәсендәге хезмәтләре балалар әдәбияты белән бәйле була. Аның «Су кызы» (1942), «Рөстәм» (1944), «Серле таяк» (1944), «Уңган кыз» (1954) исемле әкият-пьесалары театрларда заманында зур уңыш белән баралар.

Габдулла Шамуков әдәбият тарихында мәсьәләләре, театр сәнгате турындагы фәнни һәм публицистик мәкаләләре белән дә урын алды. Иҗатының тагын бер нәтиҗәле эшчәнлеге тәрҗемә өлкәсенә карый: дөнья һәм рус драматургиясе классикларыннан У.Шекспир, Л. де Вега, П.Бомарше, Ф.Шиллер, А.Островский, А.Пушкин, Н.Гоголь, М.Горький әсәрләре күп еллар буена аның тәрҗемәсендә куелдылар.

Театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Г.Шамуков Башкортстанның атказанган, Татарстанның, Россиянең, СССРның халык артисты дигән мактаулы исемнәргә ия булды.

Ул 1944 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Шамуков Г.** Уңган кыз: Әкият-пьеса 3 пәрдәдә, 5 күренештә. — Казан: Татгосиздат, 1954. — 51 б.
**Шамуков А.** Водяная: Пьеса по мотивам детских стихов-сказок Г.Тукая. — Уфа: Башкнигоиздат, 1942. — С. 23.

**Аның турында:**

**Кумысников Х.** Габдулла Шамуков // Советская Татария. — 1957. — 8 мая.
**Гумеров А.** Актер и писатель // Советская Татария. — 1959. — 12 декабря.
**Гимранова Д.** Грани таланта // Советская Татария. — 1976. — 20 ноября.
**Элин Р.** Талант, не дающий стареть // Вечерняя Казань. — 1979. — 24 декабря.
**Сарымсаков Ш.** Талант һәм тырышлык: Г.Шамуковка — 70 яшь // Социалистик Татарстан. — 1979. — 23 декабрь.
**Гыймранова Д.** Картаймас иҗат // Казан утлары. — 1982. — № 1. — 182–186 б.

## ШАМИЛ ШАҺГАЛИ (1920–1987)

Шамил Шаһгали (Шамил Шаһгали улы Миңлегалиев) Башкортстанның Чакмагыш районы Калмашбаш авылында туа. Яшьли ятим калып, балалар йортында тәрбияләнә. Чиләбе өлкәсендәге Аргаяш урта мәктәбен һәм Эстәрлетамак шәһәрендә берьеллык радистлар курсын тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан кайткач, Уфада халык иҗаты йорты директоры булып эшли. Башкорт дәүләт педагогия институтында укый, аннан Башкортстан һәм Татарстан мәктәпләрендә укытучы булып эшли. 1962–1966 елларда Ш.Шаһгали Мәскәүдә Югары әдәби курсларны һәм режиссерлык курсларын тәмамлый.

1955 елда ул үзенең «Бала бәхете — ана бәхете» исемле беренче пьесасын яза.

1959 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында аның «Таң атканда» пьесасы куела. Шулай ук «Без аерылышмабыз», «Яшьлек мәхәббәте», «Дуслык һәм мәхәббәт», «Курай моңы», «Тайга йолдызы» пьесалары Башкортстан һәм Татарстан театрлары сәхнәләрендә бара.

1955–1983 еллар арасында драматург өч дистәгә якын сәхнә әсәре иҗат итә.

Ш.Шаһгали 1962 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Шаһгали Ш.** Таң атканда: Драма. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1960. — 105 б.

**Шаһгали Ш.** Пьесалар: Буран. Таң атканда. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1975. — 119 б.

**Аның турында:**

**Гыйммранова Д.** Дуслык һәм мәхәббәт [Ш.Шаһгали пьесалары Минзәлә театры сәхнәсендә] // Татарстан яшьләре. — 1963. — 5 октябрь.

**Әпсәләмова Г.** Дуслык һәм мәхәббәт // Кызыл таң. — 1965. — 13 июль.

**Илялова И.** И яна ла йөрәгем! // Социалистик Татарстан. — 1986. — 26 июль.

**Гыймранова Д.** И яна ла йөрәгем! // Социалистик Татарстан. — 1986. — 22 апрель.

Ш.Шаһгалинең тууына 80 ел // Казан утлары. — 2000. — № 6. — 188 б.

## СӘЕТ ШӘКҮРОВ (1917–1989)

Сәет Габделхәй улы Шәкүров 1917 елның 14 декабрендә Татарстанның Балык Бистәсе районы Балыклы Чүкәй авылында туа. Гомуми урта белемне Казанда М.Вахитов исемендәге күргәзмә-тәҗрибә мәктәбендә ала, 1934–1938 елларда Казан театр техникумында укый. Техникумны тәмамлагач, 1938–1942 елларда Татар дәүләт академия театрының колхоз-совхоз филиалында, соңрак Минзәлә колхоз-совхоз театрында актер булып эшли. 1942 елда армиягә алына, Ленинград хәрби ветеринария училищесында укый һәм фронтның алгы сызыгына җибәрелә. Германия җиңелгәч, Көнчыгышта Япониягә каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, каты яралана. Сугышчан хезмәтләре өчен орден һәм медальләр белән бүләкләнә.

1946 елны армиядән кайткач, Сәет Шәкүров актерлык хезмәтен дәвам итә. 1946–1956 елларда Мамадыш, Әлмәт, Минзәлә колхоз-совхоз театрларында, Республика күчмә театрында эшли, 1956–1959 елларда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйный. Аннары ун ел буе Академия театрының баш администраторы, 1975 елдан Республика күчмә театрының директоры булып эшли.

Сәет Шәкүровның драматургия өлкәсендәге беренче адымы 1938 елда язылган «Орденлы Касыйм» исемле пьесасы була. Аның күләмле икенче әсәре — «Тормыш бусагасында» драмасы — егерме елдан соң гына дөнья күрә һәм 1958 елда Минзәлә театры сәхнәсендә куелып уңыш казана. Алтмышынчы елларда инде Минзәлә, Оренбург татар профессиональ театры сәхнәләрендә драматургның шигырь белән язылган «Зөһрә йолдыз» трагедиясе, «Уракчы кыз», «Мәхәббәт газабы», «Сары елан», «Кыз биру», «Карт гашыйк» кебек драмалары һәм комедияләре уйнала.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында барган «Туган туфрак» (1969), «Тол хатыннар, тол кызлар» (1973) драмалары — бүген дә актуальлекләрен югалтмаган әсәрләр.

Бөтенсоюз смотрында «Уракчы кыз» спектакле белән катнашкан Әтнә халык театры 1967 елда лауреат исеменә лаек була.

1970 елда С.Шәкүровка «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

Ул 1970 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Шәкүров С.** Тормыш бусагасында: Драма 4 пәрдәдә, 7 күренештә. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1967. — 84 б.

**Шәкүров С.** Зөһрә йолдыз: Трагедия 8 күренештә. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1968. — 121 б.
**Шәкүров С.** Уракчы кыз: Драма 8 күренештә. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1969. — 74 б.
**Шәкүров С.** Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1971. — 192 б.
**Шәкүров С.** Ике пьеса. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. — 146 б.
**Шәкүров С.** Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. — 180 б.
**Шәкүров С.** Сине ташлап китә алмыйм: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1983. — 104 б.

**Аның турында:**

**Камал Ә.** Җитдилек җитәме? // Татарстан яшьләре. — 1965. — 16 сентябрь.
**Мәхмүтов Һ.** Мораль сафлык өчен // Социалистик Татарстан. — 1968. — 3 сентябрь.
**Мәхмүтов Һ.** Сәет Шәкүров драмалары // Казан утлары. — 1971. — № 2. — 139 б.
**Гыйззәт Б.** Әсәрдән әсәргә үсә бара // Казан утлары. — 1971. — № 2. — 183 б.
**Әпсәләмова Г.** Ике спектакль тәэсире // Кызыл таң. — 1971. — 31 июль.
**Мәхмүтов Һ.** Тол хатыннар, тол кызлар // Социалистик Татарстан. — 1973. — 4 апрель.
**Хәсәнов М.** Сары елан // Социалистик Татарстан. — 1974. — 24 февраль.
**Гаффар Ә.** Күңелдәге Зөһрә йолдызлар: Драматург С.Шәкүровка — 60 яшь // Социалистик Татарстан. — 1977. — 18 декабрь.
**Сафиуллин Ә.** Юксындыра // Ватаным Татарстан. — 1997. — 16 декабрь.
Сәет Шәкүровның тууына 80 ел // Казан утлары. — 1997. — № 12. — 186 б.

## ИЛДАР
## ЮЗЕЕВ
## (1933–2004)

Илдар Гафур улы Юзеев 1933 елның 3 гыйнварында Башкортстанның Яңавыл районы Ямады авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. 1950–1954 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар филологиясе бүлегендә укый. 1954–1967 елларда И.Юзеев «Ялкын» журналының җаваплы сәркатибе, «Чаян» журналының әдәби хезмәткәре булып эшли. 1967 елдан Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант вазифасын башкара. 1973 елда Мәскәүдә Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлагач, И.Юзеев «Казан утлары» журналының поэзия бүлеге мөдире булып эшли. 1977–1987 елларда Татарстан Язучылар берлегендә яшь авторлар белән эшләү бүлеге мөдире һәм идарә рәисенең урынбасары вазифасын башкара.

Мәктәптә укыган вакытта аның шигырьләре Уфада «Әдәби Башкортстан» (хәзерге «Агыйдел») журналында, «Кызыл таң» газетасында басыла башлый. 1956 елда язучының «Таныш моңнар» исемле беренче поэмалар һәм шигырьләр җыентыгы дөнья күреп, укучы һәм тәнкыйть тарафыннан югары бәяләнә. Бу еллардан башлап И.Юзеевның бик күп лирик шигырьләре, поэмалары, балладалары дөнья күрә: «Тау чишмәсе» (1958), «Поэмалар, шигырьләр» (1960), «Яшь наратлар» (1965), «Поэмалар» (1966), «Яшьлек дустыма» (1967), «Төнбоек» (1970), «Карурман» (1973), «Бөркетләр кыяга оялый» (1975), «Кыр казлары артыннан» (1980), «Мәхәббәт китабы» (1982), «Калдыр, аккош, каурыеңны...» (1997), «Аю сатам, кем ала?» (1999) һ.б.

И.Юзеев поэзиясе лиризм, психологизм, хис-кичерешләргә бай булуы белән аерылып тора. Аның шигырьләренә көй язылган җырлар арасында «Яшь наратлар», «Кайтам инде», «Бөркет турында җыр», «Мәтрүшкәләр», «Сине уйлап янам» һ.б. халык күңелен тиз яулады.

Шагыйрь үзен либретто жанрында да сынап карый. «Ерактагы кәккүк авазы» операсына либретто яза (композиторы — Р.Кәлимуллин).

Илдар Юзеев оста драматург буларак та танылды. «Сандугачлар килгән безгә» (1974), «Кыр казлары артыннан» (1976), «Кайтмый калсам, көтәрсеңме?» (1977), «Бәхетемнән узып барышлый», «Сөйгәнемнең туган көне», «Безнең әти мировой» (1989), «Гашыйклар тавы» (1965–1993), «Эзләдем, таптым, югалттым» (1997) һ.б. драмаларында һәм комедияләрендә иҗтимагый-мәдәни, милли проблематикалар күтәрелә. Әдипнең «Ак калфагым төшердем кулдан» (1990) әсәрендә туган җирендә һәм эмиграциядә яшәгән татарларның көнкүреше яктыртыла. Халыкның телдән, гореф-гадәтләрдән, мәдәниятеннән ерагаюны автор сәяси проблемалар белән дә бәйли. «Очты дөнья читлегеннән» драмасында И.Юзеев татар халкының мәшһүр улы Г.Тукай образын тудыра.

Әсәрнең идеясен укучыга һәм тамашачыга җиткергәндә әдип сәнгать чараларыннан оста файдалана. Мәсәлән, «Мәңгелек белән очрашу» (1983) трагедиясе тирән психологизм, фәлсәфилек, мифологиягә мөрәҗәгать итү белән аерылып тора.

Шагыйрь-драматург пьесалары спектакль буларак та озын гомерле булып, Татарстанда һәм Россиянең төрле театр сәхнәләрендә уңыш казанды. Аның әсәрләре Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Казан дәүләт яшьләр театры, Башкорт дәүләт академия театры һ.б. театрлар сәхнәсендә куелды. «Сандугачлар килгән безгә» моңсу комедиясе татар, башкорт, мари милли театрлары, Тува, Санкт-Петербург һәм башка төбәкләрдәге рус театрлары сәхнәләрендә куелды, телеспектакль буларак күрсәтелде.

Илдар Юзеев «Миләүшә» җыентыгы өчен 1968 елда Муса Җәлил исемендәге Республика бүләгенә лаек була. 1980 елда аңа «Таш диварлар авазы» һәм «Өзелмәс кыллар» поэмалары өчен Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелә. Драматургия өлкәсендәге хезмәтләре өчен И.Юзеев 1979 елда Татарстанның, 1982 елда Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәргә ия була. 1986 елда «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә. 1993 елда Илдар Юзеевка «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелә.

И.Юзеев 1958 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Юзеев И.** Янар чәчәк: Комедия 3 пәрдәдә, 5 күренештә. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1962. — 79 б.
**Юзеев И.** Кыр казлары артыннан: Пьесалар. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1980. — 207 б.
**Юзеев И.** Мәңгелек белән очрашу: Трагедияләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1985. — 256 б.
**Юзеев И.** Сандугачлар килгән безгә: Комедияләр, драмалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. — 350 б.
**Юзеев И.** Шагыйрь сәхнәсе: Драмалар, комедияләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. — 191 б.
**Юзеев И.** Ахырзаман гашыйклары // Яңа татар пьесасы: 3 томда. — 1 т. — Казан: Идел-Пресс, 2004. — 398–435 б.

**Аның турында:**

**Хөсни Ф.** Уйна, уйна, моңлы сазым!: Шагыйрь И.Юзеев портретына кайбер штрихлар // Хөсни Ф. Ни әйтергә? Ничек әйтергә? — Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. — 190–196 б.
**Кукушкин Р.** Канатлы дөнья. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1984. — 185 б. (И.Юзеев турында 152–153 б.)
**Игъламов Р.** Хакыйкатьне эзләү юлыннан // Казан утлары. — 1983. — № 1. — 156–161 б.
**Даутов Р., Нуруллина Н.** Совет Татарстаны язучылары. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. — 559–563 б.
**Мостафин Р.** Илдар Юзеев // Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. — Казан: Раннур, 2001. — 299–314 б.
**Даутов Р.** Балачак әдипләре: Беренче китап. — Казан: Мәгариф, 2002. — 223 б. (Илдар Юзеев турында 199–207 б.)
**Ихсанова Л.** Тирән яра: Шагыйрь И.Юзеев турында истәлекләр // Сабантуй. — 2005. — 29 гыйнвар.
**Мөгътәсимова Л.** Аның изге әманәте: И.Юзеев турында истәлекләр // Мәдәни җомга. — 2005. — 28 гыйнвар.
**Поварисов С.** Моң эчендәге матурлык: Шагыйрь И.Юзеев иҗаты турында // Мәдәни җомга. — 2005. — 7 октябрь.
**Кумысников Х.** В согласии и в споре с драматургией // Советская Татария. — 1983. — 30 июня.

## ФӘНИС ЯРУЛЛИН (1938)

Фәнис Яруллин (Фәниз Гатаулла улы Яруллин) 1938 елның 9 февралендә Татарстанның Баулы районы Кызылъяр авылында игенче-крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Язучының балачагы авыр сугыш елларына туры килә. Җидееллык белемне туган авылында ала, сигезенче сыйныфны Баулы урта мәктәбендә тәмамлый. 1954 елда ул Баулы элемтә конторасында монтер булып эшли башлый. 1957 елда гаскәри хезмәткә чакырыла. Армиядә һава укчы-радистлар мәктәбендә укый. Спорт күнегүләре белән шөгыльләнгән вакытта умыртка сөяген имгәтеп, гомергә йөри алмас хәлдә кала. Озак вакыт дәвалануга карамастан, Ф.Яруллин үз алдына җитди максатлар куя. 1970 елда, читтән торып

укып, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Шул елларда әдипнең язучылык сәләте ачыла: беренче шигырь һәм хикәяләре газета-журнал битләрендә дөнья күрә. 1964 елда шагыйрьнең «Мин тормышны яратам» исемле беренче шигырь җыентыгы басыла. Алга таба әдипнең «Май төне» (1966), «Бакчалар бәскә төренә» (1967), «Минем елмаю» (1968), «Зәңгәр күлдә Ай коена» (1990), «Өе балчык, иясе карчык» (1996) һ.б. җыентыклары нәшер ителә.

1971 елда Ф.Яруллин, автобиографик характерда язылган «Җилкәннәр җилдә сынала» повестен язып, киң масса укучылар алдында танылa. Әдипнең «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра», «Чәчәкләр моңы», «Кайту», «Яралы язмышлар» повестьлары тиз арада халык күңелен яулап ала.

Ф.Яруллин драма әсәрләрен иҗат итүче буларак та танылды. Аның «Язмышларны кабат узып булмый» (1994), «Бер күрешү — үзе бер гомер» (1996), «Кызларның кызганнары» (1996–1997), «Әнә килә автомобиль», «Шүрәлеләр каргышы», «Бай эти», «Ак яфрак» һ.б. пьесалары көн кадагына суккан идея-проблематикасы, образлар системасы белән аерылып тора. Әдипнең драма әсәрләре «Һәр күңелдә сер ята» (1991), «Пьесалар» (1998), «Өе балчык, иясе карчык» (1996) исемле җыентыкларда дөнья күрде. Драма әсәрләренә куелган спектакльләр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында, Казан дәүләт яшьләр театрында, шулай ук Татарстанның Әлмәт, Минзәлә, Чаллы татар дәүләт театрларында һәм Башкортстандагы Туймазы һәм «Нур» театрларында уңыш казанды.

1964–2000 елларда утыздан артык җыентык чыгарган язучы «Аерылмас дустым» (1975) һәм «Сулыш» (1978) шигырь китаплары өчен 1978 елда Муса Җәлил исемендәге Республика бүләгенә, ә лирик шигырьләре һәм поэмалары тупланган «Җан авазы» җыентыгы өчен 1995 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. 1985 елдан язучы «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем йөртә. Әдип 1985 елдан Халыклар Дуслыгы ордены кавалеры. Татар әдәбиятын үстерүдәге зур казанышлары өчен Фәнис Яруллинга 2001 елда «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелде.

Ф.Яруллин — 1968 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

### Басылган драма әсәрләре:


**Яруллин Ф.** Әсәрләр: 3 томда. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.

**Яруллин Ф.** Һәр күңелдә сер ята: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. — 319 б.

**Яруллин Ф.** Өе балчык, иясе карчык: Курчак театрлары, мәктәп сәхнәләре, әдәби түгәрәкләр өчен әкият-пьесалар. — Казан: Мәгариф, 1996. — 64 б.

**Яруллин Ф.** Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. — 319 б.

**Яруллин Ф.** Сайланма әсәрләр: 5 томда. — 2 т.: Эссе, повестьлар, пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 493 б.

**Яруллин Ф.** Хочу автомобиль: Комедия в 2 д. / Пер. с тат. В.Гольфельд. — М.: ВААП, 1975. — С. 55.


### Аның турында:


**Галиев Ш.** Уйлана, эзләнә // Казан утлары. — 1968. — № 4. — 143 б.

**Миңнуллин Р.** Килгән буын хакына // Казан утлары. — 1978. — № 11. — 153–160 б.

**Даутов Р.** Балачак әдипләре: Беренче китап. — Казан: Мәгариф, 2002. — 223 б. (Ф.Яруллин турында 214–220 б.)

**Хуҗиәхмәтов Ә., Хәкимова С.** Фәнис Яруллин — шәхес, шагыйрь, тәрбияче. «Мәктәп китапханәсе» сериясе. — 1 т. — Казан: ТаРИХ. — 3–16 б.

**Хәкимова С.** Ф.Яруллин хикәяләренең жанр төрләре // Сб. мат. итог. науч. конференции молодых ученых Института истории им. Марджани АН РТ. — Казан, 2003–2004. С. 372–375


## ЭСФИР
## ЯҺУДИН
## (1949)

Эсфир Яһудин (Яһудин Хамис Шәмсигали улы) 1949 елның 4 гыйнварында Башкортстанның Краснокама районының Яңа Хаҗи авылында туа. Туган авылында 8 сыйныф татарча белем алгач, район үзәгенә йөреп урта мәктәпне тәмамлый. Шул вакытта беренче шигырьләре «Таң» газетасында нәшер ителә башлый. Армиягә алынгач, читтән торып хәрби хәбәрчеләр мәктәбендә укый. Беренче мәкаләләре һәм парчалары «Во славу Родины» газетасында басыла. Хәрби хезмәттән соң физкультура укытучысы булып эшли, читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый. Шул вакытта шигырьләр, хикәяләр, музыка яза. 1974 елда Казанга килеп, Казан органик синтез заводына эшкә керә. 1978 елда Казан дәүләт курчак театрында сәхнә эшчесе, бер үк вакытта актер булып эшли.

1979 елда Эсфир Яһудин Татарстан Язучылар берлеге юлламасы белән Мәскәүгә М.Горький исемендәге Әдәбият институтына укырга китә. Драматургия семинарын тәмамлаганнан соң, Әлмәт дәүләт татар драма театрында әдәби бүлек мөдире булып эшли башлый. Шул вакытта Б.Васильевның «А зори здесь тихие» исемле повесте нигезендә эшләнгән пьесаны, татарчага тәрҗемә итеп, Әлмәт театрында куйдыра.

1989 елда Э.Яһудин, Нефтекама каласында «Прометей» ял һәм мәдәният үзәгендә шәхси театр ачып, шуның директоры вазифасын башкара. Бу вакытта үзе язган пьесаларны сәхнәгә куя, күп районнарга гастрольләр оештыра.

Әдипнең К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында 1993 елда куелган «Мәхәббәткә мәдхия» исемле мелодрамасы озак еллар сәхнәдән төшми. Әлмәт татар драма театрында «Мәхәббәт зилзиләсе», «Эт чаба дип...» исемле пьесалары, Яр Чаллы театрында «Әйттереп калыйк әле!» һ.б. комедияләре һәм драмалары сәхнәләштерелә. Үзе куйган «Ашыгасың, Сафа!» музыкаль комедиясе тугызынчы ел Минзәлә театры сәхнәсендә бара.

1992 елда әдип Татарстан кинокомитеты юлламасы белән Мәскәүгә кинодраматургларның Югары курсларына укырга җибәрелә. Аннан кайткач, ул, «Оҗмах газабында өч төн», «Әсфәндияр» исемле киносценарийлар язып, «Идел» журналында бастыра. Рөстәм Мингалим белән бергәлектә иҗат ителгән «Ак метеор» исемле киноповесть Себер татарларының беренче шагыйре Булат Сөләйман язмышына багышланган.

Эсфир Яһудин, берничә ел дәвамында үткәрелгән «Яңа татар пьесасы» конкурсында катнашып, лаеклы урыннар били. Аның «Бер кояш астында» драмасы 2004 елда «Яңа татар пьесасы» җыентыгының икенче кисәгендә басылып чыга. Әдипнең республикабыз театрларында уңыш белән барган сәхнә әсәрләре — «Идел буе сәхифәсе», «Тәтәй кызлар утары», «Киң урамнар тар иде», «Әгәр дә көн туса», «Тутый кош» — 2004 елда нәшер ителгән «Мәхәббәткә мәдхия» дигән пьесалар җыентыгында урын алды.

Әдип проза өлкәсендә дә эшчәнлеген туктатмый. 1996–2006 еллар эчендә аның сигез повесте басылып чыкты.

2006 елда Эсфирның Оренбург шәһәрендәге Татар драма театрында бер пьесасы сәхнәләштерелде һәм Яр Чаллы театрында «Китмәскә килгән кошым» исемле музыкаль комедиясе куелды.

Э.Яһудин Бөек Ватан сугышы каһарманнары Муса Җәлил һәм Гайнан Кормашка багышлап язган сонетлар авторы буларак та билгеле. Аның иҗатының «Шәхесләр циклында» Зәет Мәҗитов, Гариф Ахунов, Эдуард Мостафин, Булат Сөләйман, Фәиз Зөлкарнәй, Сибгат Хәким һәм башка әдипләр турындагы парчалары аерым урын алып тора.

Эсфир Яһудин — 1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Басылган драма әсәрләре:**

**Яһудин Э.** Мәхәббәткә мәдхия: Пьесалар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 239 б.
**Яһудин Э.** Бер кояш астында // Яңа татар пьесасы: 3 томда. — 2 т. — Казан: Идел-Пресс. 2005. — 392–428 б.

**Аның турында:**

**Мингалим Р.** Ул яза гына белә: // Шәһри Казан. — 1999. — 15 гыйнвар.

# ЭЧТӘЛЕК

*Кереш сүз* ............................

Алиш Абдулла .........................
Аманулла (Әмир Камалиев) ..................
Аппакова Дәрҗия .......................
Ахунов Гариф .........................
Әблиев Мөхәммәт .......................
Әминов Юныс .........................
Әмир Мирсәй ..........................
Әмири Кәрим ..........................
Әмиров Кәшшаф ........................
Әмирхан Фатих .........................
Әхмәт Абдулла .........................
Идрис Багданов .........................
Баттал Салих ..........................
Батулла Рабит ..........................
Баян Әхсән ...........................
Бәйрәмова Фәүзия .......................
Бәкер Кәбир ..........................
Бикчурин Шамил ........................
Бохараев Равил .........................
Бурнаш Фәтхи .........................
Вахит Хәй ............................
Вәлиев Диас ...........................
Вәлиев Разил ..........................
Вәли Ярулла ..........................
Галәү Мәхмүт .........................
Галиев Гариф ..........................
Галиев Фәнәвил ........................
Галимов Әкрам .........................
Гаффар Әхәт ..........................
Гафури Мәҗит .........................
Гобәй Гариф ..........................
Гыйззәт Таҗи ..........................
Гыйләҗев Аяз .........................
Гыйләҗев Мансур .......................
Гыйльманов Галимҗан .....................
Зәбири Хәбибрахман ......................
Зәйдулла Ркаил .........................
Зәйнашева Гөлшат .......................
Зәйни Шаһиморат .......................
Җәләлов Хәлим ........................
Җәлил Муса ...........................
Җиһаншина Рәшидә ......................
Ибраһимов Галимҗан .....................
Ибраһим Хәбир .........................
Иделле Газиз ..........................
Ильяс Рахман ..........................
Ильяси Габдрахман .......................
Исәнбәт Нәкый .........................
Исхакый Гаяз ..........................
Ишморат Риза .........................
Ишморатова Рәисә .......................
Казаков Исхак .........................
Кальметов Сәет .........................
Камал Галиәсгар ........................
Камал Әнәс ...........................
Камал Шәриф ..........................
Кариев Габдулла ........................

Каюмов Гафур .........................
Коләхмәтов Гафур .......................
Корбан Рафис ..........................
Кутуй Гадел ...........................
Лерон Ләбиб ..........................
Маликова Мәдинә .......................
Мәхмүтова Исламия ......................
Мингалим Рөстәм .......................
Минский Габдрахман ......................
Миңнуллин Туфан .......................
Монасыйпов Газиз .......................
Насрый Гамир .........................
Нәҗми Кави ...........................
Рахманколый Әхмәт ......................
Рәкыйпов Шамил ........................
Рәмиев Исмәгыйль .......................
Рәмиев Сәгыйть ........................
Рәхим Гали ...........................
Рәхим Гәрәй ..........................
Сабитов Габделхәй .......................
Садриев Фоат ..........................
Садри Г.-Халикъ ........................
Салихов Данил .........................
Саттаров Шәриф ........................
Сафиуллин Юныс .......................
Сәгыйди Әбрар .........................
Сәгъди Рәдиф ..........................
Сәйфи-Казанлы Фатих .....................
Такташ Һади ..........................
Тинчурин Кәрим ........................
Толымбай Гомәр ........................
Туйкин Фазыл ..........................
Укмаси Миргазиз ........................
Уральский I ...........................
Усманов Шамил ........................
Фәйзи Әхмәт ..........................
Фәйзи Мирхәйдәр .......................
Фәттах Нурихан ........................
Фәхретдинов Шамил ......................
Халиди Фатих .........................
Хәким Зөлфәт .........................
Хәмид Ризван .........................
Хәсәнов Мәхмүт ........................
Хөсәенов Шәриф .......................
Хөсни Фатих ..........................
Шамуков Габдулла ......................
Шаһгали Шамил ........................
Шәкүров Сәет .........................
Юзеев Илдар ..........................
Яруллин Фәнис .........................
Яһудин Эсфир .........................

Биобиблиографический справочник

Составители:

**Ганиева** Флера Акрамовна, **Яруллина** Рамиля Асхадулловна,
**Саттарова** Алсу Мансуровна

**ТАТАРСКИЕ ДРАМАТУРГИ**

На татарском языке

Биобиблиографик белешмәлек

Төзүчеләре:

**Ганиева** Флера Әкрәм кызы, **Яруллина** Рамилә Әсхәдулла кызы,
**Саттарова** Алсу Мансур кызы

**ТАТАР ДРАМАТУРГЛАРЫ**

Мөхәррире *В.Р.Шәрипова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.02.2007.
Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Times New Roman» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 14,28. Шартлы буяу-оттиск 14,70.
Нәшер-хисап табагы 11,99. Тиражы 3000 д. Заказ С-325.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.
«Идел-Пресс» полиграфия- нәшрият комплексы ААҖ. 420066.
Казан, Декабристлар урамы, 2.